Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 26 (1391) 8 июль 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga
madanizhomga
madani_zhomga



8

Графика юнәлешен сайлаган рәссам Радик Мусин һәр иҗат кешесенең үз йөзе, үз стиле булырга тиеш дип саный.



12

Башкортстан якларына яңа сәфәр вакытында күрше республикада Салават Юлаевны ничек зурлаганнарына, кадерләгәннәренә сокланмый кала алмадык.



14

Милләтебездә чишмәләргә карата борын-борыннан килгән хөрмәтне искә алып, Саба төбәгендә бик матур гореф-гадәтләрне яңарта башладылар.

Әһле ислам дога кылган чакта, Сәҗдә итә булыр бар җиһан...

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Чуашия Республикасына эш сәфәре кысаларында Урмай авылында төзекләндерелгән Җәмигъ мәчетен ачуда катнашты.

- Россия почтасы Ростуризм һәм Рус география җәмгыяте белән берлектә Татарстанның танылган урыннары төшерелгән открыткалар чыгарды.

- Кама Тамагы районының Мәрәтхуҗа авылында Туфан Миңнуллинның музей-йорты рәсми рәвештә кунаклар кабул итә башлады.

- Бу елның август-сентябрь айларында беренче тапкыр «Иң яхшы туган тел һәм әдәбияты укытучысы» Бөтенроссия конкурсы узачак.

- Азнакай шәһәренең Мәдәни үзәгендә Россия һәм Татарстанның халык артисты Әзһәр Шакировның «Халкыбызның кадерле шәхесләре» исемле яңа китабын тәкъдим итү кичәсе булды.

- Иртәгә Татарстан Милли китапханәсендә «Биләр. Мирас хәзинәсе» документаль фильмы тәкъдим ителә.

- Бөтендөнья татар конгрессы Милли шура рәисе Васил Шәйхразиев Мордовиянең «Умырзая» җыр һәм бию ансамбленә милли киемнәр тектерү өчен сертификат тапшырды.

- Санкт-Петербургта рәссам Илдус Вахитовның «Тылсымлы Татарстан» күргәзмәсе ачылды.

- Корбан ае башлану уңаеннан, Татарстан мөфтиятенең «Зәкят» хәйрия фонды 30 мохтаҗ гаиләгә азык-төлек җыелмалары таратты.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Винера ГАНИЕВА, җырчы, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты:

«Җырчы һөнәре бик җиңел дип уйламасыннар. Ул бик авыр. Кеше күңеленә онытылмаслык шәхес булып керәп каласың килсә, син үз тембрыңны табарга, җырны җиренә җиткереп башкарырга тиеш. Тавыш күп кешедә бар, безнең халык җырлый торган, моңлы халык. Өстәл артында кунаклар арасында җырлау әйбәт күренеш, ләкин җырчы булыр өчен табигатьтән бирелгән сәләтне саклап, үстерер өчен син беркемгә дә охшарга тиеш түгел».

СЫНАМЫШЛАР

8 июльдә эссе булса, челлә 40 көнгә сузыла ● 10 июльдә яңгыр яуса, әбиләр чуагына кадәр туктамый ● 12 июльдә (Питрауда) яңгыр яуса, печән череп бетә ● Питраудан соң өч-дүрт көн үткәч сандугач сайраса, тагын биш атнадан көз башланыр ● Питраудан соң бер атна үткәч күке кычкырса, көз озак булыр ● Питраудан соң сандугачның теле бетә, үләннең тәме бетә.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 10 минутта** чыкты, һәм ул **20 сәгать 26 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **17 сәгать 16 минут**. Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **17 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **15 июльдә 16 сәгать 59 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

8 июль – әдәбият галиме, археограф Альберт Сәет улы Фәтхиевнең туууына 85 ел (1937–1992);

– шагыйрь Рифат Гали улы Сәлаховка 35 яшь (1987).

10 июль – рәссам Халидә Нуриман кызы Гыйләҗевага 70 яшь (1952).

11 июль – шагыйрә Дилә Хәмзә кызы Бикмәтовага (Булгакова) 85 яшь (1937);

– Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Люция Миннәхмәт кызы Хәмитовага 55 яшь (1967).

13 июль – сәясәт һәм дәүләт эшлеклесе, публицист Мирсәет Хәйдәргали улы Солтангалиевнең туууына 130 ел (1892–1940).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июльнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(7-13 июль)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 майдан 27 июльгә кадәр** йөрәк һәм нечкә эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көне

ҖАН АВАЗЫ

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН

Хәсән Туфанны юксыну

Шигъри тылсым иясе Хәсән Туфан язмышына ишелеп төшкән нахак яла ягулардан, тоткынлыктан, зиндан ишекләренең эчпошыргыч шыгырдауларыннан котылып, туган Татарстаны җиренә 1956 елда аяк баса. Шул ук саңәдә аны нечкә зәвыклы, атаклы «Флейталар» поэмасы авторы Әхмәт Фәйзи «Еллар өстәлгәннәр яшенә» тезмәсе белән сәламли.

Еллар өстәлгәннәр яшенә,
Кырау төшкән аның чәченә –
Заман үзенекен эшләгән.

Шундый олы җанлы, сабый балалардай ихлас йөрәкле затны рәнҗеткән өчен үпкәсен белдергәннән соң, аны Улан-Удэ шәһәрендә качак татар балаларын укытканда «Советларга каршы котки, үгет алып барган», дип гаепләүләргә карамастан, корыч холыклы Туфан кальбен үзгәртмәгән, тәшенкелеккә бирелмәгән дигән гөманын калкытып куя.

Нинди усал җилләр иссә дә,
Чәчләренә кырау төшсә дә,
Йөрәгенә кырау төшмәгән.

Исемнәргә, сәләтле каләм ияләренә бай һәм бигрәк тә милли гамьле шәхесләргә ифрат игътибарлы татар сүз сәнгатендә Туфан иҗаты, аның сынмас-сыгылмас холкы белән сокланып рухланмаган һәм уй-хисләрен шигъри юлларга салмаган татар телле каләм иясе юктыр! Шул олы «манара»га лаеклы сүз зебәрҗәте таба алмый интегүчеләре дә аз булмагандыр шәт. Чөнки С.Хәкимнең «Туфан дәфтәре» бәйләменнән, Зөлфәтнең «Чык төшкәндә Парнас тавына», Г.Рәхимнең «Туфан елмаюы», К.Сибгатуллинның «Туфан белән сөйләшү», «Туфаннар» шигырьләреннән, Р.Харис, Р.Фәйзуллин, Л.Шагыйрьҗан, З.Мансуров, Г.Морат, Зәйдулла һ.б. каләмнәреннән төшкән җылы сүзләрдән соң яңачалыгы белән шаккатыруы кыен һәм сират күперен чыгуга тиң иде.

Туфан белән иңен-иңгә терәп иҗат иткән С.Хәким аның бер «физик халәтен» искә төшерү аша каләмдәшенең шигъри үзенчәлеген калкытып куюга ирешә:

Баһадирлар кебек йоклый,
Чыраенда: уф ардым...
Җыры башка, хәтта башка
Йокысы да Туфанның.

Чәчмә жанрда Туфан иҗатына затлы бәянең дустанә фикердәше, Аккош күлендә яшәгәндә шатлыгын-кайгысын бүлешкән Гомәр Бәширов каләменнән төшүе табигый иде. Ул «Бүген дә, иртәгә дә» исемле язмаларында Туфан шәхесен, аның иҗади үзенчәлеген гаҗәеп нечкә күзәтүе, тыгыз фикерле юлларга сыйдыра.

«Шагыйрьләр хакында сүз чыкканда, гадәттә, ул поэзия өчен яши, диләр. Х.Туфанны исә мин, ул үзе шигырь булып яши, дияр идем. Чөнки Туфанны шигърияттән, шигърияттне Туфаннан башка күз алдына китерүе мөмкин түгел. Х.Туфан поэзиягә аяк басуы белән яңа сүз әйтте. Ул сүз осталарының берсенә дә охшамаган...»

Аксакалыбыз сүзләренә якын фикерне Р.Зәйдулла тирән мәгънәле бер метафорага сыйдыра: «Чын шигырьгә әверелә шагыйрь»... Өстәмә аңлатуны таләп итми торган таяныч нокталары күңел түрендә, «уч төбендә»: Тукай, Җәлил, Мөдәррис һәм, әлбәттә инде, Туфан.

Учлап-учлап шигырь өләшәләр,
Һәрбер кулда – купшы гөлләмә.
Ә чын шигырь –
Туфандагы сыман –
Сөрелүләр белән түләнә.

Туфанның вафатыннан соң, инде каләмен чарлап, төрле жанрларда үз өслүбен тапкан, интеллектуал шагыйрь тарафдары буларак танылган Р. Зәйдулла яңадән остазының образына, иҗатына мөрәҗәгать итеп, лиро – эпик жанрның катгый таләпләренә җавап биргән. Әлегә үзенең иң затлы иҗат җимешләреннән берсе – «Койрыклы йолдыз» поэмасын бастырып чыгара. Символик-психологик мәгънәгә ия әсәрендә шагыйрь укучысын Туфан феномены турында бергәләп киңәш-табыш итәргә, уйлашырга чакыра, аның тормыш юлы кебек иҗат методы, шигъри алымнары тәфсилле шәрехләүне сорап тора, дигән фикер уздыра.

Шагыйрьнең ошбу әсәре, гомумән, иҗаты турындагы уй-фикерләремне, ул шактый еллар хезмәт итеп, шаян да, уйга салучан да «Зәйдулла каланчасы»н алып барган «Идел» (2022, №1) журналында бәян иткән идем. Бу очракта «Койрыклы йолдыз» әсәренең сюжет канвасы үзәгендә шәхси риваять-истәлекләр ятканны гына искә төшереп үтәм. Шул чорның гаярь тәнкыйтьчесе Р.Мостафин «Хәсән Туфан» исемле мәкаләсендә, олуг шагыйребез белән очрашуда катнаша алганнарны «бәхетле студентлар», дип атый һәм яшьләр алдында чыгыш ясаганда Хәсән абыйның үзгәреп, яшәреп китүен искәртә.

Казан дәрелфөнүненең татар филологиясе бүлегендә 1956-1961 елларда укыган студентлар әле генә тоткынлыктан котылып кайткан шагыйрь, легендар шәхес Х.Туфан белән очрашу кичәләренә алданрак килеп (ул чорда Язучылар берлеге Бауман урамының иң затлы бинаһарының берсенә урнашкан иде), урын алып, күзләребезне чекрәйтеп, авызларыбызны ябарга да онытып, еш кына соңрак килгән өлкәннәргә урыннарны бушатып, рухланып, әсәрләнеп, дөньябызны онытып, шагыйрьнең һәр сүзен, кафиясен, чагыштыруын хәтергә сеңдереп тыңлаганнарыбыз бүгенгедәй күз уңында тора.

Х.Туфан белән очрашуда утырган «бәхетле студентлар»ның хәзер дә, иншалла, исәннәре бар – фән докторлары, күренекле галимнәр Илида Бәширова, Фәрит Юсупов, Аяз Гыйләҗевнең турылыклы хәләл җефете Нәкыя ханым, күптән түгел арабыздан киткән шагыйрь–мулла Равил Сәйфетдиновлар залда утырган олуг язучыларыбыздан узып, кул күтәреп сорау бирергә җөрьәт итмәсәк тә, «Туфан абый (Хәсән дип эндәшүне аны «түбәнәйтү», ягъни «җиргә төшерү» дип уйладык, күрәсең) «зинһар, шигырьләрегезне күбрәк укыгыз әле», дигән үтенечебезне кәгазьгә ышанып җибәрүебез хәтердә. Өлкәннәрне күбрәк «тегендәге» яшәү – «яшәмәү» шартлары, сәяси мәсьәләләр, милли мөнәсәбәтләр борчый иде. Шыгрым тулы залны берләштергән уртак хис: бар авырлыкларны җиңеп, рухын, халкына ышанычын саклап кала алган олы шәхес белән озаграк бергә булу иде. Шунда алган җылылык, бер милләт балалары булуыбызны сиземләү, бөтен залны берләштергән татарлыгыбыз бик озакка сакланды.

Туфан иҗаты татар сүз сәнгатенең югары бер үре, ә шәхесе гаҗәеп бер феномен булып күңелләребез түренә кереп калды. Минем киләчәк фәнни-гамәли, гыйльми-тәнкыйди язмышым Х.Туфан иҗаты белән бәйле булачагы турында хыялланa да алмадым ул чорда. Аны хәтеремдә калдыру өчен кат-кат күрүнең ихтыяҗы да юк иде. Миңа ул «минем студент чорымдагы Хәсән абыем».

Иң әүвәл, аның озынча чандыр гәүдәсе һәм дөньяның ак тынлыгын сеңдергән нәзакәтле сыны истә калган. Йөзе шикелле үк ап-ак чәчен күңел аклыгы тышландыра сыман. Шигырьләрен укыганда, сүзләреннән мәрхәмәтлелек, кешеләргә чиксез мәхәббәт саркылып тора. Чигәләре, тормыш басымына бирешеп, эчкәрәк кергән. Аның караве, «кирәкне биргән дөнья» хәлләренә үч итеп, «дуфанлыгы» баш түбәсенең очын өскәрәк калкыткан. Кабарынкырак иреннәре хуҗаларының сабырлыгына ишарә итеп, хәбәр биреп торса, шактый алга чыгып торган ияге аның тормыш сынауларына баш бирмәстәй ихтыярлы кеше, ир-егет булуына җисми дәлил кебек иде. Бөтен маңгае буйлатып сызылган тирән сырлар шагыйрь узган чорларның «шаһитлары» буларак кабул ителде. Дусты Такташ белән ярыша-көнләшә иҗат иткән егерменче елларның үз сызыгы. Көтелмәгән афәте белән килгән утызынчы еллар үз «буразнасын» тудыра. Бөтен халык, ил фаҗигасен һәркем шәхси язмышы аша уздырган кырыгынчы еллар үз сырын өсти. Аларны илленче, алтмышынчы, җитмешенче еллар сызыклары «дәвам» иттерә.

Бездән соң килгән буын студентлары да Туфанны күреп, ишетеп калу хыялы белән яшәгән икән. Һәм Р.Зәйдулла «Койрыклы йолдыз» поэмасында бәян иткәнчә, хәзерге сүз сәнгатебезнең әйдаманнары – 80 нче елларның икенче яртысы шәкертләре – үҗәт әрсезлекләре беләнме, исән имин чакта аның фатихасын алып калу хыялына бирелепме, яисә халык әйтемендәгечә, «башларын җүләргә салып»мы – Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон, Газинур Моратлар Х.Туфан янына дәвалану йортына ук килә. Бар тоткарлауларны үтеп, Хәсән абый бүлмәсендә шигърият, милләт язмышы турында гәпләшеп, сүз-фикер алышу бәхетенә ирешәләр. Бу өч егетнең хәзерге житди иҗади казанышларын күз уңында тотып, әлеге «партизаннарча» очрашу аларда җаваплылык тойгысын «куертып», талант бөреләрен ачып җибәргәндер дип фаразлыйм. Зәле авыр булуга карамастан, Х.Туфан әлеге «әрсезләр» йөзендә дәвамчыларын күреп, аларны аска хәтле озата төшә, татар студентлары белән очрашуга килүгә вәгъдә бирә һәм, табигый ки, сүзендә тора. Бу мизгелне Зәйдулла «Койрыклы йолдыз» поэмасында ифрат ямьле шигъри энҗеләргә тереп бирүгә ирешә.

Йолдыз нуры җыйган
күзләреңдә
Таң гөленең чыгы сирпелгән.
Нинди уйлар били сине,
шагыйрь?
Нигә күз карашың биртелгән?

(Дәвамы 5 нче биттә).

АХЫРЗАМАН АЛЫШЫ

Ахырзаман турында сүз барганда, күпләр аны ничектер гадиләштереп, дөньяның бетү вакыты, дип кенә белә. Хәтта дин әһелләре дә кайчак, Кыямәт көне белән бутап, Исрафил фәрештәнең ике тапкыр сур (быргы) өрүе һәм барча үлекләрнең, каберләреннән кубарылып чыгып, Аллаһ каршында җавап тотуы, дип кенә аңлый һәм аңлата. Әмма Ахырзаман Коръәнгә кадәрге изге китапларда да телгә алынган (Армагеддон, «Битва Конца» h.б.). Аларда ул, «Изге Җир» тирәли «яңа күк йөзе»нә кадәр 30 еллап алдан булыр, дип әйтелә. Коръәндә дә Ахырзаман галәмәтләре Кыямәт көне алды яшәеше итеп бирелә. Әмма изге китапларда ул төшенчәләргә эзотерик (тирәнрәк, яшерен) мәгънәләр салынуын да онытмыйк. Шуңа күрә Коръәндә язылганнарны да ислам метафизикасы (Мәңгелек һәм тәҗрибә үткәреп булмый торган илаһи башлангычларның даимилеген таный торган фәлсәфи тәгълимат) югарылыгында аңлау таләп ителә. Әйтергә кирәк, ишетә белгәннәр өчен «Сур быргысы» инде икенче кат та хәбәр бирде. Әйе, кешелек цивилизациясе өчен, хактан да, җавап тоту вакыты җитте. Комсызлыгы, мәнсезлеге вә ваемсызлыгы белән ул Җирдәге яшәешне шул дәрәҗәгә җиткезде ки, аның үз килачәге дә реаль куркыныч астына куелды. Кайчандыр оҗмахтан куылган адәми зат, үз әхлагын, аңын һәм яшәү рәвешен илаһият кануннарына туры китереп үзгәртмәсә, Җирдән дә куылырга мөмкин.

Ислам метафизикасы буенча, Аллаһ әле яралтылышта ук кешегә Җир хуҗасы булу бурычын йөкләгән. Шуңа күрә аңа, башка тереклек ияләреннән аермалы буларак, акыл биргән. Әмма ул хайвани инстинктлардан да мәхрүм ителмәгән. Аның өчен фанилыктагы сынауның фәлсәфи мәгънәсе хайвани яшәештән рәсүли аңга кадәр үсеп җитүдә чагыла. Аллаһ бәндәләргә табигый байлык һәм аннан файдалану мөмкинлеген дә мулдан биргән. Чикләмәгән. Хәтта диннәрне дә, аң-белем дәрәҗәсенә һәм милләт булып яшәү рәвешенә туры китереп, сайлап алу мөмкинлеге калдырган. Шуның белән бергә, яралтылышта ук яшәешнең барлык өлкәләрендә дә илаһият законнары урнаштырылган. Адәми затка исә, үз тәҗрибәсеннән чыгып һәм акыл мөмкинлекләрен дә эшкә җигеп, язылмаган ул законнарны (илаһият кануннарын) ачыклау һәм серләренә төшенү мөмкинлеге бирелгән. Аларның ачыкланган өлеше «фән» дип атала. Тик кеше, атом серләрен ачып, инде ясалма интеллект турында лаф орса да, илаһият кануннарының әле бик аз өлешен үзләштергән.

Аллаһ кануннары исә кешенең әдәп-әхлак ягын да, аларга тәңгәл җәмгыяви яшәеш вә үсеш рәвешен дә билгели (адәми зат өчен болары әле, мөгаен, мөһимрәкләр дә). Шуның белән бергә, аны азындыру, коткы салу һәм хак юлдан яздыру өчен, Раббыбыз Җиргә иблисне дә җибәргән. Зурдан алганда, кешелек тарихы ул – адәми затның иблис белән көрәше һәм хак юлга омтылу тарихы да. Тик, ни кызганыч, кеше белән әле бүген дә иблис токымы идарә итә. Ул аның әхлагын җимерә, сугышлар китереп чыгара, комсызлык вә мәнсезлегенә таянып, һәр җирдә мәкерле гамәл кыла. Эш инде төп халыкларны туган җирләрендә туган телдә белем алудан һәм тулы хокуклы яшәү рәвешеннән мәхрүм итүгә кадәр дә барып җитте. Көн туды исә, кеше аңы гаммәви дәрәҗәдә иблис коткысына дучар ителә. Ошбу мәкерле эшкә, сәясәт вә икътисад кына түгел, суд системасы, мәгариф һәм хәтта парламентлар да җәлеп ителгән. Бүген инде тоталь дәрәҗәдә, караны – ак, акны кара, дип тәкрарлау бара. Бу яктан, иҗтимагый аңда хәзер «Ахырзаман алышы» да, югары рухи омтылыш вә әхлак белән, иблис коткысы арасында аяусыз көрәш рәвешендә бара.

Аңлашыла ки, кешелек цивилизациясенең киләчәге ошбу рухи алышта өстенлеккә кем ирешүенә бәйле булачак. Шуңа бүген төп сорау да: «Адәми зат Аллаһның Җирдәге сынавын уңышлы үтә алырмы?», – шәкелен ала. Яңа дөньяви тәртип тә шуннан чыгып билгеләнәчәк. Аерым халыклар яки илләр генә түгел, цивилизацияләр һәм хәтта кешелек язмышы үзе дә хәзер шуңа бәйле. Әлбәттә, бүгенге глобаль процессларда турыдан-туры катнашкан халыклар вә цивилизацияләр ниндидер өстенлекләргә дә ирешергә (әйтик, аларның телләре «төбәк теле» статусы алырга, яисә ниндидер башка преференцияләр бирелергә) мөмкин. Ә цивилизацион үсеш кагыйдәләрен инде җиңүчеләр билгеләячәк. Тик алар нинди генә юнәлеш алмасын, илаһи чишелеш Аллаһ кодрәте белән кылыначак.

Фоат УРАЗАЙ.

«Йолдызлык» йолдызлар үстерә

mincult.tatarstan.ru

Пушкин мәдәният үзәгендә «Созвездие-Йолдызлык» арт-резиденциясенең беренче театр сезонын ябу тантанасы узды. Театрның яшь артистлары – Н.Җиһанов ис. Казан дәүләт консерваториясен, ГИТИС һәм илнең башка иң яхшы иҗади югары уку йортларын тәмамлаучылар белән сезон буе Россия һәм Татарстанның танылган сәхнә осталары эшләде. Ил өчен аеруча икътисади яктан катлаулы вакытта коллектив тарафыннан өстәмә финанслаудан башка 11 спектакль куелды.

Татарстан яшьләр эшләре буенча министр урынбасары Софья Мостафина билгеләп үткәнчә, арт-резиденция бинасында күптән түгел янгын булуга карамастан, театр эше дәвам итәчәк. Тикшерү эшләре, бинаны торгызу һәм зыянны бәяләү вакытында репетиция һәм спектакльләр күрсәтү шәһәрнең төрле театр мәйданчыкларында узачак. Хәзер труппа яңа сезон премьерасын - «Кызлар-матурлар» мюзиклын әзерләү өстендә эшли.

«Созвездие-Йолдызлык» республика үзәгендә бу спектакльнең күрсәтмә репетициясе узды. Ул Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев пьесасы буенча куелган. Спектакль пьесаның Рәшит Заһидуллин һәм Елена Аржакованың иркеле тәрҗемәсендә рус телле адаптациясе булып тора.

Спектакльне сәхнәләштерергә Р.Заһидуллин алынды. Быел аның җитәкчелегендә «Созвездие-Йолдызлык» арт-резиденциясендә «Ерак йолдыз яктысы» спектакле куелган иде.

«Кызлар-матурлар» спектаклендә миңа Разил Вәлиев әсәрләрендә булган татар халык зирәклеген һәм рус мәдәнияте контекстында Көнбатыш Европа музыкасын берләштерү бик кызыклы тоелды. Дөресен әйткәндә, мондый тәҗрибә җиңелләрдән түгел. Ләкин әлегә нәтиҗәләр турында сөйләргә иртәрәк - бүген безмондый симбиозның туу процессын гына күзәтәбез», – дип белдерде режиссер.

«Әгәр дә мин үз вакытында мондый спектакльләрне күргән булсам, минем шәхес буларак үсешемә бу зур ярдәм булыр иде. Мондый тамашалар ярдәмендә 16-17 яшемдә мин үземне кызлар белән ничек танышырга, алар белән үзеңне ничек тотарга һәм аларга хисләремне ничек белдерергә икәнен күптән өйрәнер идем. Моңа мәктәптә өйрәтмиләр бит. Бу спектакльдә әлеге темаларның катлаулы театр алымнары аша бирелмәве, тупас акыл өйрәтү булмавы бик шәп. Хәзер бөтен җирдә экспериментал театрлар эшли, ләкин алар рәтендә «Кызлар-матурлар» – ул саф һава сулаган кебек», – дип фикерләре белән уртаклашты арт-резиденция директоры Дмитрий Туманов.

«Музыкаль номерлар һәр герой өчен махсус язылган. Музыка персонажларның характерларын дөрес аңларга булышсын дип тырыштык. Минемчә, бик үзенчәлекле хезмәт барлыкка килде, мондыйны Казанда минем күргәнем юк. Артистлар алдында катлаулы бурыч – алар актерлык осталыкларын да, музыкаль талантларын да берьюлы кулланырга, аларны берләштерергә тиеш», – дип билгеләп үтте композитор Юрий Чаплин.

Кыска да, эчтәлекле дә

Abau студиясе күренекле режиссёр Марсель Сәлимҗановка һәм язучы Фатих Әмирханга багышланган анимацион роликлар чыгарды. Анимация роликлары циклы Мәдәният министрлыгының социаль челтәрләренә урнаштырылган. Киләчәктә мәгърифәтче Фатиха Аитова, «Яңалиф» язу машинасы уйлап тапкан Әскәр Шейх-Алига багышланганнары дөнья күрергә тиеш.

Әүвәлрәк әлеге студия Илһам Шакировка һәм Салих Сәйдәшев белән Кәрим Тинчурин тандемына багышлаган роликлар тәкъдим иткән иде.

Роликлар барысы да өч телдә – татарча, русча һәм инглизчә әзерләнә. Видеоларны эшләгәндә, авторлар язучы Рабит Батуллага, Казанда исәпләү техникасы тарихы музеена, Татарстан Милли музеена, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына, Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә, «Җыен» фондына һәм геройларның туганнарына мөрәҗәгать иткәннәр.

Анимацион роликларда актриса Лилия Нурель, Taraf төркеме солисты Булат Шәйми, шагыйрә Миләүшә Гафурова тавышы яңгырый.

Корбан бәйрәме дә заманча

Иртәгә, 9 июльдә, мөселманнар иң зур бәйрәмнәрнең берсен – Корбан бәйрәмен билгеләп үтәчәк. Казанда мәчетләргә бәйрәм көнендә автобусларда барып җитәргә мөмкин була. Бәйрәм чаралары 2:30 сәгатьтә Коръән уку белән башлана. Корбан чалу йоласы өч көн дәвамында – 9, 10 һәм 11 июльдә була. Моны махсус билгеләнгән 17 урында башкарырга мөмкин булачак.

Әлеге чараны оештыручылар тарафыннан санитар-эпидемиягә каршы чаралар да каралган, мәчетләр территориясендә биокалдыклар өчен махсус контейнерлар урнаштырылачак, ә барлык хайваннарның тиреләрен Тольяттидагы мех фабрикасына озатачаклар, дип сөйләде Казан Башкарма комитеты аппаратының Җәмәгать оешмалары белән хезмәттәшлек итү бүлеге башлыгы Илнур Шакиров.

10 июльдә Казанда М.Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркында «Корбан Фест» зур гаилә фестивале узачак. Бәйрәм Вахитов һәм Идел буе районнары мөхтәсибәте тарафыннан бишенче тапкыр уздырыла. Аның төп темасы Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу белән бәйле булачак.

Оештыручылар әзерләгән бәйрәм программасы көндезге сәгать бердә башлана һәм кичке сәгать бишкә кадәр дәвам итәчәк. Кунаклар бөтен бәйрәм буена гаилә белән күңел ача алачак: алар өчен осталык дәресләре, балалар, әниләр һәм әтиләр өчен актив уеннар, күргәзмәләр, фотозоналар, сабын тамашасы, фәнни шоу, аквагрим һәм башкалар әзерләнә.

Казанда корбан чалу урыны әзерләнгән мәчетләр.

Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары: «Казан нуры», «Салихҗан», «Фатиха» мәчете; Вахитов һәм Идел буе районнары: Мәрҗани, Апанай, «Тынычлык», «Гадел», «Ризван» мәчете, «Корбан-бәйрәм» корбан чалу комплексы (Бертуган Петряевлар ур., 6); Киров һәм Мәскәү районнары: «Рамазан», «Мәүлид», «Әхмәдзәки», «Рәҗәп» мәчете; Совет районы: «Билал», «Куддус», «Иман нуры» мәчете, «Бистә нуры Габделгаллә» мәчете.

1 нче биттә – Болгарда ислам динен кабул итүнең 1100 ел тулуны бәйрәм иткәндә укылган бәйрәм намазы күренеше. Фото: president.tatarstan.ru

Гөрләде Сабан туйлары

XII Бөтенроссия авыл Сабан туе быел Мордовиянең Ләмбрә районы Аксюн (Аксеново) авылында узды. Бәйрәмдә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Мордовиягә Сабан туенда катнашу өчен Россиянең 24 субъектыннан: Ульяновск, Оренбург, Пенза, Әстерхан, Самара, Түбән Новгород, Новосибирск, Чиләбе, Төмән, Ростов өлкәләреннән, Башкортстан, Чуашия, Марий Эл, Удмуртия, Бурятиядән, Пермь краеннан һәм башка төбәкләрдән рәсми делегацияләр килде, әлбәттә, иң зур делегация Татарстаннан иде.

Рөстәм Миңнеханов Бөтенроссия авыл Сабан туеның югары дәрәҗәдә оештырылуын билгеләп үтте. Ул Мордовия башлыгы Артем Здуновка, бәйрәмне уздыруда өлеш керткән казанлылар һәм Татарстан районнары вәкилләренә рәхмәт белдерде. А.Здунов ассызыкланганча, Бөтенроссия авыл Сабан туе – Россия халыкларының мәдәни мирасы еллының һәм Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуның иң мөһим вакыйгаларыннан. Сабан туе мәйданында концертлар, күргәзмәләр, бию флешмоблары, спортның милли төрләре буенча спартакиада оештырылды. Авыл хуҗалыгы техникасы күргәзмәсе дә бар иде.

Р.Миңнеханов һәм А.Здунов милли ишегалларында һәм ярышлар мәйданчыкларында булды, шул исәптән билбау көрәше буенча бөтенроссия ярышларын һәм традицион уеннарны карады, Кукмара районының масштаблы экспозициясе белән дә танышты.

Сабан туеның абсолют батыры исеме өчен Булат Мусин белән Раил Нургалиев көрәште. Җиңү яулаган Р.Нургалиев Татарстан Президенты бүләген – «Лада» машинасы ачкычларын Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров кулыннан кабул итеп алды.

Юртак токымнары чабышларында җайдак Илсур Галимҗанов Вернблум Аш кушаматлы ат белән җиңүче булды. Малның хуҗасы – Рәмис Айзатуллов. Җиңүчеләргә төп приз – «Лада» машинасын Мордовия башлыгы Артем Здунов һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тапшырды.

Чабышта Татарстан, Мордовия, Чуашия республикаларыннан, Пенза өлкәсеннән килгән атлар һәм җайдаклар көч сынашты. Җайдаклар арасында ир-атлардан тыш, гүзәл зат вәкилләре дә бар иде.

Быел Аксюн авылы янындагы кырда 520 тамашачыга исәпләнгән трибуналы махсус ипподром корылган иде.

Чираттагы Бөтенроссия авыл Сабан туе 2023 елның 20 маенда Әстерхан өлкәсендә узачак. Мордовия башлыгы А.Здунов Бөтенроссия авыл Сабан туе символы «Тулпар ат»ны Әстерхан өлкәсе вице-губернаторы Павел Паутовка тапшырды.

Узган ял көннәрендә Сабан туе күп төбәкләрдә узды. Свердловск өлкәсендә эш сәфәре белән килгән Р.Миңнеханов якшәмбе көнне өлкә Сабан туен карады. Аны өлкә губернаторы Евгений Куйвашев озата йөрде. Кыр бәйрәме Кадниково авылында уздырыла. Аны Татарстан Республикасының даими вәкиллеге һәм Лаеш районы ярдәме белән «Свердловск өлкәсе татарлары конгрессы (Урал татарлары)» төбәк иҗтимагый оешмасы оештыра.

Җәйнең июль ае башланганда Сабан туен Кыргызстан Республикасында да бәйрәм иттеләр. Ул Каракол шәһәрендә «Каракол – Берләшкән Дәүләтләр Бердәмлеге мәдәни башкаласы» халыкара программасы кысаларында узды. «Без бергә! Безнең көч – бердәмлектә!» девизы белән әлеге бәйрәмдә Кыргызстанның барлык этник төркемнәре һәм татар иҗтимагый оешмалары катнашты.

Бәйрәм Караколның күпмилләтле булуын чагылдырган бию флешмобыннан башланды. Анда татарлар, кыргызлар, руслар, уйгурлар, казахлар, үзбәкләр һәм башка милләт вәкилләре катнашты.

Кунакларны Каракол шәһәре хакимиятенең этник мәсьәләләр буенча җаваплы сәркатибе К.Азизов сәламләде. Үз чыгышында ул Караколда яшәүче татарларга һәм барлык халыкларга шәһәрдә милләтара бердәмлекне саклаган өчен рәхмәт белдерде.

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының чит илләрдәге татар иҗтимагый оешмалары белән эшләү бүлеге баш референты Г.Нигъмәтуллина Татарстан Президенты Р.Миңнехановның Сабан туе уңаеннан котлавын укыды.

Иманлы академикны искә алдылар

Чуаш дәүләт университетының Гыйльми советы залында академик Хәбиб Миначев истәлегенә багышланган түгәрәк өстәл узды. Ул Идел буе Болгар дәүләтендә ислам кабул ителүгә 1100 еллыгын бәйрәм итү чаралары кысаларында үткәрелде. Форумны Чуашия Мәдәният, милләтләр эшләре һәм архив эше министрлыгы ярдәмендә Чуашия мөселманнары Диния нәзарәте, Ульянов исемендәге Чуашия дәүләт университеты оештырды.

Түгәрәк өстәл эшендә дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган мәгариф һәм фәнни-тикшеренү учреждениеләре, дини оешмалар вәкилләре, галимнәр һәм экспертлар, җәмәгать эшлеклеләре, педагогик хезмәткәрләр, студентлар катнашты.

Россия мөселманнары Диния нәзарәте башлыгы, Чуашия мөфтие Әлбир хәзрәт Крганов сүзләренчә, уку елы тәмамланган киеренке вакытта университет җитәкчелеге Чуашия мөселманнары Диния нәзарәтенең Батыр районы Кыр Бикшеге авылында туып-үскән академик Хәбиб Миначев истәлегенә фәнни чараны уздыру турындагы тәкъдимен кабул итте. Ул – Чуашияне органик химия өлкәсендә үзенең идеяләре һәм ачышлары, фәнгә хезмәте белән танылган шәхес.

Мөфти ислам диненең дә белем алу мәсьәләсенә һәм кеше тормышында гыйлемнең мөһим роленә зур игътибар бирүенә басым ясады. Әлбир хәзрәт шулай ук хәзерге заман шартларында кайбер гуманитар дисциплиналарны укытып, илебез дини мәктәбен үстерү аша ислам мәгарифенең бербөтен системасын формалаштыру процессларының уңышлы баруын да искәртте.

● Кытай армиясе карамагында һәркайсы 100 әр граммга кадәр йөк күчерергә өйрәтелгән 10 мең почта күгәрчене бар. Алар, сугыш башланып, башка барлык элемтә чаралары гамәлдән чыккан очрак өчен асрала.

● Боснијадә 72 яшьлек ир-ат тәрәзәдән гел төрле күренеш күзәтергә теләгән хатыны өчен әйләнә торган йорт төзегән. Ир хатынының зарлануыннан, очсыз-кырыйсыз ремонттан туйган һәм әлеге төзелешкә 6 ел гомерен сарыф иткән. Иң акрын тизлегендә йорт үз күчәре тирәсендә бер тәүлектә әйләнеп чыга, иң тизендә – 22 секунд эчендә.

● СССР Фәннәр академиясенең Ярымүткәргечләр институты директоры академик А.Иоффе (1880-1960) 30 миллион санлы логарифмнар таблицасын хәтерендә тоткан.

Хәсән Туфанны юксыну

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Шигырьләре, үзен тотышы белән яшьләр күңеленә иман нуры, матурлыкка мәхәббәт иңдергән Туфан соңгы сүзен әйтергә әзерләнә.

Ахырдан үзе торып басты...

Залда – яшьләр.

Утны-суны кичкән, 1928/1929 елларда Кавказ, Урта Азия якларында җәяүле сәяхәттә йөргәндә дә, 1940-1956 елларда тоткында чакта Себер суыкларына бирешмәгән, тәрәзәдән аңа карап торган үгезне «җылы сүзе», ипи кисәге белән тынычландыру әмәлен тапканда да Хәсән хәзрәтләре болай ук дулкынланмагандыр. Ә бүген аның йөрәге сыкрый, саубуллашу мизгелләре әрнетә, җанын талый, әйтер сүзләрен оныттыра... Бу тантана милләт балалары белән шагыйрьнең дөньялыктагы соңгы очрашуы булгандыр. Җитмәсә, киеренкелекне арттырып, кызлар гаҗәеп элегик, моңсу «Казан кичләре»н җырлап, Тукаебыз әйтмешли, күз яшьләре белән битләрен энҗели-энҗели, сөекле шагыйрьләре белән саубуллаша.

Хастаханәдә янында булган егетләр Туфанны соңгы юлга озатуда, җәсәден җир-анабызга тапшыруда да катнаша һәм аның рухына, васыятьләренә, шигъри үренә турылыклы калырга тырышып иҗат итә!

Минем Х.Туфан белән якыннан истәлекле вә эшлекле очрашуым үткән гасырның җитмешенче еллары башында булды. Әлегәчә шагыйрьне күбрәк түрдәге өстәл янында яисә трибунада күреп, ара-тирә гомуми исәнләшеп, аның һәр яңа шигырен укып, үзен изгеләштереп кенә яшәсәм, көтмәгәндә-уйламаганда миңа фортуна елмаеп, бөек шагыйрьләребез белән якынайтып, күпмедер күләмдә дуслаштырып куймасынмы? Мин инде байтактан Алабугада яшәп, 1971 елдан шунда урнашкан педагогика институты ректоры вазифаларын үтәп, урыс купецлары каласына татар рухын сеңдерү, милли бүлекләрне үстерү юнәлешендә җан атып эшләп ятканда, тормышымда иң мөһим вакыйгаларның берсе булды: Татарстан китап нәшрияты җитәкчелеге мине чакырып алып, рәсми рәвештә, Х.Туфанның ике томлыгына эчке рецензия һәм монографик рухтагы кереш мәкалә язуны тапшырды. Сәбәбе үземнең әдәби тәнкыйть өлкәсендә артык «әрсезләнеп» китүемдәдер, дип уйлыйм. Шул чорда исемнәре, иҗат җимешләре халык теленнән, матбага битләреннән төшмәгән С.Хәким, Г.Афзал, Ш.Галиев, И.Юзеев, аларга 60 нчы елларда килеп кушылган Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Р.Мингалим, З.Мансуров, Г.Рәхим һ.б. иҗатларына багышланган мәкаләләремнең даими басылып торулары да этәргеч биргәндер яисә берәрсенең бу җегеткә «җитдирәк» эш кушып, сынап карыйк әле үзен, дигән булуы да ихтимал.

Әлбәттә, мөстәкыйльлеге белән хакимиятнең саруын кайнаткан Х.Туфан кебек олуг шагыйрьгә бәя бирү, бигрәк тә аның тәүге сайланмаларына кереш сүз язу сөенечле булса да, күтәрә алмаслык йөкне җилкәңә салмыйсыңмы дип шикләндерген, уйландырып та куярлык иде. Бигрәк тә Г.Нигъмәти, (1929), С.Хәким (1958), Х.Госман (1964), Н.Юзиев (1969), Г.Бәширов (1974) кебек бөекләребез аның бай һәм нечкә зәвыклы иҗатына әтрафлы бәяләрен биргән. Соңрак исә аның мирасын фәнни-гамәли шәрехләүгә Ә.Еники, М.Кәрим, Р.Мостафин, М.Гайнетдинов һ.б. үз өлешен кертте. Акрынлап шагыйрь иҗаты төрки дөньяда һәм рус матбугатында да таныла башлый. Аның җыентыклары үзебездә генә түгел, «Советский писатель», «Художественная литература», «Современник» кебек Мәскәү нәшриятларында басылып чыгып, уңай бәяләр алды.

● Сәйфи Кудаш, Хәсән Туфан, Мостай Кәрим.

Кыскасы, нәшрият тәкъдименә сөенсәм дә, каушабрак калуымны сиздермәскә тырышып, «булдыра алырмынмы икән» диебрәк, ыкы-мыкы килеп утырган хәлдә, шул чорның нәшрият директоры Гарәф Шәрәфетдинов бүлмәсенә Хәсән абый үзе килеп кермәсенме? Әүвәл кабинет хуҗасы белән исәнләшкәннән соң, минем якка борылып, күптәнге танышын очраткандый:

– Нихәлләр, энекәш! Сез минем якташ та икәнсез әле, – дип гади генә итеп кулын бирде.

Шуннан соң, беркадәр гомуми сүзләр белән фикерләшеп алгач, томнарның төзелеше, бүлек исемнәре турында сөйләшеп утырдык. Басманың төзүчесе шагыйрь мирасын өйрәнүгә зур көч куйган, төрмә, КГБ архивларына хәтле үтеп кергән Мәсгуд Гайнетдинов һәм гаҗәп җаваплы «хәреф чыпчыгы» – Рәис Даутов редакторы булган Туфан тупламасының югары сыйфат дәрәҗәсендә басылып чыгуында шик-шөбһә булуы мөмкин түгел иде.

Х.Туфан шигъриятенең сайланмаларына бәя бирүгә алынуымның янә бер сәбәбе бар иде: агымдагы татар поэзиясенең халык иҗаты белән күп яклы сәнгати бәйләнешләрен, бер-берсенә тәэсирен өйрәнеп, 1968 елда якланган кандидатлык диссертациямнең нәзари һәм гамәли терәге булып Х.Туфан белән С.Хәким иҗатлары торды (соңрак бу хезмәтем «Илһам чишмәләре» исемендә Татарстан китап нәшриятында басылып та чыкты. 1988).

Сүз дә юк, Туфанның бөтен иҗатын иңләп, томлыкларын ачып җибәргән кереш мәкалә аның югары кимәлле шигъриятенә лаек булырга тиеш иде. Мин әүвәл аның бөтен язганнарын кульъязмалардан, басылган китапларыннан кат-кат чагыштырып, купшы хисләргә бирелмичә, саллы хезмәт язгандай булдым, ягъни Ходай Тәгаләбез биргән бар рухи көчемне биреп иҗат иттем. Язмаларым Хәсән абыйның үзенә дә ошагандай тоелды. Әллә минем күңелне күрү өчен генәме, мәкаләнең соңгы юлларын кат-кат карап чыкканнан соң,«минем бөтен иҗади тормышым шул өзеккә сыйган кебек», диде ул мәгънәле итеп һәм тавышын күтәрмичә генә.

Җыентык күптән басылып чыгып, таратылып, биобиблиографик истәлек булып калганга күрә, укучыны әлеге юллар белән таныштырып үтәргә булдым. «Сәлам сиңа, тормыш!» – ди шагыйрь мәгърур тавыш белән һәм, чал чәчләрен артка ташлап, яшьләрчә дәртле вә фәлсәфи уйчан күзләрен ерак-еракларга юнәлтә... Йөзендә бәхет нурлары кабына. Замана турында, кешелек турында уйлый ул. Аннары ак кәгазьгә яшел кара эзләре төшә башлый. Димәк, тагын бер яңа шигырь туып килә. Хәсән Туфан илле елдан артык әнә шулай шигърият эчендә кайнап яши. Халык тормышы белән яши!»

М.Гайнетдинов, Р.Даутовлар бакыйлыкка күчкәнче, Х.Туфанның җыентыклары даими нәшер ителеп, иҗатына бәяләр әйтелә торды. Әмма хәзергесе көндә үзен аның мирасын өйрәнүгә багышлаган галимне атый алмыйм. Шагыйрьнең лирикасын өйрәнүне фәнни мәүзуг итеп шәкертем, Х.Туфанның якташы Р.Сабировка биргән идем, ул кандидатлык диссертациясен язып, уңышлы яклады да, журналистикага бирелде, хәзер – «Шәһри Казан» мөхәррире. Татар мәктәпләре, югары уку йортларында милли бүлекләр кыскартылу сәбәпле, агымдагы әдәбиятны гына түгел, хәтта классикларыбызны өйрәнүче галимнәр сафы да елдан-ел сирәгәя бара. Бу хәл, табигый ки, рухи мирасыбызга игътибарны киметүгә алып килә.

Телебезне, гореф-гадәтләребезне, димәк ки, милли киләчәгебезне югалту куркынычы баш очыбызда эленеп торган бер чорда шул изге төшенчәләр өчен җан атып яшәгән, холыклары һәм тирән рухлы иҗатлары белән сокландырган шәхесләребезне тиешенчә олылый, исемнәрен саклый алу таяныч ноктасы булырга тиеш дигән фикер бәхәс уятмас кебек! Мәкаләдә әйтелгән теләк-фикерләрне истә тотып, мин Татарстан Мәгариф министрлыгы белән Язучылар берлегенә Хәсән Туфан исемендәге еллык әдәби премия булдыруны тәкъдим итәм!

Иншалла, әдәби үсешебезгә юнәлеш, дәрт, көч биреп торучы Һ.Такташ, М.Җәлил, Ш.Маннур, С.Сөләйманова кебек шагыйрьләребез исемендәге бүләкләребез бар. Шулай да, бар сәяси авырлыкларны, рәнҗетүләрне үз җилкәсендә кичерсә дә, рухын сындырмаган, каләмен кулыннан төшермәгән, тормыш-язмыш сөземтәсе – «Бирде дөнья киракне, еламаска өйрәтте», дигән гыйбарәсе өчен генә дә аның иҗаты премия булдыруга лаек һәм исемен янә бер билге белән мәңгеләштерү аның рухына дога булып та барыр иде. Премия һәр елны Туфан туган ноябрь (искечә) – декабрь (яңача) айларында бирелсә, үзенә күрә әдәби ел йомгакларының күрке дә булыр иде.

Атнаның сәяси мизгелләре

БӘХӘСЛЕ ҖИҢҮ

РФ саклану министры С.Шойгу ил башлыгы В.Путинга Украинада Россия кораллы көчләренең, Лисичанск каласын яулап, ЛНРны тулысынча азат итүләре турында рапорт бирде. Аның әйтүенчә, ике атнадан артык үткәрелгән операция нәтиҗәсендә, 25 торак пункт (Северодонецк, Золотое, Горское һ.б.) контрольгә алынган. Лисичанск өчен барган бәрелешләрдә Украина армиясе (ВСУ) 5,5 меңгә якын сугышчысын югалткан (шулардан 2,2 меңе – юк ителгән). Хәрби техникадагы югалтулары да зурдан (196 танк һәм бронемашина, 12 самолет, 65 очучысыз очкыч, 6 ЗРК, 97 РСЗО, 166 туп һ.б.) булган, шактый гына сугыш коралларын (39 танк һәм бронемашина, 11 туп һәм миномет) дошман әле ташлап та качкан икән. Әлбәттә, Россия президенты әлеге җиңүне югары бәяләде, аны яулаган сугышчылар ял итәргә һәм сугышчан мөмкинлекләрен яңартырга тиешлеге хакында да искәртте. Бу датаны ЛНР өчен бәйрәм көне итү турында да сүз булды.

Әмма бәйрәм рухына күләгәне дошман пропагандасы төшерде. «РИА Новости» агентлыгы язуынча, В.Зеленский офисы башлыгының киңәшчесе А.Арестович Лисичанск белән Северодонецкины калдыруны ВСУ тарафыннан үткәрелгән уңышлы операция, дип аңлата. Аның максаты – Россиянең төп көчләрен тоткарлап һәм таушатып, Көнбатыштан куелачак сугыш кораллары һәм икенче оборона сызыгын әзерләү өчен вакытны оту, фронтның башка участокларында һөҗүмгә күчү өчен шартлар тудыру булган. Кыскасы, ике як та үз максатларына ирешкән булып чыга. Әмма, гомумән алганда, мәсьәләнең ике як өчен дә фаҗигале ягы да бар: дөнья тотучыларның геосәяси ниятләрен гамәлгә ашыруда, ике яктан да бер үк халык «сәясәт коралы» һәм «туп азыгы» итеп кулланыла.

Мәгълүм геосәясәтче Г.Киссинджер Давоста ясаган чыгышын җәмәгатьчелек дөрес аңламавы турында белдерде. Украина һәм аның яклыларны Россия гаскәрләренә җимергеч җиңелү китерү омтылышыннан туктарга һәм, территориаль бәхәсләрдә юл кую хисабына, солых турында сөйләшүләрне башлап җибәрергә чакырганда, ул Кырым һәм Донбассны гына күздә тоткан, имеш. Аныңча, территориаль бәхәсләрнең кискенләшүе, идарә ителми торган нәтиҗәләргә дә китерергә мөмкин икән. Кыскасы, Украинада кризис һәм хәрби хәрәкәтләр озаккарак сузылган саен, четерекле сораулар да арта тора.

Фоат УРАЗАЙ.

Батырша илендә

Быел милли каһарманыбыз Батырша – Габдулла Галиевнең тууына – 305, вафатына 260 ел тула. Идел Болгарстанында ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үткәндә, шәһри Болгарда да Батырша хәзрәтнең исеме зурлап искә алынды, рухына дога кылынды. Бу эшләрнең башлап йөрүчесе Фәүзия Бәйрәмова булды. Моңа кадәр дә ул аның турында «Батырша җитәкчелегендә милли-азатлык көрәше» (2005), «Баһадиршаһ» (2006) һәм «Батырша явы» (2012) китапларын язып бастырган иде инде.

22-25 июнь көннәрендә Ф.Бәйрәмова тагын Батырша хәзрәтнең туган ягы – Башкортстанның Иске Балтач районында булып кайтты. Чараны оештыруда аңа Иске Балтач үзәгендә Батырша музеен төзеткән һәм аның директоры булып эшләүче, милли каһарманның нәсел дәвамчысы, Балтачтагы Батырша мәчетенең имам-хатыйбы, бөек Батырша явы һәм бу төбәктәге татар авыллары турында 7 китап язган Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаров ярдәм итте.

Очрашулар Батыршаның туган авылы – Югары Карыш мәчетендә башланды, соңыннан Иске Балтачтагы Җәмигъ мәчетендә дәвам итте. Язучы халыкка күренекле яу тарихын сөйләде, бу төбәктә ислам диненең сакланып калуында Батырша хәзрәтнең тоткан урыны гаять зур булуын аңлатты. Мең ел буе дәүләт тоткан татар халкының хәтта дәүләтсез калганда да иманны бирмәүләрендә аерым шәхесләрнең, бигрәк тә Батырша кебек дин әһелләренең, милли зыялыларның роле зур булуын әйтте. «Милләт алдында көчләп чукындыру афәте торганда да Батырша хәзрәт кебек каһарманнар, үз гомерләрен корбан итеп, динне саклап калган. Ислам диненең 1100 еллыгын билгеләп үткәндә дә без аларга бурычлы». Ф.Бәйрәмова татар халкының дин һәм ирек өчен гасырларга сузылган тиңсез көрәшен тарихи мисаллар белән сөйләде, соңыннан мәчеткә Батырша турындагы китапларын бүләк итте.

Очрашуларда авыл мөселманнары, Иске Балтач авылының Үзәк мәчете имам-хатыйбы Филүс Камалтдинов, Югары Карыш имамы Фәнәвил Габбасов та катнашты. Алар киләсе елга авылның 330 еллыгы булуын, шул уңайдан Югары Карышта Батырша хәзрәтнең нигезенә истәлек стеласы кую мәсьәләсен күтәрде, аны туристлар маршрутына кертергә теләкләре булуын җиткерде. Аллага шөкер, Югары Карышта урта мәктәп Батырша исемен йөртә. Тик менә Батырша хәзрәтнең нигез урыны ташландык, анда билдән үлән үсә. Батырша хәзрәтнең мәчете һәм мәдрәсәсе булган урында да бушлык. Ходайның рәхмәте белән мәдрәсәдән калган данлыклы китапханә бүген аның нәсел дәвамчысы Рәфис хәзрәттә саклана, ул борынгы китапларны Балтач музеенда күрергә мөмкин.

Янәшәдә генә Чуртанлыкүл. Бу – атаклы мишәр морзалары Янышевларның туган авылы, бу нәселдән чыккан биш ир туган төбәктәге тагын биш татар авылына нигез салган. Чуртанлыкүл элек мәчетле булган, тик бу авыл озак еллар мәчетсез яши. Рәфис хәзрәтнең зур тырышлыгы белән генә, элеккеге башлангыч мәктәп бинасы мәчет итеп үзгәртелә, бер бүлмәсендә авыл музеен ачалар. Җомга намазларын Иске Балтачтан килеп Йосып хәзрәт Исмаев укыта.

Район үзәге Иске Балтач Башкортстанның төньяк-көнбатышында, Пермь крае чигендә урнашкан, ул нигездә татар-мишәрләрдән тора, алар бергә Казан ханлыгы җимерелгәч, чукындырудан качып килә, монда Алтын Урда чорында яшәп яткан нугай татарлары янына сыена. Шуларның бер өлеше, Батырша хәзрәт кебек, динен-милләтен яклап, XVIII гасыр урталарында көчләп чукындыруларга каршы яуга күтәрелә, икенче өлеше, Яныш старшиналар кебек, патша хакимияте белән бергә аларны бастыра. Татарның зурлыгы да, хурлыгы да янәшә йөри. Элек шулай булган, ни кызганыч, хәзер дә шулай...

Ф.Бәйрәмова милләтебезнең шушы бөек һәм фаҗигале язмышын сөйләде, чукындыруга каршы күтәрелгән Батырша явының җиңелү сәбәпләрен аңлатты. Батыршаны үзебезнең мишәр-башкорт старшиналары тотып бирә, аны коткычы, дип, Петербургта хөкем итеп, телен, борынын кисеп алалар, маңгаена «вор» дип утлы тамга кыздырып сугалар һәм гомерлеккә Шлиссельбург кальгасына ябалар. Шунда дүрт елдан артык газап чигеп, үзен саклаган сакчыларның дүртесен балта белән бәреп үтергәч, Батырша хәзрәт үзе дә йөрәге ярылудан вафат була... Хатынын һәм кызларын чукындырып, монастырьга ябалар, сабый улы Уфадан Мәскәүгә озатканда, юлда катып үлә. Ислам юлында аның бөтен гаиләсе корбан була, әмма милләте исән кала. Батырша күтәрелешеннән һәм Пугачев яуларыннан соң куркуга калган Екатерина II дин ирегә турында фәрман чыгарырга мәҗбүр була. Шушы күтәрелешләр сәбәпле, башкортларга җир хокукы бирелә, мөселман татарлар чукынган татарлар өчен налог түләми башлый, керәшеннәр өчен рекрутка солдат бирми. Шул чорда Диния нәзарәте төзелә, мәчетләр салына башлый.

Әлбәттә, патшалар алмашыну белән, мөселманнарга караш тагын үзгәрә, көчләп чукындырулар шаукымы 19 гасыр буе дәвам итә, чиркәү кенәгәләренә элек керәшен дип язылган татарларның нәселе бер гасыр буе янадан исламга кайту өчен көрәшә. Бу хәлләр Ф.Бәйрәмованың «Гөләйза» романында да ныклап тасвирланган...

Батырша мәчете белән Батырша музее янәшә тора, аның белән музей директоры Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаров үзе таныштырды. Монда Ризаэддин Фәхреддиннән башлап, Габделбари Баттал-Таймас, Сәлам Алишев, Җәмит Рәхимов, Фәүзия Бәйрәмова, Мәсгуд Гайнетдинов, Фәйзелхак Ислаев, Вахит Имамов, башкорт язучыларының һәм галимнәренең дә Батырша турында хезмәтләре урын алган. Әмма бирелдә иң кыйммәтле ядкәр – Батырша китапханәсе. Ул 80 томнан тора, кайбер кульязма китаплар 500-700 битле. Монда Батырша хәзрәт үлгәч басылып чыккан китаплар да бар, алар аның мәдрәсәсендә тупланган. Мәрҗани институтыннан Казан галимнәре килеп, бу китапларның өлешчә тасвирламасын ясаган, әмма күпчелек кульязма китаплар һаман өйрәнелмәгән. Шулай ук Уфадан башкорт галимнәре дә килеп, бу китапханәне өйрәнгән, әмма аларның нәтиҗәләре билгеле түгел. Югыйсә, тулы бер фәнни институт еллар буе өйрәнерлек мирас! Шунысын да әйтергә кирәк – Батырша китапханәсе Р.Шәйхәйдаровның шәхси милке, ул аны музейга биреп кенә торган. Дәүләт бу бинага хуҗа булса да, Батырша китапларына хуҗа түгел, бәлки, яхшыгадыр...

«Батыршаның халыкка мөрәҗәгать итеп язган өндәмәсе һәм кулга алынгач, патшабикәгә язган гарызнамәсе бүген Мәскәү-Петербург архивларында саклана һәм фәнни әйләнешкә кертелгән. Шулар буенча XVIII гасырдагы милләт тормышын да, татар язмышын да белергә була, ә ул тоташ фаҗигадән тора. Батырша – шуларны язып калдыруы белән дә тарихи каһарман һәм милләт атасы! Батырша хәзрәт – милләтнең азатлык символы ул!» – диде Ф.Бәйрәмова, музей белән тагын бер тапкыр танышкач.

Әйе, Батырша хәзрәткә, аның хезмәтләренә игътибар җитәрлек түгел. Бары тик Уфада, Әлмәттә һәм Иске Балтачта гына аның исемендә урамнар бар, ә Казанда урын табылмаган (?). Батырша тарихын һәм мирасын санаулы кешеләр генә өйрәнә, аның буенча фәнни эшләр юк диярлек. Моның төп сәбәбе – Батырша хәзрәтнең, үз халкын яклап, империянең татарларны көчләп чукындыру сәясәтенә каршы чыгуы. «Аны шуның өчен кичермиләр, үзен күтәрмиләр, исемен күрсәтмиләр, – диде Ф.Бәйрәмова. – 2017 елның 12 апрелендә, Петербургта уздырылган «Фәезханов укулары» кысаларында Батыршаның тууына 300 ел тулу билгеләп үтелә. Анда тарихчы Фәйзелхак Ислаев «Батырша һәлак булган Шлиссельбург крепосте диварына истәлек тактасы куярга кирәк», дип тәкъдим ясый, әмма бу русларда ризасызлык уята. Рус православие чиркәвенә караган «Всемирный русский народный собор» дип аталган оешма вәкилләре моңа каршы чыгып, Батырша хәзрәтне «Известный антироссийский националист и религиозный фанатик», дип атый. Татарның татар булып, үз динендә калырга теләве шулай тамгалана. Хәер, әгәр Идел-Урал мөстәкыйль алган булса, Батырша хәзрәт аның түрендә булыр иде, чөнки ул – милләтнең Азатлык билгесе!»

«Тарихи-мәдәни мирас» фондының матбугат үзәге.

ЮЛЫН БАШЛАП КИТКӘН КӘРВАН

(С.Хаҗыбәевнең «Кәрван» симфониясе тәэсирендә)

Бер ботак шәүләгә мохтаҗ,
Бер болыт явымга ач.
Борчуын имләр дару юк...
Иксез-чиксез чүлдә калган
Юлын башлап киткән кәрван.

Мөсафирлык – иске сырхау,
Арттан сөрән житмәс юллар...
Кире кайтып булмас аннан,
Син – бичара, юл – бичара.
Юлын башлап киткән кәрван.

Дөнья – уен үтәр-үтәр,
Йөгең җайлы, якты китер!
И Аллаһ, мине дә китер,
Ялгыз китәрбез дуслыктан,
Юлын башлап киткән кәрван.

Бу ни язмыш, бу ни хикмәт,
Әллә илне жую бәхет...
Күрсәм-күрмәсәм ни кыйсмәт.
Тапсаң икән чара, дәрман,
Юлын башлап киткән кәрван.

Ак дөя өстендә гүзәл,
Яшькә тулган моңлы күзләр.
Үлем кагылудан әүвәл
Илдән китү моңы – дастан,
Юлын башлап киткән кәрван.

Сахра озын, яңгыр, җилләр,
Бу әкияткә бергә китик...
Адаштырыр сине фәләк,
Кайтырбыз кайсы юллардан,
Юлын башлап киткән кәрван?

Йөрәгемдә жырлы сәфәр
Яңгырар үлгәнгә кадәр.
Дөя белән минем киңәм
Әфьюндыр Хактан, Ходадан,
Юлын башлап киткән кәрван.

Ватаннан Ватанга барыйк,
Ярты юлда туктап алыйк.
Хакка йөз тотып ялварыйк,
Көрәштә булыйк каһарман,
Юлын башлап киткән кәрван.

Соңгы вакытта яшь татар шагыйрьләре арасында Көнбатышка йөз тотып, шигырьне аларча аңлаучылар күбәйде. Югыйсә безнең классикларыбыз Шәрык шигъриятенә йөз тоткан. Бер карасаң, бу табигый да. Күпме генә көнбатыш кешеләре булырга тырышсак та, асылыбыз башка төрки халыклар белән бергә шәрык рухына береккән.

Сона ханым Вәлиеваның шигырьләре белән беренче танышып чыккач та, күңелгә әнә шундый фикерләр килде. Аның шигърияте шәрыкча төгәл, хикмәтле, хисләргә бай. Татарчага тәрҗемә итәргә китапны Әзәрбайҗан язучысы Юнус Огуз тапшыргач та, бу җаваплы эшкә алынырга булдым.

Сона ханымның әсәрләре татар укучысы өчен дә кызыклы булыр, дип уйлыйм. Ни дисәң дә, элек руслар Кавказ татарлары дип йөрткән кардәш халыкның әдәбиятында уртак моңнарны безгә дә ишетү мәслихәт.

...Араз буенда бер кыз йөгерә. Ул нидер эзләп, әле анда, әле монда сугыла. Ниһаять, үзе яккан учак каршысына тезләнә дә, «Аразбары» көенә моңлана. Югыйсә каршы якта да аның игезәге, аның кардәшләре бар. Бүген алар күренми. Вакыт дәрьясын кичеп, Араз елгасын йөзеп чыгып булмый шул...

Күптән түгел Сона Вәлиевага 60 яшь тулды. Аны олуг юбилее белән тәбрик итәбез! Иҗади уңышлар сезгә, Сона ханым!

Рифат СӘЛАХ.

Сона ВӘЛИЕВА, әзәрбайҗан шагыйрәсе

Яр буенда әрни хәтер...

АРАЗБАРЫ*

Араз буен кемнәр кичте,
Яр буенда кемнәр күче?
Күз яшемне гөлләр эчте,
Салмак сайрый былбыл бары:
«Аразбары».

Тарихларның сүнмәс өне,
Елга да сөргендә инде.
Тәңре төзер ул күперне
Ярты кальга, ярты кайгы –
«Аразбары».

Юлга төшкән томан гына,
Үзем җитим юлларыма.
Нинди агач соң алдымда?
Җимеше – аерылу тәме –
«Аразбары».

Әле бар мин, әле юк мин,
Нәкыш-нәкыш моң тукыдым.
Язылмаганны укыдым,
Парә-парә, ярты-ярты
«Аразбары».

Кукчә, Шуша, Тәбриз моңы
Элеккечә җанга кунды.
Янып, көлдән янә тудым:
Утым үземнән югары,
«Аразбары».

Яр буенда әрни хәтер,
Юл бер адым, ара – дәвер,
Ни язмыш бу, нинди тәкъдир,
Кайда калды бәйрәм таңы,
«Аразбары»?

Язганнарым иңли күкне,
Без яшәгән җир кемнеке?
Корбан итеп ал син мине,
Араз атлы моңлы җанны,
«Аразбары».

«Шаех Сәфи», күрсәт юлны,
Җир кушылды, күк кушылды.
Кыныңнан чыккан угыңмы
Нәкъ йөрәгемә кадалды,
«Аразбары»?

Аһларым яндырыр ташны,
Кире кайткан бар юлдашым,
Төште кемнең каргышлары:
Кайгым – бөтен, туфрак – ярты,
«Аразбары»,

Өем, учагым Тәбриздер,
Туе, матәме минсездер,
«Карагилә» бер үксездер,
Ил кайгысы һаман сары,
«Аразбары».

Таш диварсыз кальга эзлим,
Муеныма минде золым,
Сөякләргә үтте золым,
Синдәдер сер ачкычлары,
«Аразбары».

*__Аразбары__ - әзәрбайҗан халык җыры, «Араз киртәсе» дигән сүз. Араз елгасы буенча сызылган чик әзәрбайҗан халкының бер өлешен Иранда калдырган.

КАПКАҢА КИЛДЕМ, АЛЛАҺЫМ!

Гөнаһ һәм гаеп белән,
Савап һәм бурыч белән,
Җан атлы букчам белән
Капкаңа килдем, Аллаһым!

Гомер буе гөл иктем
Шатлык биреп, гамь чиктем,
Туганчы мәләк идем,
Алдангач, килдем, Аллаһым!

Гомер – тышау эчендә,
Сөю, догам – эчемдә.
Юлны башлап эчемнән
Капкаңа килдем, Аллаһым!

Син аңлыйсыңдыр мине:
Бер акыллы, бер тиле.
Ни иктем дә ни бирим,
Кулларым буштыр, Аллаһым!

Кемгә калды йорт-җирем,
Күккә җитәр кул бирче...
Йөрәгемне гамь күмде,
Капкаңа килдем, Аллаһым!

Юлга энә биләнде,
Бормаланды, бизәлде,
Бар моңым шигырьләнде,
Капкаңа килдем, Аллаһым!

Күпме, азмы, Син беләсең,
Догам, язгым, Син беләсең,
Гыйсъянымны Син беләсең,
Капкаңа килдем, Аллаһым!

Бер юл ачылыр, килермен,
Бер көн сайланыр, килермен,
Бер көнгә алдан белермен,
Диярмен: килдем, Аллаһым!

ЕЛЫЙ АЛМАГАН ЧАКТА

Күңел тулса,
Елый алмыйм,
Барыбер язам шигырь.
Күз яшьләрем урынына
Кәгазьгә сүз түгелер.

Телем-телем сүзләр үкси,
Күңлем
Юл-юл агачак.
Күзләремнән, калебемнән
Йөрәккә ут кабачак.

Бүлмәсенә чигенәчәк
Янартаудай хисләрем.
Тынычлангач, йөкләр алар,
Күреп тәмле төшләрен.

САГЫНГАН КЕШЕ

Коеп яуган кар астында
Җилләрне бара сөйрәп.
Үксез калган җанына шул
Бер кеше генә кирәк.

Киткән кешесен сагына...
Ул кайтса – чыгар кояш.
Күңелен кимерә тынлык –
Кем булыр аңа юлдаш?

Ул ике таш арасында
Кысылып калган кебек.
Гомерлек гамь читлегеннән
Коткарыр аны өмет.

Иңенә күкләрне аскан,
Күзләре юлда һаман.
Керфекләрендә дивардыр,
Күз яше кибеп калган.

Якыннары арасында
Ул үзен ялгыз тоя.
Мәхәббәтнең кальгасында
Ул үзе горур кыя!

Үз өендә дә ялгыз ул,
Үз өендә дә ятим.
Күңел капкасын кагучы
Берәү табылыр, бәлкем.

СИҢА БЕР ШИГЫРЬ УКЫЙМЧЫ

Бу форсат – еш килмәс мөмкинлекләрдән,
Фәрештәләр белән төшкән күкләрдән,
Мең елдыр һичкемгә сөйләнелмәгән,
Кил, сиңа бер моңлы шигырь укыймчы.

Без – чүлдә кулэгә көткән җаннар күк,
Бер шифа тапмаса, йөрәк янар күк,
Бер бөртек йөзем, бер бөртек анар күк,
Кил, сиңа бер моңлы шигырь укыймчы.

Тәңребездән иңгән шифа, тат кебек,
Тик тимә җаныма җиде ят кебек.
«Мең дә бер кичә»дә Шәһризад кебек,
Кил, сиңа бер моңлы шигырь укыймчы.

Ни бар сүздән бөек, сүздән зуррак та!
Сүз – дустым да, сүз – дошман да, сүз – ят та.
Тәңре җаннарны сүз белән уята,
Кил, сиңа бер моңлы шигырь укыймчы.

Күңлем – чәчәк аткан бадәм агачы,
Тәңре могҗизасы, җанның дәвасы,
Дәүләт-байлыгым шигъри табышым
Бүлик икегә, бер шигырь укыймчы.

ҮПКӘЛӘГӘН ЧАГЫМДА

Үпкәләшкәч, татулашу рәхәт,
Әйтерсең лә син бердәнбер җирдә!
Дөньядагы тәүге гүзәл хисләр
Бөреләнеп чәчәк ата синдә.

Рәнҗүләрдән өзелсә дә күңел,
Дәһшәтләнеп килсә мәхшәр дә.
Чарасыздан, татулашкан саен
Дәртең арта җирдә яшәргә!

Хисләреңдә янә адашмасаң,
Әллә үле, әллә тере син.
Ихтыярсыз, ямаулы күлмәкчән
Туйга барган гүзәл кебек син...

Рәссам Радик Мусин 1989 елны Башкортстанның район үзәге Борай авылында туган. Алты яшькәчә Агыйдел шәһәрендә яшәгән, соңрак Борай урта мәктәбенең IX сыйныфын тәмамлап, 2005-2010 елларда Уфа сынлы сәнгать училищесының сәнгать бүлегендә укыган. 2011-2014 елларда Уфаның З.Исмәгыйлев исемендәге дәүләт сәнгать академиясендә белем алган. Шул ук елларда Уфаның «Богемика» шәхси дизайн мәктәбендә рәсем, сынлы сәнгать дәресләрен һәм «Радикаль сынлы сәнгать» авторлык курсын алып барган. 2015-2017 елларда исә Санкт-Петербургта яшәгән. Бүгенге көндә Мәскәү каласында яшәп иҗат итә.



● Татар кызы.

МИЛЛИ КОД –

● Тибет кызы.

●Башкорт кызы.

«Әтием Ридус инде бакыйлыкта... Әнием Ләлә – музыка буенча тәрбияче, – ди иҗатчы. – Әбием Наилә дә музыка өлкәсе хезмәткәре, башлангыч классларда педагог булып эшләде. Мин кечкенәдән гел рәсем ясадым, бу шөгыльгә әнием өйрәтте. Унике битле, шакмаклы дәфтәр бирә дә: «Рәсемнәр яса әле!» – ди. Дәфтәр бераздан рәсемнәр белән тулгач, әнием тагын кәгазьгә төрле сызыклар сызгалый һәм шуларны берәр образ килеп чыгарлык итеп үзгәртергә куша. Алары да килеп чыга иде. Тик мин сынлы сәнгать мәктәбен түгел, ә балалар музыка мәктәбенең фортепиано классын тәмамладым. Шуннан соң сәнгать училищесының эстрада бүлегендә укырга уйладым, музыкант булырмын дигән идем дә, әти-әни рәссамлыкка укырга киңәш итте. Әнинең бертуганы – Җәмил Әхмәтгалиев та оста рәссам!»

Уфа сынлы сәнгать училищесына кергән Радикка җиң сызганып укырга туры килә. Чөнки рәссамлыкта махсус белеме булмагач, училищега бары тик сынау шарты белән генә кабул ителә ул. Ә андый шарт белән алынучылар өчәү була. Ел буе тырышып укыган Радикны гына II курска күчерәләр. Училищеда бары иҗат, уку белән генә шөгыльләнгәч, яхшы мөгаллимнәрдән белем алгач, осталык арта гына. «Иҗатта үз юлың белән барырга кирәк икәнен шунда аңладым, – ди Радик. – Портрет жанрында күбрәк ясыйм. График портретларга алынсам, рәсем линияләрен бик төгәл китереп чыгара торган линер ярдәмендә башкарам. Уфа сынлы сәнгать училищесын тәмамлагач та, Санкт-Петербургка юнәлдем. Шул каладагы А.Л.Штиглиц исемендәге сәнгать-сәнәгать академиясенә укырга кермәкче идем, әмма бу ният тормышка ашмады. Башкортстанга кайтып, Уфадагы шәхси дизайн мәктәбендә дүрт ел буе «Радикаль сынлы сәнгать» курсын алып бардым. Шул ук вакытта Уфаның З.Исмәгыйлев исемендәге сәнгать академиясендә укыдым, III курстан соң академиядән үз теләгем белән киттем. Янә Питерга юл алдым, ул кала гел үзенә тартты. Ул аерым бер галәм үзәге булып тоела иде. Әмма Петербургта синең үзең дә, иҗатың да беркемгә дә кирәкми икәне бик тиз аңлашылды. Бу– күңелне моңсулык белән тутыра торган халәт. Тора-бара башка иҗатчылар белән аралаша башладым, төрле фестивальләрдә дә катнаштым. Питердагы тәүге ел ярым вакытым бик авыр булды. Бу шәһәр – гомумән, башка организм, анда син, әйтерсең лә бик зур ярышта катнашасың. Чөнки Питерга чит дәүләтләрдән дә килеп иҗат итәләр, рәссамнар күп. Шуңа күрә ул вакытта Уфадан алган заказлар бәрабәренә генә яшәдем. Бервакыт Казанга кайтып китәргә булдым. Ул миңа һәрчак ошый иде! Әмма Петербург үзе тоткарлады төсле. Кайтырга җыена башлаган көннәрдә мәшһүр җырчы С.Шнуров зур күргәзмә әзерләве һәм рәссамнар җыйнавы хакында игълан итте. Ә мин моңа кадәр дә аңа портретын ясап бүләк иткән идем. Тик ул чакта без аз гына аралашып алдык. Зур проектка керешкән җырчы житмеш кеше арасыннан нибары өч иҗатчыны сайлап алды. «Эрарта»дагы шушы күргәзмәдә катнашу миңа тәҗрибә тупларга булышты. Чөнки «Сәнгать эрасы» дип исемләнгән бу музей Петербургның беренче заманча сәнгать музее иде, өстәвенә ул әле Васильев утравында ук урнашкан, аңа тамашачылар да күп йөри.

Ярты ел әзерләнгән күргәзмә өчен унбиш картина ясадым. Әмма бу мине рәссам буларак танытмады. Чөнки без бары тик Сергей Шнуров уңышы өчен тырыштык. Чыннан да, җырчының фанатлары күргәзмәгә килеп, аны егыла-егыла мактап китте. Әлеге күргәзмәне бераздан Мәскәүнең заманча сәнгать музеенда да ачтылар. Күргәзмә бер ел буе Россия буенча экспозицияләнде. Шул чакта Мәскәү миңа Петербургка караганда да ямьлерәк күренде. Ихлас булыйм: Питер – ул төксе дә, тар да булып тоела торган шәһәр. Андагы яшәү темпы да Мәскәүнекенә караганда акрын. Дөрес, дусларың күп булса, һәркайда күңелле. Ә менә Мәскәү – ул исә бик киң, анда яшеллек күп, урманлы җирләре дә бар. Ландшафтының кайбер урыннары Башкортстанны да хәтерләтә, җыеп әйткәндә, Мәскәү энергиясе ул чактагы күңелем халәтенә туры килде дә куйды. Һәм мин Мәскәүдә яшәвем иҗатым өчен уңышлырак булыр дип уйладым».

● Монгол кызы.

● Бурят кызы.

● Радик Мусин зур әнисе белән.

МИНЕМ ИҖАТЫМДА!

●Сөембикә.



●Сүзгә.

● Әрмән кызы.

Радик Ридус улыннан Казанга кайтмавының сәбәбен дә белешәм.

«2014 елда Казанны беренче тапкыр күрдем. Исем китте: кибеттә – татарча сөйләм, урамда – татарча сөйләм... Татарча сүзләр ишеткәч, хәтта елыйсылар килде. Чөнки Мәскәүдә яшәгәндә, татарлык үзен бик тиз искә төшерә, беренче планга чыга. Тик Казанда мәдәни чаралар күпкә азрак, күргәзмәләр сирәк. Чит илгә китәчәк картиналарга бәя бирүче белгечләр юк, алар бары Мәскәүдә генә. Шуңа күрә Мәскәү беренчел, әмма анда да күңелгә нәрсәдер җитми...

Мин үз һөнәремдә. Картиналарым да сатыла, билгеле. Менә криптоаукционда да бер эшемнең фотосын саттым. Моннан ел ярым элек стартаплар сату белән мәшгуль бер фирма өчен мәшһүр Илон Маскның портретын ясарга туры килгән иде. Мин юри генә, кармак салып, үземнең талантымны билгеләп карарга булдым. Шушы портретның үзен түгел, бары тик фотосын гына криптоаукционга куйдым. Ул сәхифәгә чыгып, 15 минут узуга ук 1200 долларга сатылды. Күз алдына китерегез, әлеге аукцион казиноны хәтерләтә. Анда катнашу өчен син башта үз хезмәтләрен аукцион аркылы саткан берәр рәссамның чакыруын кабул итәргә тиешсең. Аннан соң бу мәйданда булу өчен акча кертү сорала. Әйтик, анда катнашу өчен миңа 8 мең сум акча да түләргә туры килде... Шуннан соң тагын бер эшемнең фотосы белән катнаштым. Ә ул... сатылмады. Әгәр дә сатылса, тагын куяр идем, тик уңыш булмагач, туктадым. Мин акчаны җилгә очыра торган ир-ат түгел, аннары холкымда азартлыкка тартылу да юк, шуңа күрә мондый аукционнар эшчәнлегендә башка катнашмыйм.

Билгеле, минем джаз музыкасын уйнаучы һәм блюз җырлаучы буласым килгән иде... Ләкин бу хыял булып кына калды. Шулай да берәр концертка барсам, урындыкта тик кенә утыра алмыйм. «Их, йөгереп чыгарга иде дә, фортепиано артына утырып, уйнап җибәрергә иде. Алардан да ким уйнамас идем!» – дип уйлана башлыйм». Сүз уңаеннан, Радик фортепианода, гитарада, домбрада, авыз гармунында яхшы уйный.

Иҗатында ул кеше образларына, сюжетлы композицияләргә игътибарлы. Әмма китаплар бизәлешендә катнашу уе белән янмый. «Миңа аерым фигуратив сынлы сәнгать һәм портретлар ясау ошый. Текстларга берегү – минем юнәлеш түгел», – ди әңгәмәдәшем. Радиктан Сөембикә-ханбикә образын ничек иҗат иткәне хакында да сорашам.

«Санкт-Петербургта яшәгәндә үк, мин татар музыкасын тыңлый, төрки милләтләр тарихы белән кызыксына башладым. Мин бит татар авылында туып-үстем. Формалашкан мохитем дә татар мохите иде. Үземне һәрчак татарлыгым аша кабул иттем. Ә Петербургка килгәч, күңелем мәдәни шок халәтен кичерде. Шул вакытларда Казан егетләре белән таныштым. Алар арасында Бөтендөнья татар конгрессында эшләүчеләр дә бар иде. Алар төрле мәдәни чараларны, фестивальләрне татар телендә генә алып барды. Мин мондый чараларның үзем өчен мөһим, ә татар мәдәниятенең башка мәдәниятләрдән бер ягы белән дә ким булмавын аңладым. Шул чакта иҗатымда милли образлар, милли кодлар пәйда булды... Әйтик, Румыния дәүләтендә оештырылган Татар мәдәнияте көннәрендә ачылган күргәзмәм өчен үземә кызыклы булып тоелган ун тарихи шәхесне сайлап алган идем. Шуларны рәсемнәр итеп ясадым. Сөембикә-ханбикә дә шул чакта иҗат ителде. Моннан кала мин Сүзгә ханбикә образына да тукталдым. Сүзгә ханбикә өчен туры килүче образны Мәскәү метрополитены поездында очраттым. Метро вагонындагы бер кызга игътибар иттем. Ул скрипкачы һәм төрки милләтле кыз иде кебек... Сүзгә ханбикә шушындый йөзле дә булгандыр дип уйладым. Аңа: «Бер яңа сериям иҗат итә идем, сез менә Сүзгә ханбикә образына туры киләсез, сезне фотога төшереп алырга гына рөхсәт итегезче», – дип үтендем. Ул каршы килмәде. Сүз уңаеннан, ул чакта миңа Сүзгә-ханбикәне бик күпләр белеп тә бетермидер кебек булып тоелды.

Сөембикә образы да нәкъ шулай туды! Тагын бер кызга карагач та, башыма: «Бәлкем, моннан биш гасыр элек яшәгән Сөембикә-ханбикә дә шушындый булгандыр!» – дигән уй килде».

– Радик, сезгә – 32 яшь. Рәссамлыкта үз тәҗрибәгез бар. Бу һөнәргә аяк басып кына килүче яшүсмерләргә нинди киңәш бирер идегез?

– Булачак рәссамнар үз шәһәрләрендә яки үз Ватаныбызда гына түгел, ә гомумән, бар дөньяда нинди мәдәни чаралар үткәрелүен белергә тиеш. Әйтик, нинди күргәзмәләр, нинди иҗат бәйгеләре оештырыла? Алар нинди темаларга багышланган һ.б. Бу җитди күргәзмәләрне, иҗади бәйгеләрне оештыручыларны да белү шарт, алар белән таныш булу да мөһим. Интернет булышлыгы белән хәзерге рәссам авылда яшәп тә, үз картиналарын сата ала. Моның өчен титаник хезмәт таләп ителми. Рәссамның бары үз йөзе, үз стиле генә булырга тиеш!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Адлер ТИМЕРГАЛИН

КАЙТЫР ЮЛЛАР

Кайчагында, ничәмә-ничә гасырга бер тапкыр, Галәмнең кайсыдыр бер нуль ноктасында, нигәдер ялгыз электрон туа. Күзгә күренми торган нәни генә бер кисәкчек ул. Матдә һәм энергия саклану кануннарын мыскыл иткәндәй, ул кинәт юктан бар була. Бу кануннарны ачкан Лавуазье һәм Джоульләр мондый чакта данлы табутта яткан килеш оятларыннан кызара торгандыр. Әлегә фән теше үтмәгән бу күренешне антилавуазье эффекты дип йөртәләр.

Электрон менә шулай вакыт-вакыт гел дә юктан барлыкка килә дә, әйләнә-тирәгә коточкыч куәтле гравитацион дулкын тарала. Андый дулкын сыртына эләккән космик корабльнең эше харап. Гравитация көче аны, уенчык көймәне атып бәргән шикелле, йөзләрчә парсек читкә ыргыта.

Егерме беренче гасырның күренекле астрофизигы һәм математигы Бэрт Сәлим, антилавуазье күренеше аркасында вакыт агышы кискен үзгәреп, бер мизгел эчендә мен еллар аша сикереп үтәргә мөмкин дип саный иде.

Безнең сәяхәтчеләр менә шушы сирәк очрый торган хәлгә юлыктылар.

Алар авариядән соң үзләренең кая килеп чыгуларын да белмиләр, чөнки кап-кара бушлыкта һичбер җемелдәүсез янган йолдызлар берсе дә таныш түгел иде. Иксез-чиксез дөньяның кайсы гына төше икән бу? Галәм зур Киек Каз Юлы чолгап алган системадан кала, анда бүтән галактикалар, аннары китереп аларын бергә туплаган Метагалактика бар, ә ул тагы да зуррак дәрәҗәле системага карый...

Сәяхәтчеләр Галактиканың читенә – сул як култыгына барып, беренче тапкыр Бөек Божра белән радиоэлемтәгә кергәннәр һәм тугандаш затларны табу шатлыгын җиргә алып кайтып баралар, өйгә ашыгалар иде.

Корабльнең аскы дюзлары потлы чүкеч астына кереп чыккан кадак кебек яньчелгән иде. Аларны бераз рәткә кертү, төзәтү-ямаштыру өчен айдан артык вакыт китте.

Астронавтлар өчәү иде.

Ракетопланның гаять зур шәүләсе болытлар өстеннән уктай шуып узып китте.

– Шәһәр... – дип пышылдады капитан, аскы иллюминаторга иелгән көенчә. – Грин, ә экраннар ни күрсәтә?

– Шәһәр, капитан, – диде кәефе күтәрелгән пилот, борынгычалап (буш вакытларында ул борынгы үле телләрне һәм риваятьләрне өйрәнә иде). – Очсыз-кырыйсыз шәһәр! Без котылдык бугай. Безгә ярдәм итәчәкләр!

– Котылдык шикелле, – диде капитан һәм үтә күренмәле титаноглас башлыгын салып битен сөртте.

– Ә ник сигналлар ишетелми? – дип сүзгә кушылды Алиса, радиоаппаратка ишарәләп. – Үлеп-кырылып беткәннәрмени!

– Әйе, эфир тып-тыныч, дулкын әсәре юк, – диде Грин. – Җилсез көнне көзгедәй ялтырап яткан күл диярсең.

– Тымызык күлдә корт уйный, – дип башын чайкады шикләнүчән һәм сакчыл капитан. – Грин, планер канатларын чыгарыгыз!

– Төшәбезме, капитан?

– Башка чара юк.

Корабль кәкре сызык буенча түбәнгә омтылды. Шул секундта ук диярлек колак телефоннарында улап сызгырган тавыш ишетелде һәм ракетоплан, сикәлтәгә төшкән автомобиль кебек, югары сикерде. Экраннарда шәмәхә ялкын кабынганы күренеп алды.

– Пилот! Руль нишләде?

– Рульдән түгел бу, капитан! Без әллә нинди гравитацион мендәргә бәрелгән күк булдык!

– Алиса!

Радистка кыз җавап бирмәде. Ул күзләрен чытырдатып йомган килеш утыра иде.

– Борт-радист! Сигнал бармы?

– Алиса, ни булды? – дип кычкырды пилот микрофонга. Аның тавышында борчылу, хәтта курку ишетелеп китте.

Кыз башын күтәрде һәм көч-хәл белән генә елмаеп:

– Гафу итегез, – диде. – Микротелефон сафтан чыкты... Радионур...

– Радионур?

– Әйе, – диде радист һәм җитез куллары белән телефонны тоташтырырга тотынды. – Безне капшап таптылар һәм...

– Мин дә ишетәм! – дип кычкырды шул чакны Грин. – Безгә радионур ияреп бара, капитан!

– Станция берәү генәме?

– Безне, эстафета кебек, бер станциядән икенчесенә тапшыралар.

Капитан, каты авыртуны җиңәргә тырышкандай, чыраен сытты. Авария вакытында аның яңагы җәрәхәтләнгән иде. Хәзер шул яра җөе кәгазь тасма шикелле агарып китте. Ни эшләргә?

– Тагы йөз километр өскәрәк!

Пилот бу әмерне берсүзсез үтәде, ләкин аны һаман бер уй борчый иде: ягулык тамчылап санарлык кына калды, болай булса, планетага төшү өчен дә җитмәве бар бит! Ә кислород?

– Поляр орбитага күчәргә!

Пилот газ рульләрен эшкә кушты.

Ят планетаның урта киңлекләре өстендә куе яңгыр болытлары йөзә иде. Тоташ болыт өемнәрен яшен чаткылары телгәли. Ләкин котып өлкәләре аяз: яшькелт сары ярымутраулар, бозлавыклы атаулар һәм ак бүрек кигән таулар, тагы да арырак тоташ боз-кар мәйданы күзгә чалынды.

– Үрдәк борынына охшаган ярымутрауны күрәсезме? – дип сорады капитан.

– Шунда утырырга дисезме?

– Әгәр төшәргә ирек бирсәләр...

– Баягы мендәр гравитацион калкан булды микән әллә? – диде Алиса.

– Әйе, Алиса, – диде аңа капитан. – Күрәсең, мондагы халык килмешәкләрне сөйми...

Капитан күзләрендә шик, ят дөньяга ышанмау һәм хәтта дошманлык билгеләре чагыла иде.

Төшкән урыннары табигый матурлыгы һәм уңайлык ягыннан һич тә мактарлык түгел иде. Дөрес, ерак та түгел зәңгәр күл җәйрәп ята, димәк, суга кытлык булмаячак, һавасы турыдан-туры суларлык, чытырмандай үскән куаклар исә учак ягу өчен әйбәт булып чыкты, һавада да, туфракта да микроорганизмнар табылмады.

Сәяхәтчеләр, тирә-юнь белән бер кат танышкач, ут ягып шуның тирәсенә утырыштылар.

– Әгәр бу кунак сөймәс планета халкы булышмаса, бөтен төзәтү эшләрен үзебезгә ерып чыгарга туры киләчәк, – диде капитан.

– Ә атом-төш ягулыгы?

– Анысын да үзебез әзерләрбез, Грин. Судан дейтерий алырбыз.

– Күпме вакыттан?

– Бәлки өч ел, бәлки дүрт ел үтәр...

– О! – дип куйды Алиса. – Ул чагында мин әби булып бетәрмен инде!

– Ләкин без үзебезнең космик координаталарыбызны белмибез.

– Җирле халыктан башка белә дә алмаячакбыз! – дип капитанны бүлдерде Грин. – Йолдызлар таныш түгел, бәлки чоры ук башкадыр:.. Әгәр Бэрт Сәлим хаклы булса...

– Җирле халык белән элемтә урнаштырырга тырышырбыз тырышуын, – диде капитан. – Әмма мин үзем моңа ышанып бетмим.

– Ни өчен, капитан? Һәрхәлдә, мондагылар безгә планета өстенә төшәргә ирек бирделәр бит. Югыйсә, гравитацион калканны котып тирәсенә дә җәя алырлар иде.

– Алар шундый кешелексез! – дип нәтиҗә ясады Алиса һәм учактагы күмерләрне болгатып җибәрде.

Вак-вак чаткы йолдызлар болыт булып күккә күтәрелде. Борыннарга кичке салкынча һава белән аралашкан төтен исе килеп бәрелде, күңелләрне борынгыдан, кыргыйлык чорыннан ук калган тойгы – хәтәр-куркынычны алдан сизү тойгысы биләп алды. Юк, юк, аларга кылыч тешле юлбарыс та һөҗүм итмәячәк, шәрә тәнле вәхшиләр дә пычак белән янамый, җәмгыятьнең балачагына хас зиндан- коллык та, дар агачлары да көтми аларны... Мондагы мәдәният ифрат алга киткәнгә охшый. Планетаны шундый калкан белән төреп алу өчен күпме көч-энергия кирәк! Иң югары дәрәҗәгә ирешкән аң-гакылның салкынлыгы, игътибарсызлыгы, үзеннән түбәннәргә җир кортына караган кебек каравы – иң куркынычы...

Тик радио белән мәшәкатьләнергә туры килмәде. Планетаның хуҗалары элемтәгә керү чарасын үзләре күрде. Адашкан сәяхәтчеләребез аны-моны уйлап, эшләп өлгергәнче, аксыл булып төсмерләнеп торган көньягыннан мотор гөрелтәсе ишетелде һәм сыек караңгыда нидидер бер очкычның прожектор утлары күренде.

Капитан каушый торганнардан түгел иде. Ул ашыкмый-кабаланмый гына лазер-пистолетын әзерләп куйды. Башкалар да шуны ук эшләде.

Бер урынлы орнитоптерга охшаган очкыч машина учак янына ук килеп кунды.

Аннан чыккан зат... Безнең сәяхәтчеләребез галәмдә үзләренә охшаган затлар барлыгын беләләр иде. Кайчагында хәтта тулы биохимик охшашлык та очрый. Килеш-килбәтләре белән кешегә тартым затларны һуманоидлар дип атыйлар. Планетаның вәкиле нәкъ менә шул һуманоид иде. Ул сәяхәтчеләр янына килде. Бер карау белән кемнең кем булуын чамалап, капитанга металл каска кебек нәрсә сузды. Капитан, тегенең күзләренә караган көенчә, касканы башына киде. Бу каска, күрәсең, аңлашу һәм сәяхәтчеләрнең телен өйрәнү өчен хезмәт итә иде. Чирек сәгатьтән вәкил җир халкының телен үзләштереп алды кебек:

– Сәлам сезгә, илгизәрләр, – диде ул, сәяхәтчеләр телендә. Аның тавышы ягымлы гына иде.

Астронавтлар баш иеп исәнләштеләр һәм һуманоидка учак яныннан урын тәкъдим иттеләр.

– Мин ярдәм итәргә килдем, – диде вәкил, җайлап кына чүгәләп утыргач.

Капитан баш какты. Ул, һуманоид сүзләренә игътибар итмәгәндәй, касканы әйләндерә-әйләндерә карый иде.

– Кире очып китү өчен сез бөтен кирәк-ярак белән тәэмин ителерсез. Шарты болай: сез монда кабат беркайчан да әйләнеп кайтмаячаксыз... Бу планетаны онытыгыз.

(Дәвамы киләсе санда).

Ибраһим Гази көндәлеге



● Ибраһим Газинең куен дәфтәре.



● Гадел Кутуйның хаты, 1944 елның 12 августы.

● Ибраһим Гази. 1929 ел.



● Ибраһим Газинең куен дәфтәре.

Татарстан Милли музей фондларында Ибраһим Газинең үзе белән фронтта йөреп кайткан куен дәфтәре саклана – 47 битле: 1942 елның 31 гыйнварында башланып, 1944 елның 1 октябрендә тәмамланган.

Безгә матур, оста телле, тормышны тирәнтен белгән нәфис сүз остасы Ибраһим Гази уч төбенә сыярлык кечкенә блокнотка өч ел фронт хәлләрен – көнлек мәшәкатьләрен сугыш елъязмасы итеп күз алдына бастыра. Мондый ситуациядә туган экспрессив фразалар кино кадрлары кебек күз алдыннан йөгерә. «Сагынам, – ди ул, чит гореф-гадәтләрне күзәтеп. – Борынгылар шикәргә карап чәй эчкән. Поляклар чөгендер икмәгенә карап бәрәңге ашый. Аларның песиләре пес-пес дигәнгә әйләнеп карамый. Шуңа, күрәмсең, мин үземнең туган илемне сагынам. Аның мин, җиренә ятып, туфрагын үбәр идем. Чит илләрдә йөрмәгән кеше, бәлки, минем тойгымны аңламас».

Менә тагын бер бит: «Михалина килсә, кояш чыккан кебек була. Мин вакытны төнгә, көнгә, атнага, айга бүлмим... Михалина килгән көн. Михалинаны күрмәгәнгә ике көн булды дип йөртәм. Михалина – чибәр кыз. Ул керсә, пычрак өйдә нур балкый. Аның тавышы мине пружинадай итә. Без аның белән сөйләшәбез. Мин тирләп чыгам. Ул мине аңламый, мин – аны. Ләкин безнең күзләр бик яхшы аңлый».

Блокнот битләрендә Фатих Кәримнең кыр почтасы адресы: «06572-6. Ф.Карим», Сәйфи Кудашның Уфа адресы.

Уй-фикерләр артык гадәти булса да, кайбер чагыштырулары мондый авыр шартларда да шагыйранә булып туа. Шагыйрь өчен, бу блокнотта язылган гыйбарә-фикер җыентыклары – шигърият ул. Бик аз вакыт эчендә карандаш белән кәгазьгә төшкәннәр – автор өчен хисси бер яшьнәү: «Көне-төне яфрак белән яңгыр ява. Сары яфрак, салкын яңгыр. Җир шары болытка һәм томанга төренде. Айны, кояшны, йолдызларны күрмәгәнгә әлләни гомер». Тормышның көнлек мәшәкатьләрен язган чакта, ул һәрвакыт туган якны, аның бәгырь өзеп сагындыра торган үзенчәлеген искә ала.

«19 февраль. Менә 23 көн инде һаман юлда. Нинди генә идәннәрдә кунмадык, нинди генә чырайларны күрмәдек, нинди генә җирләрдә булмадык, ашарга беткәнгә күптән. Әлегә хәтле аннан-моннан юнәтеп килдек. Бар шундый авыллар, ашарга түгел, эчәргә су да алып булмый. Менә хәзер дә Актүбә дигән авылда туктадык. Коеларның тирәнлеге 19-20 метр, су ала алмыйлар, чөнки озын җеп юк. Кар эретеп эчәбез. Бу яклар, гомумән, сөйкемсез. Кызыл балчык, шәрә – һичбер агач юк. Үзебезнең якны сагынырсың. Шунысы тагын, утын табып булмый. Камышинда 4-5 көн гел газета ятык – менә кая китә икән алар! Бөтен бер фронт газетасы бергә җыелган: ягабыз да ягабыз». «Кичә улымның туган көне иде. Мин төн буе квартира таба алмыйча, тездән пычрак сөреп, фатир эзләдем. Дөресрәге, эзләдек. Дөнья тулы солдат, баш тыгып булмый, бер яры кертмиләр. Төнге сәгать берләрдә шәһәрдән 2-3 чакрым бер авылда, Сталинградтан качкан бер татар агай-энесе кунарга кертте. Чишенмичә, егылып йоклап киттем (алдан ике төн бер вагонда бер тамчы йокы күрмәгән идем). Торып ашап-эчкәч, тагын киез итек белән пычрак сөреп, комендантка фатир дауларга киттек. Ниһаять, бер ташландык йорт бирделәр, ягылмый, тәрәзәләре ватык. Хуш исле печән өстендә шушы сүзләрне язып утырам. Безнекеләр Орелны алган, кайчан-ничек китәбез, билгеле түгел».

Сүзләр белән кәгазьгә төшерелгән картиналарда солдат халкының көн саен күз алдында булган вакыйгалары документаль кино кадрлары кебек күз алдыннан йөгерә.

«23 февраль, Зимовники. Биредә сугыш эзләре ярылып ята: янган, җимерелгән йортлар, үлгән атлар, җимерелгән машиналар, ярылмаган снарядлар, тау-тау гильзалар, янган немец паровозлары, җиңел машиналар». «24 февраль. Зимовникидан самолет белән Ростовка килдем, аннан Батаевскийга». «Ростов өстендә кара сөрем. Бөтен нәрсә яндырылган. Кара көйгән йортларның скелетлары гына тырпаеп тора. Немец самолетлары ишелеп ята, пәрәвездәй булып, телеграф чыбыклары буталып беткән. Бомба ясаган чокырлар; ярылмаган авиабомбалар; янган вагоннар; автомобильләр; ат үләксәләре; чатан этләр; шартлатылган күперләр; сугыш бу җирдән өермә төсле үткән, үз юлындагы барлык нәрсәне яндырган, җимергән, таптап-изеп үткән, шәһәр яны гына терелеп килә».

Блокнот битләрен укыганда, ул вакытның икътисади хәле күзаллана.

«Кружка сатып алып, 10 сумга бер тәлинкә бәрәңге, шунда базар уртасында чүмәшеп ашагандай иткәч, шәһәргә барган идек: парикмахерда озын койрык». «Вокзал каршындагы мәйданда туктап, көзгене чыгарып, бритваны учка кайрап, урам уртасында сакал кырдым. Аяк асты бук, сасы. Менә шул инде солдатның тормышы. Алда – башланмаган юл (27 сентябрь, 1944 ел, Минск шәһәре)». «Ачыгып, каңгырап, Москвада йөри торгач, бүген таңда Минскига килеп төштек. Шәһәрдән сөремләнгән таш тартмалар гына калган. Юл газабы – гүр газабы дип юкка әйтмәгәннәр. Йокысыз, ач вагонда тәүлекләр буе аяк өсте килә-килә тәмам ябыктык. Көзгегә карасам: бер биш еллык картайганмын. Ашханә юк икән, базарга барып 10 сумга бер сынык икмәк алдык, 10 сумга!». «Карлыгач четер-четер килә» [4, с. 21].

Көндәлекне укып чыккан тарихчы хәрби частьнең чынлыкта йөргән маршрутын күзәтә, өйрәнә ала.

«Киев аркылы үттем, шәһәрдә йөрдем. (16-17 сентябрь, 1944)». «Львовта булдым. Бер поляк интеллигентлары семьясында кундым. (14-15 сентябрь, 1944)». «15 октябрь. Поляклар казны тере килеш йолкый. Каз кычкыра. Күрше ашаганга, теш казып йөрибез шунда». «28 сентябрь. Бороновичига килеп, аның да боткасын ашадык. Яңгыр. Юкә, карама яфраклары сап-сары».

«4 октябрь, 1944 ел. Польша. Көз җитте. Яфрак коела. Зәгъфран кебек сары яфрак аяк астына түшәлеп ята. Анда да монда да су җыелып тора. Ә кояш безне онытты. Көннең ямьсезлеге, табигатьнең көзге моңсулыгы, баш өстендә торган кара болыт күңелне таш кебек изә. Бүген сыерчыклар үзләренең оялары белән саубуллашты. Канат җилпегән булалар, сайраган булалар. Яз искә төште. Балкып торган Кырымда йөргән шатлыклы көннәр күз алдына килеп басты. Күңел талпынып, ... эреп куйды, ләкин кошчыклар соңгы җырларын җырлап бетерде дә, бөтенләйгә китеп барды. Алар китте, без калдык. Алар язлый тагын әйләнеп кайтыр, ә без... Без кайтырбызмы ояларыбызга?».

Блокнотның 16 нчы битендә И.Гази зәгъфран төсендәге үләнне салып киптергән. Язмаларының шаһите булып, ул әле дә шул биттә ята...

Блокнотның беренче битендә Ф.Кәрим шигыре – Кадриясе – хатынына багышлап язган. Чын дуслар язышып торганнар – күренә.

Ә шулай да син еракта
Мин тик хатыңны күрәм.
хатка язган сүзләреңне
Күзләрең итеп үбәм (Ф.Кәрим).

Гадел Кутуйның Казаннан юллаган соңгы хаты И.Газига язылган булган. Әдәби экспозиция төзегән вакытта, 1958 елның 31 декабрендә, әдәбият бүлегенең бердәнбер хезмәткәре Фатыйма апа Вәгазова аны Язучылар союзыннан алып кайткан, фронтовик язучыларның союзга җибәргән хатлары, кульязмалары белән (120050 (1-17).

Эчтәлеге сүзен-сүзгә болай: «Газый дус! Мин әле хәзер генә союздан, мине озату кичәсеннән кайтып кердем. Тагын ике сәгатьтән вокзалга төшәм. Син: «Нишләттеләр инде?» – диярсең. Әйе, китәргә туры килә.

Соңгы сүзләремне сиңа язып калдырам. Исән-сау яшәгез. Тату булыгыз. Фронтовик язучыларның гаиләләрен ташламагыз. Күз-колак булып торыгыз. Мин русча җыентык калдырдым. Дөньяга чыгар дип ышанып китәм. «Ростәм»нең дәвамын җибәрермен. А.Гомәр аны үзе китап итеп бирер. Өч табагы С.Ә. журналында.

2 аем күңелле генә узды. Рәхмәт. Галимәнең хәленнән хәбәрдар булып тор. Карточкадан өзмә. Сәламәтлек теләп: Гадел. 12.VIII.44 г.»

Менә нинди затларның изге теләкләре калган безгә. Үзләренә дога булсын...

Рәмзия АБЗАЛИНА.

Мәдәни җомга
8 июль
№26, 2022

● Малаяз авылы «капкасы».

● Салават җыры. Е.Клейменов эше.

● Бәхтияр Канкаев портреты.

Салават һәм

Әле студент чагында, каһарман Бәхтияр Канкаевның көрәш юлы белән таныша башлагач та, әлеге Пугачев бригадирының туган ягын күрәсе килгән иде. Адәм гомере – агымсуларга тиң, ул хыял бөреләнә башлауга да 40 еллап үткән. Ләкин Мөхәммәт Мәһдиев әйтмешли, күрәчәк ризык, барыбер, тешеңне сындырып булса да керә икән. Менә мин фәкыйрегезгә дә, җиденче дистәне кырлап барганда, атаклы Салават Юлаев белән каһарман Бәхтияр Канкаевның туган «төяк»ләренә сәяхәт кылу бәхете эләкте.

Бәхтиярнең кече Ватаны булган Мәчетле районы Башкортстанның иң көнчыгышында, Екатеринбург янәшәсендә икәнен карта аша гына эзләп белә идем. Юлдашым Рифат Каюмов белән Чиләбегә илтә торган юлны сайладык. Әмма Уфадан соң йөз чакрым чамасы ара узуга ук, тешне кысып түзмичә, сүгенергә дә туры килде. Без моннан Чаллы вәкилләре белән 22 ел элек тәүге тапкыр узган, ул чагында Чиләбе Сабан туен үткәрергә дип барган идек инде. Әле шул 2000 елда ук Уфа белән Чиләбе арасындагы юлны 15-20 чакрым саен ермачлап ташлаганнар, әле уң, әле сул ягында мәрмәр кыяларны кимереп, ташларын юл астына түшиләр, елга-инешләр өстенә бетон багана һәм плитәләр тезәргә эш фронты әзерләнгән иде. Чиләбе юлы – Россиянең Европа белән Азия өлешен тоташтырырга тиешле төп артерия, аның аша сәгать саен йөзәрләгән машина уза, аларның яртысы Урал аръягындагы тимер, чуен, бакыр, алюминий, никель заводларыннан меңәрләгән тонна металлны Европага ташый, шуңа күрә ул вакыттагы төзелеш һәм җимереклекләрне «вакытлыча гына бу, шулай тиеш», дип кабул иткән идек. Менә инде 22 елдан соң кабат «аяк бастык», ә Чиләбе юлы һаман яу кырындагы траншея һәм окопларга тиң. 15 чакрым ара узасың да йә бер ягы ябык күпер борынына, йә асфальтны актарып ташлаган «бомба» чокырына килеп төртеләсең. Чиләбе юлында һичнинди үзгәреш юк, ил шикелле үк, ул ташландык хәлдә. Миллионлаган адәм баласының сугыш чорында тоткыннар белән әсирләр төзегән агач баракларда кайнар су белән бәдрәф тә күрмичә «гомер» итүен, Себер киңлекләрендә ел саен йөз меңнәрчә гектар тайганың янып юкка чыгуын, миллионлаган гектар басуларны алабута белән билчән каплап бетерүен бөтенләй «онытканнар», шул килеш тә чиктәш халыкларга «үрнәк» ил рәвешен тагарга, чикне киңәйтергә җөрьәт итәләр бит!..

Сукрана-сукрана, туктый-туктый булса да, Сим каласына җиттек. Салаватның әтисе Юлай Азналин старшина булган Шайтан-Көзәй волостеның йөз мең дисәтинәсе өчен шалкан бәясе түләп, бер урыс сәүдәгәре 1760 елда монда завод китереп салган. Үзен төп башына утыртуны аңлап алган Юлай 1774 елның 23 маенда - Сим, ә аннары Өс-Катау, Катау, Йөрүзән заводларын, Орловка, Ерал авылларын яндырып юк иткән. Менә шушы «этлеге» өчен Юлайны әлеге заводлар каршында һәм Орловка авылы мәйданында 45 әр мәртәбә камчы белән яргач һәм борынын кисеп, яңакларына, маңгаена кыздырылган тимер белән «мөһер суккач», улы белән бергә Балтыйк буендагы Рогервик крепостена мәңгелек каторга эшенә сөргәннәр дә инде... Ә Симдагы завод үзе тиз арада сафка бастырылган, һаман гомер буе металл койган. Дөрес, без үткәндә, завод торбасыннан төтен чыкмый иде, эшчеләре «каникулга» киткән. Кала урамнарының да байтагы әле булса утын яга икән... Ярты Рәсәй кебек үк хәерче кала үзе, ә бер карак бай юл читенә ялт итеп торган хәрчәүнә-кафе төзеп куйган тәки. Аның ишек төбендә йөзләрен сакал баскан, кылка киемдәге «өлкән агайлар» ике-өч тәңкә теләнеп үзәгеңә үтә. Гаҗәеп мәмләкәт бу: әле Пугачев чорында да нәкъ шушындый ук мәгыйшәт хөкем сөргән...

Шушы Симнан соң 23 чакрым ара узгач, Кропачево янында, бер асфальт юл Екатеринбург каласына алып китә. Чиләбе трассасында юлның ике ягын да йә мәрмәр кыялар, йә тоташ урман капласа, монысының тирә-юнендә иркен дала һәм ак болытлы, зәп-зәңгәр күк йөзе. Беркадәр баргач та, тау битендә «Шайтан-Көзәй ыруы» дип таштан тезгән язу очрап кала. Тагын 7-8 чакрым узуга, «Салаватның туган төяге» дигән шундый ук күрсәткеч. Инде Салават районы эченнән барабыз, үзәге – Малаяз атлы бик зур авыл. Әмма «Салават төяге» дигән тылсым ычкындырмый гына бит, тиз арада барып, нык күрәсе килә. Ходайның рәхмәте дигәндәй, юлның икенче ягында ДПС билгесе куелган машина күреп алдык. Юлның уртасында тоташ сызык сызылуга да карап тору юк, кырт борылып, янәшәсенә барып туктадык. Кабинадан бер капитан атылып чыкты. «Нинди әрсезләр бу? Протокол төзеп, штраф чәпәмәем!» Мин юатам, гафу үтенәм инде, ләкин тел очымда бөтенләй башка бер гамь: «Салаватның туган төяге, дигән ошбу җиргә ничек үтеп була, анда ниләр бар?» – дим. Аңлаштык. Айрат атлы бу капитан әүвәл Малаязга, С.Юлаев музеена барырга киңәш итте. «Директоры Зилә атлы бик мөлаем ханым, сезнең кебек ерак юлдан килгән кунакларны озатып йөрми калмас», – дип өметләндерде дә әле...

● Тәкәй авылы урынында төзелгән таш тирмә.

Малаязга кергәндә, Салават һәйкәленең силуэты төшерелгән «капка» каршы ала. Район үзәге төзек һәм гаҗәеп чиста. Өр-яңа йортлардан авылның читендә бистә үсеп чыккан. Хәер, иске урамнарында да яңа йортларны санап бетергесез. Административ биналар, мәдәният сарае, кибетләр – һәммәсе дә «энәдән» генә төшкән. С.Юлаев музее үзәк урам түрендә, бик зур мәйдан биләп урнашкан. Әлбәттә ки, коймалар бик затлы, ихатага брусчатка түшәлгән, һәр тарафта Урал тауларыннан күчерелгән нарат, чыршы, сәрби, зирек агачлары. Уртада өч катлы мәһабәт бина һәм каршыда карашы белән күк йөзенә омтылган Салават һәйкәле. Биредә атна саен диярлек туган якка, башкорт милләтенә һәм Салават рухына багышланган митинглар, фестивальләр уза, сабый балалар һәм яшь буын шушында милләтпәрвәрлек рухы белән янып китә икән.

Инде кичке 18 сәгать булса да, музей түрендә безне Зилә ханым үзе каршы алды. Капитан Айрат һич тә арттырмаган, Зилә ханым бик ачык күңелле, газиз Башкортстанына һәм горур Салаваткa чиксез гашыйк бер җанатар икән. Эш сәгате тәмам, дип тә кисәтмичә, музей экспонатлары, тарихи документлар белән таныштырып чыкты, ә икенче иртәдә инде безне Салаватның туган төягенә алып китте. Шаккатмалы хәл бит: Салават туган Тәкәй авылы урыны нинди хилафлык беләндер Чиләбе өлкәсенә бүленеп бирелгән, ә ике чиктәш өлкә башлыклары былтыр күрешеп, шушы төбәкне кабаттан Башкортстан Республикасына кайтарып алган икән. Таулар әйләнәсендә урнашкан, үзәнлеге ашъяулыктай җәйрәгән бик тә матур төбәк. Элегрәк, әле Чиләбе өлкәсе җирләре булуга карамастан, биредәге бер як тау итәгенә кирпеч тирмә, карательләр тарафыннан яндырып юк ителгән авыллар исемлеге теркәлгән стенд һәм Тәкәй авылы урыны икәнен тәгаенләгән стела бастырып куярга өлгергәннәр. Ә хәзер инде Башкортстан хөкүмәте махсус карар кабул иткән, биредә Салават һәм Юлайга багышланган музей комплексы төзеләчәк, моның өчен асфальт юл салу эшенә әле быел ук керешәчәкләр икән...

● Йөрүзән елгасы буендагы кыяда Салават яшеренеп яткан мәгарә авызы.


● С.Юлаевның вафат булуы хакында Рогервик комендантының рапорты.



●Салават Е.Пугачев белән.

●Салават лагерь корып яткан Котыш авылының күренеше.

Бәхтияр ватанында

●Малаязда С.Юлаев музее.

●Музей директоры Зилә ханым белән без Тәкәй авылы урынына куелган стела янында.

Башкортстанның һәр төбәге җәза гаскәрләре белән тулып, Пугачев фетнәсе бастырыла башлагач Салават качып яткан мәгарә дә исән икән әле! Зилә ханым, һич тә иренмичә, Әлкә һәм Идрис авыллары аша безне Екатеринбург юлының уң ягында, Йөрүзән елгасы буенча тезелгән мәрмәр кыялар иленә алып китте. Биек бер кыя өстенә барып туктагач, гаҗәеп матур, әкияти панорама ачылды. Уртада йөгерек сулы, саллар агызырдай гайрәтле Йөрүзән боргалана. Елганың бер як ярында – тоташтан гел урман. Икенче ягында аксыл-соры, текә кыялар рәте сузылган, аларның өсләрендә дә тау-таш арасына тырнак-тамырларын батырган каен, нарат, чыршы урманнары. Алар арасында абага, кылган, аллы-гөлле меңәрләгән чәчәк, бөрлегән, җир җиләге. Фани дөньяның җәннәт дип аталган сихерле почмагына тиң табигать!..

●Салаватны әсирлеккә алу. М.Хуҗиев эше.

Чиләбе ягыннан агып килгән Йөрүзән читендәге кыяларның берсендә өч кара күз. Якынлашкач төбәлсәң, алар – өч мәгарә авызы. Шуларның берсендә татар писаре Габдерәшит Галиев белән бергә Салават качып яткан. Кыялар өстеннән мәгарә авызына өстәге каеннарга аркан бәйләп төшкән алар. Бүген инде ул мәгарә янына төшү өчен сукмак булдырганнар. Үзе нәзакәтле, үзе мөлаем Зилә ханым белән бергә мәгарә янына без дә төштек. Мәгарәнең авызыннан мүкәләп диярлек узасы, ә эчтә тураеп басарга да була. Тыштан кеп-кечкенә булып күренгән мәгарә кыя астында 92 метрга сузыла. Аңлашыла булыр: карательләр кыя өстеннән төшеп, Салаватны кулга эләктерә алмаган. Ләкин бездә сатлыкҗан кабихларга кытлык һичбер вакытта юк. Җәмгур белән Мөхсин атлы бертуган Әбдесәламовлар Салаватның чаңгы тагып чыгуын сагалап торганнар да, аны арканлап, җәзачы поручик Лесковский кулына илтеп тапшырганнар. Лесковский Әби патша әмере белән шундук капитан дәрәҗәсенә лаек булган. Ә Салаватның үзен туктаусыз сорау алулар һәм җәзалаулардан соң 7 урында – әтисе ярдәме белән бергә яндырган Сим заводында, Юлай һәм Ләк авылларында, Кызыл Яр – Красноуфимскида, Көнгер белән Уса калаларында һәм Елдәк крепосте янында, җәзачы подполковник И.Рылеевка каршы яу урынында 25 әр мәртәбә камчы белән тотып ярганнар да, борынын кисеп, яңаклары белән маңгаена «мөһер» сукканнан соң, әтисе Юлай белән бергә Балтыйк буендагы Рогервикка сөргенгә озатканнар. Юлай шунда – 1796, ә Салават 1800 елның 26 сентябрендә вафат булган. Икесен дә, мөселманча догалар укып, ләхеткә нәкъ Салават шикелле үк Пугачев бригадиры Канзафар Усаев (Хөсәенов) иңдергән... Шушы кыядан ерак түгел зур аланда кыш айларында атна саен диярлек «Салават чаңгысы» дип аталган бәйге үткәрелә, ул качып яткан мәгарәгә сәяхәтчеләрнең туктап торганы юк. Хәтта, шартына Идрис авылы янындагы чишмәдән көянтәләп су ташу да кергән, Салаватның икенче хатыны Зөлфия исемендәге чибәрләр конкурсы да шушында үткәрелә!..

Салаватны зурлау гына түгел, ә туган төбәгенә бирелгәнлек, газиз халкының һәрбер истәлеген энҗеләрдәй барлау һәм кадерләү хисен тәрбияли белүләренә тәмам шаккатасың! Уфа каласында Европадагы иң зур җайдак һәйкәле булып танылган Салават басып тора. Башкортстанда Салават районы гына түгел, шул ук исемдәге шәһәр дә бар. Аерым бер театр, спорт командалары, дистәләгән фестиваль һәм конкурслар Салават исеме белән атала. Шул ук вакытта Татарстанда яки Башкортстанда Пугачев гаскәрендә Салават белән бердәй бригадир дәрәҗәсенә ирешкән Канзафар Усаев, Бәхтияр Канкаев, Ярмөхәммәт Кадермәтов кебек татар каһарманнарының исемнәрен йөрткән сыңар тыкрык та юк, аларның батырлыгын бүген мең кеше дә белми!..

Салават төбәгеннән соң Мәсәгуть (Дуван районы үзәге), Котыш, Ахун авыллары, атаклы Янган-Тау санаторие янынннан туктый-туктый үттек, үзебез дә белмичә, Котыш һәм Ахун табигатен фотоларга төшердек. Рәми Гарипов җырларга күчергән Каратауның, Әй һәм Йөрүзән елгаларының гүзәллеге таң калдырды. Татарстан – җәннәт бакчасы, дип лаф орсак та, Башкортстан табигате биш баш өстен икән. Мәчетле районының үзәге булып торган Олы Ыктамак авылы да берьюлы ике елга суы белән каршы алды. Баш ваттык, сораштык – һични аңламадык. Олы Ака авылы ягыннан сузылган елга Ака булып агып килә дә, кечкенә бер инеш белән кушылгач, нинди хикмәттәндер Ыкка әверелә, әмма 5-6 чакрым да агарга өлгермичә, нәкъ район үзәгендә Әй елгасына килеп кушыла һәм алга таба Әй булып дан ала. Ака дигән ат урыс килмешәкләренең үтенә ярамаганмы, әллә географияне белүләре үтә чамалымы – нәтиҗәләр чыгарырлык түгел. Шунысы хак: мондагы вакытлыча Ыкның Татарстан җире буйлап аккан ярсу Ыкка һичбер катнашы юк...

(Дәвамы киләсе санда).

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

Саф сулы ямьле Саба

Шушы көннәрдә «Саф сулы ямьле Саба» проекты кысаларында үткән «Җир ананың зәңгәр күзләре» бәйрәмендә миңа да катнашырга насыйп булды. Саба районының Кече Шыңар авылын нигезләгән бабакайлар да Челтер чишмәне, аның гаҗәеп матур тирәлеген яратып шул урында яшәп калганнардыр.

Шыңарның дүрт кенә йорттан торган Чишмә урамында берничә дистә ел элек кенә берсеннән-берсе уңган 11 кыз үскән. Алар кул эшләренә дә, аш-суга да оста булган. Урамнары белән кич утырып кул эшләре тотканнар, оекбашлар, шәлләр бәйләгән, сөлге, кульяулык чиккәннәр. Сабан туенда аларның бүләге өчен ир-егетләр бил алышкан. Шыңар көрәшче, җырчы егетләре белән дан тота. Алар мәйданга чыгып бил алыша, сәхнә түрендә җыр суза. «Җир ананың зәңгәр күзләре» дигән бәйрәмгә дә Челтер чишмә янына авыл белән чыкканнар. Чишмә урамындагы дүрт йортның берсендә Зөләйха апа белән Бөек Ватан сугышы ветераны Габдерәүф абый Нуриевлар гомер кичергән. Ул Оренбургтан мамык алып кайтып, авылның шәл бәйләүчеләрен чимал белән тәэмин иткән. Аннары Габдерәүф бабай авылда мәчет салдырган. Челтер чишмә тарихы белән Нуриевларның бишенче кызы, җиденче дистәсен тутырырга өлгергән Розалия таныштырды. Олы елга тавы итәгендә кайнап өскә күтәрелгән Челтер – бик борынгы чишмә. Ул – үзенчәлекле, агып чыкмый, ә өскә кайнап күтәрелә. Габдерәүф абзыйга әби-бабалары сөйләгәнчә, чишмә ургып чыккан бу урын башта мул сулы, киң күл рәвешендә булган. Каз-үрдәкләрне дә ике яктан таяк белән генә куып чыгара алганнар. Тора-бара ул күлне инеш итеп ерып, суның кайнап чыккан урынының һәм агымы кырыйларын ташлы балчык салып күтәрткәннәр. Бу 200 еллар чамасы элек була. Күпмедер вакыт үткәч, 1930 елларда чишмә артындагы таудан балчык ишелеп, чишмәне каплый. Авыл сусыз кала. Халык ул вакытта Олы Шыңарның чакрым ярым ераклыктагы чишмәсеннән эчәр су алып кайта. Бергәләп, чишмәне балчыктан арындырып, аңа тәбәнәк кенә агач бура куялар, түбәсен рәшәткә сыман итеп ябалар. Розалия ханым шушы чишмә буенда уйнап, агымын яланаяк ерып үскән, салкын да тимәгән, тамак авыртып каяндыр кайтканда, салкын суын эчкәч, савыгып китә торган булганнар. Чишмәнең улагын ерганнан соң, ул ике елга бергә кушылган Ташулык суына коя да, авылны Югары һәм Түбән очларга бүлеп, Мишәгә килеп кушыла. Элекке елларда суыткычлар юк иде бит. Чишмә шушы тирәдә яшәүче кешеләр өчен сөт ризыкларын саклау урыны да булган, аның агымы буйлап сөтле, каймаклы, эремчекле чиләкләр тезелеп киткән. Чишмә корылмасын соңгы тапкыр 1998 елда яңарталар. Әмма аңа кояш керә торган урын калмый, түбәсен каплыйлар.

Бу көнне тирә-ягы чистартылган, матурланган, бизәлгән Челтер чишмә янында авылның борынгы гореф-гадәтләре искә төшерелде. Рәзинә Нуриева әнисе Зөләйхадан өйрәнеп калганча «Таң суы» алу йоласын күрсәтте. Аның балаларга күз тигәннән, өлкәнрәкләргә төрле чирләрдән шифасын күрәләр. Таң суы атнага бер тапкыр чәршәмбе көнне иртәнге намаздан соң кояш чыкканчыга кадәр алына. Өйдән бисмилланы әйтеп, Аллаһыдан авыруның чирләрдән савыктыруын сорап, салаватлар, мактау сүзләре әйтеп, чишмәдән 41 чүмеч су тутырыла, җиде сүрә укыла.

Чишмә кайчандыр бер-берсен сөйгән ярларның очрашу урыны да булган. Бу көнне яшьләр чишмә янында «Вәгъдәләшү» йоласын да яңартты.

«Тәбә» күренеше яшьләрнең кичке уеннарын искә төшерде. «Самавыр агарту», «Су алу» гадәтләре бик күпләрне балачагына кайтарды. 81 яшьлек Наилә апа Нигъмәтҗанова исә ишле гаиләгә килен булып төшкән чагын хәтерләде. «Шушы чишмәдән җидешәр көянтә су алып менә идем», – дип истәлекләргә бирелде ул.

Авылның төбәкне өйрәнүчесе Айдар Гарипов Шыңар тарихын барлап хезмәт язып чыгарган. Ул бәйрәмдә авылның тарихы белән таныштырды. Тарихчы авылның нигезләнүен Казан ханлыгы чорына бәйли. 1524 елга караган кабер ташы да Шыңарда саклана. Айдар әфәнде бу якларда элек тоташ урманнар булуын да искәртеп үтте. XVIII гасырда да Кече Шыңар урманы Петр беренче тарафыннан исәпкә алынган, корабльләр төзетү өчен махсус реестрга кертелеп, дәүләт карамагына тапшырылган була. Җирле шагыйрә Гөлсинур Галәвиеваның Шыңарга багышланган шигыре якташлары тарафыннан яратып кабул ителде.

«Җир ананың зәңгәр күзләре» – Саба районында үткәрелгән 23нче чишмә бәйрәме икән. «Саф сулы ямьле Саба» проектының авторы – Саба китапханәләр системасы директоры, районның «Ак калфак» оешмасы җитәкчесе Ләйсән Билалова. Ул 2020 елда китапханәчеләр, «Ак калфак» оешмасы әгъзалары белән бергә авылларның тарихын өйрәнүгә юнәлдерелгән «Ямьле Саба» проектын эшли. Аны бу эшкә балаларыбызның үз туган яклары тарихларын начар белүе кебек хәл этәрә.

«Ямьле Саба» проектның бер юнәлеше экологияне яхшыртуга – чишмәләргә багышланган була. Ул вакытта күп кенә чишмәләр чүп-чардан арындырыла. Әмма аларга әле барыбер игътибар тиешенчә күрсәтелми. Хәтерләсәк, 2021 ел бик коры килде. Чишмәләр яздан ук инде кибә башлады яки суларын азайтты. Ләйсән ханым Экология министрлыгында эшләүче тормыш иптәше Ришат Билалов белән дә бу хакта борчылып сөйләшә, бергәләп Саба районында элеккеге чишмәләр исәбен һәм бүгенге көндә күпмесе сакланып калуын карыйлар. Кызганыч ки, бик күп чишмәләрнең юкка чыгуы ачыклана. Чишмәләрне чистарту һәм аны авыл халкы бәйрәме итеп гөрләтү Мишә елгасы башланган Мишәбаш авылыннан башлана. Ул бик күңелле үтә, әмма 38 градус эсселек барысын да хәлсезләндерә. Шунда көтелмәгән хәл була. Арыган китапханәчеләр эш урыннарына килеп керү белән, әллә каян гына болыт килеп чыга, көчле яңгыр башлана. Шушы рәвешле, елга агымы буйлап төшеп, 22 авылда 122 чишмә чистартыла, төзекләндерелә, авылларда «Җир ананың зәңгәр күзләре» бәйрәмнәре гөрли. Озакламый чишмәләрнең төгәл урыннары күрсәтелгән, кемнәр карап торганы, тарихлары тупланган җыентык та чыгарыла.

Шундый хәл дә була. Бер авылның китапханәчесе «Безнең авылда үткәреп булмый, чөнки чишмәләр беткән, алар юлын үзгәрткән», – ди. «Авылыгызның муллasы бик акыллы кеше, аның белән киңәш әле. Сезнең авылда чишмә булырга тиеш», – ди Ләйсән ханым. Китапханәче бу арада авыл халкының хәзрәт белән берлектә атна саен басуга чыгып, яңгыр теләп, намаз укулары турында сөйли. Л.Билалова аларга башта чишмәләрне карарга киңәш итә. Авыл кешеләре юллары үзгәргән ике чишмәне чистартып, элекке урынына кайтаралар. Аның берсе мәчет акчасына тәртипкә китерелә, икенчесен шушы авылда чишмә янындагы йортта үскән ир-егет тулысынча үзе төзекләндерә. Шулай итеп бер авылда ике чишмә ачылышы уздырыла. Иштуганда халык белән очрашканда авылда кайчандыр өч чишмә булуы, әмма аларның юкка чыгуы, урыннары да билгесез икәнлеге ачыклана.

Шыңардагы кебек суы астан кайнап чыга торган чишмә Туктар авылында да бар икән. Т.Низаминың җырына кергән шул Җамалый чишмәсе чыкмый башлый. Авылда «Җир ананың зәңгәр күзләре» бәйрәме буласы көнне, кичтән чишмә булмый. Бәйрәмне башкасы янында үткәрергә килешәләр. Бәйрәмгә килүчеләр икенче чишмә янына барып җиткәндә, Җамалый чишмәсенең бәреп чыгуы турында шалтыраталар. Авылның бер апасы чишмәгә төшә, аңа карый да утырып елый. «Чишмә суың белән гомер иттек. Син дә юкка чыктың, без дә олыгайдык. Син кая киттең?» – ди. Гаҗәп хәл, чишмә бәреп чыга. Бәйрәм Җамалый чишмәсе янында үтә. «Авыл кешесенең чишмәгә карап елаганын шунда күрдем», –ди Л.Билалова. Аның үзе белән дә гаҗәеп хәл була. Ул, тез башлары авыртып, берчак култык таяклары белән йөрүгә кала. «Чишмәләр янына барасым килде», – ди ул. Хәзер инде ул кайсы чишмә янында таякларын ташлаганын хәтерләми.

«Саф сулы ямьле Саба» проекты берничә өлештән тора. Икенчесе чишмә буенда элек уйналган уеннарны, гореф-гадәтләрне кире кайтарып, халыкка күрсәтүгә юнәлдерелгән. Аккалфаклылар һәм мәдәният хезмәткәрләре аны халыкның үзе катнашында эшли. Чишмә белән бәйле барлык гореф-гадәтләр, йолалар, уеннар аерым җыентык итеп чыгарылган. Проектның өченче максаты – шушы чишмә суын эчеп үскән якташ язучыларны барлау. Аларны кайтарып, халык белән очраштырып, әсәрләрен тыңлату. Сабалыларның «Саф сулы ямьле Саба» проекты Татарстан экология министрлыгы тарафыннан игътибарга алынып, «Эколидер» конкурсына тәкъдим ителә һәм җиңү яулый. Нәтиҗәдә башка районнарда да, сабалар проектын үрнәк буларак кабул итеп, чишмәләрне карау башлана. Әйтик, Тукай районы 2022 елны Чишмәләр елы дип белдерде. Балтачлылар да проект белән кызыксынган. Проект аккалфаклылар күңеленә дә хуш килгән.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Аргы ярда әле көмеш җырлар,
Елларның да аргы ярында,
Чыдар микән йөрәк ахыргача
Җырлаганчы шуның барын да?
Зөлфәт.

Шигъриятнең Зөлфәтле чоры

Шагыйрь Зөлфәт белән без яшьтәшләр, Казан университетына да укырга бер вакытта, 1965 елда кердек. Ул – татар бүлегенә, мин – журналистикага. Икебез ике бүлектә укысак та, бер бүлмәдә яшәргә туры килде. Бераз соңрак Казанның Бауман урамындагы Матбугат йортында ул – «Чаян», мин «Ялкын» журналында икебез бер катта, янәшәдә генә эшләдек. Редакцияләр Декабристлар урамындагы яңа йортка күчкәч тә 9 нчы катта бүлмәләребез күрше иде. Бер заманны икебезгә дә Мәскәүнең Әдәбият институтында белем эстәргә туры килде. Кыскасы, кырык ел буе Зөлфәт белән бергә каләм чарлап, фикер алышып яшәдек. Шуңа аны яхшы беләм, үземне аның яшәү рәвеше, уй-фикерләре, кылган гамәлләреннән хәбәрдар дип саный идем...

Инде язганымча, укырга кергәч, безне Кызыл Позиция урамындагы тулай торакка җибәрделәр. Миңа урыны беренче каттагы егерме җиденче бүлмәдән тәгаенләгәннәр иде. Килеп урнашуым булды, ишекне хуҗаларча киереп, башын югары чөеп, шаян-шук кыяфәтле егет килеп керде.

– Мин – Зөлфәт, Мөслимчә әйтсәк, Дөлфәт булам, Дөлфәт Маликов, – дип беренче булып сүз башлады ул.

Кыяфәтеннән, сөйләү рәвешеннән, үзен иркен тотуыннан аның гадәти авыл малае булмавы күренеп тора иде. Гәүдәсе без киноларда гына күргән балет артистларыныкы сыман төп-төз, ә чәчләре Пушкинныкы сыман шагыйранә бөдрәләнеп, дулкынланып тора. Менә шушы беренче очрашудан соң, безнең юлларыбыз гел янәшә барды. Әмма үзен бик яхшы беләм кебек тоелса да, Зөлфәт турында истәлек язу ансат түгел икән. Аның «Йөрәгемне былбыл чакты» китабын 75 яшьлек күзләрем белән тагын бер кат укып, бүгенге рухым, кальбем, тәҗрибәм һәм акылым аша үткәргәч, шактый вакыт кулга каләм тота алмадым. Баксаң, элегрәк мин, яшьлегем беркатлылыгы белән, Зөлфәт шигырьләренең өскерәк катламын, диңгез өстендәге ярсу дулкыннарын гына күргәнмен, иксез-чиксез диңгезнең төбенә төшеп җитә алмаганмын икән. Зөлфәтне кат-кат укыган саен, мин ул диңгезнең никадәр тирән икәнлеген, аның төбенә беркайчан да төшеп җитеп булмаячагын аңлый бардым. Шигырь турында сөйләп, аның тылсымлы серен гади сүзләр белән аңлатырга тырышу – өметсез шөгыльдер. Әнә, Зөлфәт үзе дә: «Бу бөек серне аңлатырга адәм баласының көче җитми», – дип язган бит. Шуңа күрә аның иҗат дөньясы белән таныштыруны үзенең шигырьләренә калдырып, истәлекләргә күчик әле.

Әллә безне кемдер махсус сайлаган инде, тулай торагыбыз бүлмәсенә, ни гаҗәп, гел шагыйрь рухлы, иҗади ялкынлы шәрекътәшләр туры килгән иде. Зөлфәт инде мәктәптә укыганда ук «хәлфәсе» шагыйрь Рәдиф Гатауллиннан шигърият дәресләре алып, «яшь шагыйрь» дәрәҗәсенә ирешеп килгән иде. Мин дә шигырьләр язам, якташым Мөдәррис Әгъләметдинов белән Чаллы әдәби берләшмәсенә йөреп шактый тәҗрибә туплаган, шигырьләремне район һәм республика газеталарында бастыра башлаган идем. Ишек катындагы капа-каршы караватларны биләгән Мөслим ягы егете Фәрит Гыйльметдинов Әмирхан Еники калыбына салыбрак матур-матур хикәяләр яза, ә педант холыклы, үтә дә тәртипле Рәфикъ Юнисов «акыллы шигырьләр» чыгарып кына калмый, бездән шактый өлкәнрәк булуы сәбәпледерме, һәрчак гаделлек сагында тора, дөрес яшәү үрнәкләре күрсәтә иде.

Без – дүртебез дүрт төрле, дүрт холыклы, әмма хыялыбыз уртак – бары тик «шедеврлар» гына иҗат итү һәм әдәбиятның түр башыннан урын алу. Атаклы полководец Суворовның «Плох тот солдат, который не мечтает быть генералом» дигән канатлы сүзләрен Зөлфәт бүлмә түренә, тәрәзә өстенә зур хәрефләр белән русчалатып язып та куйды.

Арада иң романтик рухлыбыз, шагыйранә холыклыбыз, һичшиксез, Зөлфәт булгандыр. Беренчедән, ул үзенең укымышлылыгы, татар, рус һәм дөнья әдәбиятыннан яхшы ук хәбәрдар булуы белән һәммәбезне дә шаккатырды. Аның хыял офыкларының, фантазиясенең чиге-кые юк. Зөлфәт тәкъдиме белән безнең бүлмәдә шигырь язу ярышлары үткәрелә башлады. Ниндидер тема яисә вакыйга тәкъдим ителә дә без аңа бер сәгать эчендә өр-яңа шигырь язарга тиешбез. Ә тулай торагыбызда шигырь җене кагылган студентлар бик күп. Без ярыша-ярыша язабыз, аннары шигырьләребезне кычкырып укыйбыз. Студентлардан торган жюри аларга бәя биреп, урыннар билгели. Җиңүчеләргә бүләк-китаплар тапшырыла. Бу шигырьләргә салынган фикерләр ул заман өчен артык кыю булганга, аларның газета-журналларда басылуына өметебез юк иде. Шулай да чарасын таптык, үзебезнең бүлмәдә дивар газетасы чыгара башларга булдык. Зөлфәтнең рәсем ясау осталыгын белгәч, аңа газетаны бизәү эшен дә тапшырдык. (Алга китеп әйтим: соңрак ул минем кулъязма җыентыгымдагы шигырьләрнең һәрберсенә Пушкинчарак итеп иллюстрацияләр-сурәтләр ясады. Ул кулъязмамны әле дә кадерләп саклыйм.) Газетабызга яңгыравыклы «Фанатик» исеме куштык. Безнең «башкитәрлек» фикерле шигырьләребез, кечкенә парчаларыбыз, университеттагы тәртипләр турында тәнкыйть мәкаләләребез һәм Зөлфәтнең шаян-шук рәсемнәре белән тулган газетабызның даны тиздән бөтен тулай торакка таралды. Аны күрү һәм уку өчен, кем әйтмешли, «халык чират тора». Ә безнең егерме җиденче бүлмәбез инде күптән шау-шулы шагыйрьләр салонына әверелгән иде. Тирә-юньне шаулаткан хыялый кичләребезнең, романтика тулы иҗади тормышыбызның нәтиҗәсе шул булды: икенче курста укыганда Зөлфәт белән икебезгә тулай торакта урын табылмады...

Мин әле бүген дә Зөлфәтнең яшәү, иҗат итү, фикерләү рәвеше турында уйлаганда аның күңел байлыгының, үзе әйтмешли, «күңел тарихының, күңел географиясенең» иксез-чиксез офыкларын күздән кичергәндәй булам. Шигырьне, шигъриятне һәркем үзенчә аңлый, үзенчә шәрехли, үзенчә кабул итә. Зөлфәтнең һәр шигырьгә, һәр образ, фикер һәм һәр шагыйрьгә үз мөнәсәбәте, үз ачкычы бар иде. Ул бөек испан шагыйре Гарсиа Лорка шигырьләрен татарчага тәрҗемә итәргә тәкъдим ясагач, бераз аптырап та калган идем. «Мин аның шигырьләрен русча да рәхәтләнеп укыйм, аңлыйм һәм үз итәм», – дидем. Икебез аерым-аерым тәрҗемә иткән «Гитара» шигырен бергәләп сүтеп җыйгач, мин Лорканы үзем өчен өр-яңадан ачтым, моңа кадәр таныш кына белгән шагыйрь иҗатына чын-чынлап гашыйк булдым. Ә моның сәбәпчесе Зөлфәт иде. Университет лекцияләреннән кайткач, безнең бүлмәдә шигърият дәресләре башлана. Без бер-беребезне уздыра-уздыра Тукай, Такташ, Туфан шигырьләрен укысак, Зөлфәт кунакка килгән «хәлфәсе» белән бергәләп Гейне һәм Бернс, Уитмен һәм Альберти әсәрләре белән дә таныштыра иде. Шулай итеп, алар безне әкренләп дөнья шигъриятe дәрьясына алып кереп китте.

Көннәрдән бер көнне ул мине тулай торагыбыз янәшәсендәге туберкулез диспансерына әдәби очрашу уздырырга алып китте. Шул хастаханәдә эшләүче табибә белән танышып, очрашу үткәрү турында килешеп тә куйган икән. «Анда йогышлы авырулардар бит. Нигә алар янына барасы иттең?» – дигәч, ул серле елмаеп болай диде: «Алар да авыру, без дә... Алар туберкулез белән хасталанса, без – шигърият белән. Ә хаста кешенең күңеле нечкә була. Ике хаста бер-берсен аңлый ул. Аларның авыруы безгә йокмас, ә безнеке, бәлки, кемгәдер йогар. Шигырь тыңлагач, бәлки, авыруларның күңелләре бераз савыгып китәр. Шигырь тылсымы бик көчле дәва бит ул».

1968 елда Татарстан Язучылар корылтаенда Г.Камал театры балконыннан яшьләр журналы сорап листовкалар чәчү турында инде бик күп яздылар. Аңа кадәр дә татар яшьләре өчен журнал ачу кирәклеге турында Казан һәм Мәскәү җитәкчеләренә кат-кат мөрәҗәгатьләр юлланган иде. Тик нәтиҗәсе генә булмады. Ә бер көнне мине Язучылар корылтаена җибәрүне сорап Мәскәүнең Әдәбият институты ректорына хат килеп төште. Студент һәм яшь шагыйрь буларак, корылтайда чыгыш ясарга да тәкъдим иткәннәр иде. Әмма, Казанга кайткач, төрле республикалардан һәм Мәскәүдән, үзебезнең республикадан бик күп зур кунаклар катнашу сәбәпле, миңа вакыт җитмәвен искәрттеләр. Инде нишләргә? Матбугат йортында Зөлфәтне очраттым да аның белән элек үзебез яшәгән тулай торакка юл тоттык. Исәбебез – минем чыгыш ясар өчен әзерләнгән текстымны корылтай делегатларына, зур җитәкчеләргә җиткерү иде. Ә анда төп сүз – әлеге дә баягы яшьләр журналы ачу таләбеннән гыйбарәт! Баштарак безнең фикеребез аны,ничектер ишәйтеп, театр ишеге төбендә һәр кергән кешегә тарату иде. Әмма, уйлана торгач, тәртип саклаучылар моңа ирек бирмәс дип, башкача эшләргә булдык.

Тулай торактагы дус-иш, таныш-белеш студентларны әлеге атаклы егерме җиденче бүлмәгә, Рәфикъ Юнисов янына җыеп, минем чыгыш текстын ак кәгазьгә күчереп яза, ишәйтә башладык. Ул заманда безнең язу машинкабыз да юк, ксерокс, компьютер турында да ишетеп кенә беләбез. Берәү текстны кычкырып укый тора, башкаларыбыз шуны ак кәгазьгә күчерә. Арада үзеннән өстәп язучылар да булган. Таң атканчы берничә йөз данә әзерләгәч, аларны өч өлешкә бүлеп, куенга кыстырдык та Зөлфәт, аның курсташы Мирза һәм мин Камал театрының ул вакытта М.Горький урамындагы бинасына юл тоттык. Шыпырт кына икенче катка менеп, Зөлфәт – сул, мин уң яктагы, ә Мирза арткы өлештәге балконнарга кереп утырдык. Һәм корылтайның иң кызган вакытында, бүгенге матбугатыбызның аяныч хәлдә булуы, революциягә кадәр татар телендә утызлап газета-журнал нәшер ителеп тә, бүген аларның саны бер дистәдән артмавы турында язучы Рафаэль Мостафин ачынып сөйләгәндә, без өчебез өч яктан өндәмәләребезне залга сибеп җибәрдек. Моңа кадәр күрелмәгән мондый хәлгә зал аптырап тын калды, президиумдагы җитәкчеләр үзара чыш-пыш килә башлады. Корылтай эше тукталды, тәнәфес игълан иттеләр... Бу вакыйгадан соң башларыбыздан сыйпамадылар, билгеле, әмма күп вакыт та узмады, татар яшьләре өчен «Идел» журналы чыга башлады.

Зөлфәт турындагы хатирәләрне бик озаклап, тәфсилләп дәвам итеп булыр иде. Чөнки аның искиткеч мул «күңел тарихы, күңел географиясе» белән бергә гаҗәеп бай тормыш биографиясе дә бар. Ә Зөлфәт дөньясын аңлау өчен аның шигырьләрен укырга, аның иҗаты белән таныш булырга кирәк. Кыскасы, Зөлфәт дөньясының ачкычы – аның иләһи рухлы әсәрләрендә.

Татар шигъриятенең Тукайлы-Дәрдемәндле, Такташлы-Туфанлы чорын беләбез. Ә безнең буын аның Равилле-Рәдифле, Мөдәррисле-Зөлфәтле чорында яшәде һәм иҗат итте.

Разил ВӘЛИЕВ,
Татарстанның халык шагыйре.

Минвәгыйз ЗӘЙНЕТДИНОВ

Икебез дә дөрес юлдан

●Университетта бергә укыган группадашлар ун елдан соң очрашкач. 1969 ел.

1954 елның август азагы. Керү имтиханнары тәмамланды, приказлар эленде. Без хәзер Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентлары.

Күңелләр күтәренке. Тулай торакта урын да бирделәр. Әмма минем укуны башлап җибәрүем шик астында. Чөнки җиде имтиханның берсен – рус теленнән язма эшне «өчле» билгесенә тапшырган идем. Андыйларга стипендия каралмаган икән. Булачак сабакташларым Зоммер Гыйләҗев белән Альберт Фәтхиев тә шундый ук хәлдә булып чыкты. Ярый әле Зоммерның әнисе һәм апасы укытучылар, азмы-күпме ярдәм итәрлек мөмкинлекләре бар. Без Альберт белән крестьян балалары, сирәк-мирәк кенә авылдан бәрәңге, йомырка җибәргәннәрен көтсәк кенә шул.

Акчам булмау, Казанга паспортсыз, авыл Советының бер айлык белешмәсе белән генә килү сәбәпле, имтиханнар беткәч, туган авылым Лашманга да кайта алмадым. Идел буенда бер атна таш бушаттым. Яшәрлек акча эшлим, янәсе.

Тәбәнәк буйлы, сабый йөзле Альберт дустым ничек яшәде, үткәрде икән бу көннәрне?

Бер акыллысы, университетның проректоры Әхмәдулла абзый Шәфигуллин янына керергә тырыш, ул үзе дә ятимлектә, мохтаҗлыкта үскән, әле якташың да икән, дип киңәш бирде. Гариза яздым. Бу хакта Альбертка да әйткәнмендер инде. Ул да, гаризасын язып, миңа иярде. Шулай итеп без башта проректорда, аннан факультет деканында булдык. Ялварып үтенүләребез бушка булмады – кафедра мөдиребез Хатыйп ага Госман бер көнне безнең икебезне үз бүлмәсенә чакырып: «Кайгырмагыз, сезгә дә стипендия биреләчәк», дип куандырды. Иптәшләребездән бер айга соңарып, октябрь азагында без дә шул акчаны алуга ирештек.

Без беренче курста укыганда, кемнең инициативасы булгандыр, хәтерләмим, бер-беребезгә теләкләр әйтү дәфтәре ачып җибәргән идек. Альберт дустыбыз турында да анда язма фикерләр бар. Шуларны укыйм да хәйран калам – Альберт Фәтхиевнең фән юлыннан китәсен тоемлаганбыз бит! Бераз шаяртыбрак та, аның күңелен үстерү нияте белән дә әйтелгәндер бәлки ул теләкләр:Фәсыйх Хисмәтуллин (Фаяз Дунай): «Альберт, син тырыш, күп нәрсәне белергә омтылучан егет. Алга, биеккә, фән баскычларына эре адымнар белән атлап бар. Дустың Фәсыйх».

Лена ГАЙНАНОВА

Кыеп төшергәндәй кинәт өзелде...

Альберт Фәтхиләр бездән бер курс алда укыды. Шул ике курстан берничә студент факультетта «Әдәби сүз» дигән стена газетасы чыгара торган идек. Ул чагында аспирантурада укыган Альберт абый Яхин газетаның баш редакторы, ә без – редколлегия әгъзалары. Альберт абый бик шәп оештыручы иде. Газетаның һәр саны аның башында инде эшләнгән була, бергә җыелып шул планны тикшерәбез, үзебезчә яңартабыз, өстибез. Җитәкчебез мәкаләләребезне безнең алдыбызда ук редакцияли, киңәшләрен бирә. Юморга күбрәк урын бирелә. Калын кәгазьгә мәкаләләр ябыштырылып беткәч (анысын кызлар башкара), рәссамнарыбыз Альберт Фәтхи белән Илдар Әүхәдиев бизәргә тотыналар. Бу осталарның кулы тигән һәр урын ачылып китә, газетабыз матурлана, камилләшә бара.

Газетаны чыгарганда әллә күпме мәзәк сөйләнә, кычкырып көлешәбез. Альберт Фәтхи дә: «Безнең авылда...» дип мәзәкләр сөйли, үзе дә өзек-өзек иттереп рәхәтләнеп көлә.

Университетта татар бүлеге оешканнан бирле чыгып килгән «Әдәби сүз»нең йөзенче санын безгә хәзерләргә насыйп булды. Ул шундый купшы, бай эчтәлекле булып чыкты ки, «Эх, бу сан саклансын иде берәр җирдә», – дип кече Альбертның әйтүе булды, өлкән Альберт: «Саклап була аны, бары тик фотога төшерергә кирәк», – диде. Юбилей санын тотып барып, Бауман урамындагы «Фотография»дә барыбыз бергәләп рәсемгә дә төштек. Шулай итеп, ике Альберт белән бергә алдырган бик кадерле истәлек рәсемебез бар безнең.

Яшь чагында Альберт Фәтхи бик чибәр иде. Күз алдыгызга китерегез: ак йөздә зур соры күзләр, ә керфекләр, кашлар, чәчләр чем кара. Альбертның чибәр генә, тыйнак бер кызга күзе төшеп йөрүен белә идек. Кая ул хисләрен белдерү! Шул туташ тирәсендә бөтерелгән егетләр боҗрасы аша гына, тын гына, күзләре белән генә иркәли иде ул мәгъшукасын. Гомумән, Альберт эчке дөньясын бик ачып бетерми, эмоцияләрен бик тышка чыгармый иде.

Укуны тәмамлап берничә ел узгач, миңа эшем буенча университет китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегенә даими рәвештә мөрәҗәгать итәргә туры килә иде. Утыз ел шул «Әбүгалисина мәгарәсе»нә йөрдем. Университет китапханәсенең бу бүлеге хуҗасы Альберт Фәтхи килгән саен: «Нихәл? Нәрсә кирәк иде? Хәзер кемне эшлисең әле? Беләсеңме, бер кызык фикер бар...» – дип, һичшиксез, берәр яңа әйбергә игътибарыңны юнәлтеп куя. Яисә «шовинистлар, маңкортлар бик зур көч. Исхакыйның бер генә җыентыгын булса да чыгарып кал, дөньялар кирегә дә китәргә мөмкин» – дип, күңелгә шом да сала иде. Мин Г.Исхакыйның үзем элек эшләп куйган әдәби әсәрләре текстларын оригиналлары белән чагыштырыр өчен шул бүлеккә йөри башлагач та, Альберт гомер буе үзе белән бергә эшләгән Диләрә Абдуллинага: «Син китапларны Ленага өенә бир, безнең китапханә режимы белән генә эшләп утырса, эше бик озакка китәр бит», – дип әйтеп куйды. Ә Исхакый китаплары китапханәнең махсус фондыннан ачык фондка 1988 елда чыгарылган иде. Бер елдан соң, чираттагы килүемдә, Альберт һәм Диләрә мине шатлыклы хәбәр белән каршыладылар: кырыгынчы елларда Тел, әдәбият һәм тарих институтында сакланган берничә китапны әлеге бүлеккә тапшырган булганнар. Очраклы рәвештә шулар килеп чыккан. Алар арасында Исхакыйның бу китапханәдә булмаган «Ул әле өйләнмәгән иде» хикәясе дә бар. Ул хикәянең тулы нөсхәсен беренче күрүем иде.

Ике татар профессоры Исхакыйны шпион дип, Гитлерга хезмәт иткән дип язып чыккач, без өчәүләп – Альберт, Диләрә һәм мин сүз куештык: дөньялар кирегә үзгәрсә, Исхакый кайта алмаса, әзерләнгән әсәрләрне томнарга бүлеп, кайчан, ничек әзерләнүе турында язып, китапханәдәге борынгы шкафларга биклибез дә куябыз. Хөррият килгәнчегә кадәр.

1991 елда «Зиндан» җыентыгы чыккач, китапны иң башта шул «мәгарә»дәге теләктәш дусларыма Альбертка һәм Диләрәгә бүләк иттем. Китапны укып чыккач, Альберт: «Җыентык акыллы төзелгән», – дип бәя биреп куйды.

«Үзгәртеп кору» дигән нәрсә Альбертка кагылмады шикелле. Чөнки аның тәүбә итәсе эшләре дә, «үзгәртеп корыласы» да юк иде. Ул студент елларыннан ук аңлы рәвештә милләткә йөз белән баскан кеше, милләтпәрвәрлек, шул юлда фидакярлек – аның төп сыйфаты булды. Нәкъ шуның өчен кыен ашады да! Ул иллюзияләргә бирелми, «ура» кычкырырга ашыкмый. Яртылаш бөкрәеп, кулъязмалар өстенә иелеп эшләп утыруын гына белә. «Мәгарә»сендә муенына шарфы ураулы, үзе һаман томаулы булыр иде. Җәйге эссе көннәрдә дә җылынмый торган калын таш диварлар, салкын таш идән аның җелеген суырадыр кебек иде...

Татардагы өч-дүрт чын археографның берсе булган Альберт Фәтхинең хыяллары зурдан иде. Ул байтак эшләрен төгәлләргә өлгерә алмый дөнья куйды.

Һәртөрле дәрәҗәләргә, малга кул селтәп, үз эшенә җаны-тәне белән, фанатикларча бирелгән, энә белән кое казып, милләткә бәяләп бетерә алмаслык игелек эшләгән, әмма кадерсез булган фидакярләрнең гомерләре кыеп төшергәндәй кинәт өзелүчән. Мин шундыйлар рәтенә әдәбият галиме Рашат Гайнановны да, тел галиме Искәндәр Абдуллинны да кертер идем.

Май, 2007 ел.

Истәлекләр «Альберт Фәтхи» китабыннан алынды.

●«Әдәби сүз» стенгазетасының 100 нче саны чыгу уңаеннан төшелгән фото. Утырганнар (сулдан уңга): Лена Гайнанова, Нурия Рәхмәтуллина, Зәйтүнә Габбасова; басканнар: Рәшит Зәкиев, Шәйхи Садретдинов, Марсель Васильев, Илдар Әүхәдиев, Альберт Яхин, Альберт Фәтхи. 1958 ел.

«Хатын-кыз гаиләне тәрбияли, гаилә аша милләтне тәрбияли».
Роза Туфитуллова.

Роза ханым Гөлсеме

Ульяновск өлкәсенең Чардаклы район китапханәсендә Роза Туфитуллованың «Язмыш җиле» исемле китабын халыкка тәкъдим итү кичәсе узды. Китапханәне татарның милли мирасын тәшкил иткән борынгы сөлгеләре, чигү үрнәкләре белән бизәдек. XX гасыр башында чыккан гарәп язулы китаплар, Казанда Бөтендөнья татар конгрессының төрле милли җыеннарда бирелгән бүләкләре, Роза ханымның шәхси бүләкләре, китаплары, фотографияләре, «Сөембикә» журналының төрле елларда чыккан саннары, башка милли ядкәрләрдән торган күргәзмәне дә килгән халыкка тәкъдим иттек.

«Язмыш җиле» – милләт өчен бәяләп бетермәслек зур хәзинә. Яңа жанрга буразна сызып барган бу әсәр «Казан утлары»нда да басылып чыгуга ук, халык арасында зур кызыксыну уятты. Төп персонаж – Чистайның атаклы муллалары – Камаловларның кызы, Морад бабай нәселеннән булган Гөлсем туташ. Закир Камалов һәм Гыйләҗетдин Исхаковлар (Гаяз Исхакыйның әтисе) гаиләсе якыннан аралашып яши. Чистайда Камаловлар затлы нәсел, аларның өе татарның алдынгы карашлы вәкилләрен үзенә җыеп торган. Гаиләдәге балалар шул мохиттә тәрбияләнә. Өммегөлсем әле яшь була, Закир ишанның улы Ибраһим белән дус яши. Петербургта Бестужевлар курсында укый. Баш-аягы белән милләт эшләренә чумган Гаяз Исхакыйга гашыйк була. Өммегөлсем, күрәсең, аңа рухи укытучысы итеп карагандыр. Бу турыда мин авылдашым Гаяз Исхакыйның туганы – бүгенге көндә 102 яшен тутырган Ташкентта яшәүче Сөембикә апа Шәриповадан ишеттем. Камаловлар, Исхакыйлар һәм Чистайда башка күренекле нәсел кызларының җыелып төшкән фотолары соңгы елларда татар газета-журналларында, китапларда җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде.

Камаловлар гаиләсеннән Әсма – атаклы дин галиме Муса Бигиевнең хатыны, Зәйтүнә – Тукаебызның сөйгән кызы, язучы Атилла Расихның әнисе, безнең героебыз Гөлсем – Россия империясенең атаклы мануфактурачылары, Сембер промышленниклары, татар меценатлары, атаклы Акчуриннар килене.

Якташыбызга багышланган булгангадыр, әдәби кичә җиңел оештырылды, халык яратып кабул итте. Бәйрәмдә Чардаклының «Ак чәчәкләр» фольклор ансамбле катнашты. Сүз уңаеннан әйтик, «Ак чәчәкләр» дә – тарихи ат, XX гасыр башында бу исем турыдан-туры Тукай белән бәйле. «Язмыш җиле» китабында да һәр бүлек 2-3 җөмлә белән булса да, Тукайга барып тоташа. Гөлсем үзе дә Тукайның иҗатына үлеп гашыйк була. Чөнки әтисе өендә Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Муса Бигиев кебек бөек шәхесләр белән аралашып үсә бит, ватан, милләт, дин язмышына кагылышлы җанлы әңгәмәләр яшь туташның күңеленә чәчкә ата башлый. Петербургның Бестужевлар курсында укыган Гөлсем туташ зур батырлык үрнәге күрсәтеп һәм Төркияне яклап, Балкан сугышына китә. Төркиядә госпитальдә яралы солдатларны һәм офицерларны дәвалап кына калмый, аларга җан җылысы, яшәү дәрте өрә. Кайткач, Сембердә Акчуриннарда кунакта була, танышып, шуларның берсенә кияүгә чыга. «Язмыш җиле» китабын язганда, Роза ханым Өммегөлсемнең кызын эзләп таба, Казанның үзендә, Чистайда, Санкт-Петербургта, башка җирләрдә озак вакыт зур эзләнү эшләре алып бара, әдәби чыганаклар белән эшли, әсәргә кергән гаилә хәлләрен өйрәнә, тарихчы галимнәрдән консультацияләр ала.

Р.Туфитуллованың «Язмыш җиле» – милләт кызларын, гаиләне тәрбияләүдә мөнә дигән чыганак. Бик нәзакәтле әсәр. Татарның авыр, михнәтле тормышы әлегә кадәр мондый әсәрләр язарга мөмкинлек бирмәде. Милләт аңа матди яктан да, рухи яктан да әзер түгел иде. Бу әсәр татарның да нәзек кенә катламлы, чын зыялы өлеше барлыкка килүен раслый. Мондый әсәрнең тууы өчен мохит, җирлек, берничә буынның хезмәте кирәк.

Романда үз вакыты өчен матди яктан яхшы тәэмин ителгән, тәрбияле гаиләләрдә туып, Казанның, Мәскәүнең, Санкт-Петербургның абруйлы югары уку йортларында белем алган милләт кызларының ихластан үз халкына хезмәт итүләре тасвирлана. Моңа кадәр дә аерым татар хатын-кызларының хезмәтенә багышланган китаплар басыла килде. Ә Роза ханымның бу хезмәте татар кызларының иң гүзәлләрен бер таҗга җыйган.

Рус әдәбиятында милләтенә хезмәт итүче зыялы дворян кызлары Лев Толстой, Александр Пушкин, Тургенев һ.б. язучылар иҗатында Наталья Ростова, Татьяна Ларина лар булып гәүдәләнә. Декабрист хатыннары турында рус әдәбиятында бихисап әсәрләр язылган. Бу ханымнар барысы да рус, әһүд гаиләләрендә зыялы тәрбия алган. Безнең дә бит югарыда атап үтелгән ханымнар белән бер рәткә басардай гүзәл затларыбыз күп. Әсәрнең авторы Роза Рәхмәтулла кызы да шундыйлардан. Ул тормышын милләтенә багышлаган ханым, бигрәк тә ана, бала, гаилә хакын хаклап күп авырлыклар кичергән, дәүләт җитәкчеләре, депутатлар белән тарткалашып озын юллар узган кеше. Рәссам Рафкать Вахитов юкка гына Казан ханбикәсе Сөембикә образын Роза Туфитулловадан алып язмагандыр. Бөтендөнья татар конгрессы быелның февраль аенда «Ак калфак»ның утыз еллыгын үткәрде. Бу мәртәбәле җыенга үз вакытында төбәкләрендә «Ак калфак»ка нигез салган утыз хатын-кыз чакырылу иде. Конгрессның беренче рәисе Индус Таһировны һәм ул вакытта аның урынбасары, «Ак калфак»ны төзегән Роза Туфитуллованы, Милли шура рәисе Васил Шәйхразиевны без аяк өсте басып каршы алдык. Бик мәртәбәле, дәрәҗәле чара иде ул, шулай ук Казанның уникенче кызлар гимназиясендә дә булдык. Гимназия диварында эленгән ханбикәбез портретына текәлеп торганда, күз алдында Кол Галинең Зөләйхасы, ханбикәләребездән Нурсолтан белән Сөембикә; Гаяз Исхакыйның Остазбикәсе, үзенең хатыны Бибимәрьям, Хәсән Туфанның Луизасы, Гадел Кутуйның Галиясе, Габдрахман Әпсәләмовның Гөлшаһидәсе, Ркаил Зәйдулланың Мөхлисәсе кабат тугандай булды.

«Язмыш җиле» тәрҗемә ителеп, Төркиядә басылып чыгуга, президент Таип Эрдоган тарафыннан зур бәя ала һәм аның тәкъдиме белән Төркиядә 8 март бәйрәмен «Гөлсем көне» дип игълан итәләр. Китап дөнья буенча таралып Франциягә кадәр барып җитә, Чистай кызы, Сембер килене турындагы әсәр хезер тәрҗемә ителеп, Франциядә басыла.

«Язмыш җиле» – Туфитулловлар гаиләсенең уртак җимеше. Миралим әфәндeнең тормышында Роза ханым исә дөрестән дә – роза чәчәге. Ул Роза ханым өчен тормышның бөтен шартларын, шул исәптән иҗат өчен дә шартлар тудырган. Алар икесе бергә, күз тимәсен, бик матур пар. Тормышны матур, чиста үтеп, олы яшькә парлап килеп җитү – үзе бер бәхет ул. Милләт тормышында шундый матур парлар күбрәк булса иде! Татар хатын-кызына көчле затлар тарафыннан тиешенчә игътибар булганда «Язмыш җиле» кебек романнар да, югары сыйфатлы башка сәнгать әсәрләре дә туачак.

Наилә ПОТЕЕВА.
Ульян өлкәсе, Чардаклы.

● Казанда «Ак калфак»ның утыз еллыгына багышланган рәсми чарада катнашучылар. Февраль, 2022 ел.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

9 июль (шимбә). ***Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында,15.23 сәгатьтә калка, 23.54 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.14 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уяныргa мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

Крыжовник (1)

Крыжовник – тимер һәм бакырга, фосфор тозларына бай диетик җиләк, аны матдәләр алмашы бозылганда, симергәндә куллану файдалы. Ул - үт һәм бәвел кудыргыч чара, шулай ук хроник эч катудан да кулланыла. Җимешләре азканлылыктан, еш кан китүдән һәм тире авыруларыннан дәвалый. Элек Кавказда туберкулез белән чирләүчеләргә крыжовникның пешерел суытылган яфракларын ашатканнар. Җимешләре ашказаны-эчәк тракты авырулары вакытында авыртуны баса. 20 грамм крыжовник җиләген термостагы ярты литр кайнар суда 6 сәгать төнәтәләр, көненә 2 тапкыр ярты-шар стакан эчәләр, бераз бал кушарга була. Мондый чара куәтле үт кудыру үзлегенә ия.

10 июль (якшәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 11 нче көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 16.59 сәгатьтә калка, 0.14 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.12 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булыгa, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Крыжовник (2)

Остеохондрозны, артритны дәвалау өчен, 20 крыжовник яфрагын 1 стакан кайнар суда 2 сәгать төнәтеп, көненә 3 тапкыр чирегешәр стакан эчәләр. Эч кипкәндә, 2 аш кашыгы җиләкне 300 мл суда кайнатып чыгарып, суынганчы төнәтәләр, сөзеп, һәр 3 сәгать саен 100 әр мл эчәләр. Салкын тигәндә, крыжовник согын сыгып, көненә 2 тапкыр яртышар стакан эчәләр, шул сок белән тамакны да чайкыйлар.

11 июль (дүшәмбе). ***Зөлхиҗҗә аеның 12 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 18.35 сәгатьтә калка, 0.48 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.10 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Йөрәк еш типсә

Аз гына борчылганда да, кайчак йөрәк бик еш тибә башлый. Аның ритмын җайга салу өчен, тигез микъдарда кушылган әнис орлыгы һәм кориандрны иттарткычтан чыгарып, шикәр кушып болгаталар да, көненә 2 тапкыр, ашаганнан соң, 1әр чәй кашыгы кабып суыралар.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

***12 июль (сишәмбе).** Зөлхиҗҗә аеның 13 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 19.58 сәгатьтә калка, 1.44 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.07 сәгать.*

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь.

Юкә сихәте

Юкәнең кайрысы да, чәчәге дә, балы да сихәтле. Юкә чәчәге температураны төшерә, тирләтеп кенә калмый, нерв киеренкелеген дә бетерә, ютәл өянәген дә баса. Югары кислоталылыкны киметә, ашказаны, бавыр, бөер, йөрәк авыруларын дәвалауда кулланыла. Иммунитетны ныгыта, салкын тиюне кисәтә. Диабет белән чирләүчеләрнең канындагы шикәр күләмен киметә. 4 аш кашыгы юкә чәчәген ярты литр суда 10 минут пешерәләр, көненә 2 тапкыр 1 әр стакан эчәләр. Пешкән урынга, төзәлмәс җәрәхәтләргә шушы кайнатмада чылатылган йомшак тукыма куеп бәйләү файдалы. Яшь юкә кайрысын суда пешереп тә пешкән урынга бәйлиләр. Юкә балының шифасын исә язып та бетерерлек түгел.

***13 июль (чәршәмбе).** Зөлхиҗҗә аеның 14 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында,20.57 сәгатьтә калка, 3.05 сәгатьтә бата. 21 сәгать 37 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 17.05 сәгать.*

Авыр энергетикалы көн. Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

***14 июль (пәнҗешәмбе).** Зөлхиҗҗә аеның 15 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында,21.33 сәгатьтә калка, 4.42 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 17.02 сәгать.*

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый. Ай Сукоярда чакта вегетатив нерв системасын саклау мөһим, арка, умырткалык, йөрәк, кан тамырларын дәвалау, чынығу уңай нәтиҗә бирә. Кәбестә, яшел борчак, суган ашау файдалы.

***15 июль (җомга).** Зөлхиҗҗә аеның 16 нчы көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында,21.55 сәгатьтә калка,6.21 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 16.59 сәгать.*

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Маринадланган кыяр

3 литрлы банка төбенә дүрткә бүленгән кишер, 2 баш кечкенә суган, берничә бүлем сарымсак, карлыган һәм чия яфрагы, укроп башлары, керән, түгәрәк кара борыч салып, юылган кыярларны тыгызлап тутыралар, өстенә кайнап торган су коеп, 15 минут тоткач, шул суны агызып алалар да, 5 чәй кашыгы тоз, 10 чәй кашыгы шикәр, 100 г 9 процентлы серкә салып, кайнатып чыгаралар, кыяр өстенә агызып, тимер капкач ябалар һәм юрганга төреп суыталар.

Студияләрдә – милли мохит

Казанда балалар өчен татар телендә өч театр студиясе эшли. Аны җитәкләүчеләр мәктәпләрдә татар теле кыскарганда, театр студияләре татарча мохит булдыруда, телне өйрәнүдә өстәмә белем бирүдә булыша ди.

Быел Казанда балалар, яшүсмерләр өчен татар театр студияләре бер-бер артлы чыгарылыш спектакльләре белән тамашачылар, ата-аналар каршында хисап тотты. Бер мизгелгә татарча спектакль уйнарлык бу кадәр татар телле балалар кайдан табыла һәм театр студияләре арасында көндәшлек ничек бара дигән сораулар туа. Өч студиянең дә оештыручылары андый коллективларның саны тагын да артсын иде дип тели, көндәшлек булганда сыйфат арта диләр.

Казанның Щапов урамында урнашкан Актерлар йортындагы «Нур» театр студиясе элегрәк балалар белән татар телендә эшләүче бердәнбер студия иде. 2012 елдан бирле эшләп килгән студияне бүген актер Марсель Мәхмүтов җитәкли. Биредә 8 яшьтән 15 яшькәчә балалар шөгыльләнә. Соңгы вакытта ел дәвамында 18 бала йөргән. Кемдер дәвам итә, араларында быел беренче тапкыр уйнаучылар да бар. Дәресләр түләүле, аена 3 мең сум. Балалар студиягә атнасына 2 тапкыр килә. Быел алар Рэй Брэдбериның «Вельд» исемле пластик спектаклен күрсәткән. Татарча.

Марсель Мәхмүтов балалар белән берничә ел эшли, алар белән уртак тел табу бер яктан караганда авыр, икенче яктан рәхәт, ди. Бала күңелен яуласаң, ышаныч тудырсаң, бу аңа гына түгел, сиңа да канатлар куя дип аңлата актер.

Марсель студиягә йөрүчеләрнең барысы да Казан балалары ди, татар булсалар да, телне камил белүчеләр аз, әмма аларны бирегә сәнгатькә мәхәббәт кенә түгел, телне камилләштерү теләге дә алып килә, дип аңлата. Әлегә «Татар телен яратмыйм!» дип ташлаучылар булмаган. Киресенчә, татар мохитенә кереп китеп, алар тел аркасында чыгарга мөмкин булган каршылыкны җиңел җиңәләр, ди Мәхмүтов.

– Балаларның сөйләм теле дәрәҗәсе төрле. Кемдер яхшы сөйләшә, кемдер ипи-тозлык кына белә, әмма дәрескә барыбер йөриләр. Нигә кирәк икән татарча азапланырга, рус телендә эшләүче театр студияләре дә бар, әмма татарчаны нәкъ менә телне чарлар өчен дә сайлыйлар. Беренче чиратта аны әти-әниләре сайлый, алар балаларының телен яхшыртырга тели. Ә балалар бездә кызык булуын күрә дә, китми, кала, – дип сөйли ул. – Монда бит социализация уза бала, йомыкыйрак икән, ул дәресләрдә шөгыльләнеп ачыла. Курку бетә. Бала үз хисләрен үз кулына алырга өйрәнә, үзен ничек хис итүе турында аңлата белә, кешеләр алдында чыгып сөйли ала. Бу да бит мөһим.

Актер фикеренчә, студиядә дәресләр татарча барса да, бала моның белән телне өйрәнә алмый. Тел өйрәнүгә нигез гаиләдә салынса, мәктәптә ул камил дәрәҗәдә өйрәтелсә, татар телендәге театр студияләре татар телле мохит булдыруда, телгә ихтыяҗ арттыруда үз өлешен кертә, дип аңлата ул.

– Телне өйрәнү комплексы гына була ала. Бакчада татарча уеннар уйнаган, әкиятләр тыңлаган баланың белеме мәктәптә арттырылырга тиеш. Телне өйрәтү мөһим. Моннан тыш балаларга татар телендә чит илләрдә уйлап табылган уеннардан ким булмаган компьютер уеннары булуы да мөһим. Кинофильм, мультфильмнар да. Телгә мәхәббәт, ихтыяҗ тудыру төрле яктан барсын иде, – ди Марсель.

«Нур» театр студиясе җитәкчесе киләсе елда балаларны сайлап алу өчен кастинг уздырганда телгә дә игътибарны арттырырга кирәк булыр дип саный.

Казанда инде берничә ел «BezTeatr» студиясе эшли. Аны Зөлфия Вәлиева белән Миләүшә Шәйхетдинова оештырды. 2017 елдагы хәлләрдән соң татар телен саклауда, үстерүдә безнең нинди өлешебез була ала дип тормышка ашкан проект бу, дип аңлаткан иде артистлар. Башта студиядә ике төркем була, берсе – рус, берсе – татар. Хәзер исә эш бары бер татар төркемендә генә алып барыла. Моны объектив карар дип аңлата оештыручылар.

– Ике төркем, атнасына ике яки өч дәрес, балалар күп, без Зөлфия белән өлгерми башладык. Үзебез дә эшлибез бит, безнең дә график тыгыз, аннары безгә йөргән балалар да актив, аларның күбесенең йә уку, йә бәйгеләрдә чыгыш ясаулар, – дип аңлата Миләүшә. – Шуңа бары тик бер төркемне генә калдырырга булдык. Татарча эшләү үзебезгә дә кызык.

Студиядә 12 бала шөгыльләнә. Биредә сәхнә теле, бию, актерлык осталыгы дәресләре бар. Биредә дәресләр түләүле, аена 3 мең сум. Артистлар әйтүенчә, ул беренче чиратта аренда өчен түләүгә китә. Бу – акча эшләү урыны була алмый, ди алар.

«BezTeatr» быел чыгарылыш спектакле итеп Галиәсгар Камалның «Банкрот»ын куйды. Еллык нәтиҗәсен күрер өчен, беренче чиратта студиягә йөрүче балаларның әти-әниләре, әби-бабалары килгән. Балалар барысы да камил татар телендә сөйләшә. Миләүшә әйтүенчә, алар аерым кастинг уздырмаган.

– Беренчедән, безгә йөрүче балаларның ата-аналары барысы да милли җанлы кешеләр, кем сәнгатькәр, кем журналист, кем укытучы, кем артист дигәндәй. Алар балаларына татар телен сеңдерергә тырыша. Өйдә сөйләшкәннәре күренеп тора. Туган телләрен яраталар, татар театрларына йөриләр. Икенчедән, барысы да диярлек татар мәктәпләре, гимназияләрендә белем ала, – дип дәвам итә Миләүшә. – Дөрес, балалар барыбер үзара русчага күчә ала. Без шалт итеп «Биредә татарча гына сөйләшәбез» дип кисәтеп куябыз. Ул бер уенга ук әйләнде. Балалар үзләре барысын да контрольдә тотарга тырыша. Кемдер начаррак сөйләшә, әмма теләге зур. Ул баланы ничек кире кагып булсын? Аралашып камилләшә алар. Менә шул теләк киртәләрне җиңә. Уеннар кызык бит, баланың уйныйсы, катнашасы килсә, ул аның кагыйдәләренә төшенергә тырыша. Бер кызыбыз начаррак сөйләшә иде, хәзер карыйбыз да аңа сөенәбез. Әти-әнисе дә куана.

М.Шәйхетдинова аңлатуынча, балаларның татар театр студиясендә шөгыльләнергә теләве, мотивациясе телевидениегә эләгү, сәхнәгә чыгу, спектакльдә уйнауга бәйле.

– Күбесенең «ШаянТВ» тапшыруларында катнашу, алып баручы булу теләге зур. Әниләре белән театрларга йөриләр, бүгеннән үк спектакльләрдә катнашасылары килә. Зәлия Закирова, мәсәлән, Камал театрының күмәк күренешләрендә катнаша, – ди Миләүшә. – Бу мөһим, әмма әти-әниләр өчен дә, балалар өчен дә татар телле мохит булуы кадерле. Балалар үзара дуслашып бетте, азрак күрешми торсалар, бер-берсен сагынып киләләр, кочаклашалар. Гаиләләр дә үзара аралашып китә. Бу да бит кирәк. Балалар үзе кебек сөйләшүче, үзе кебек фикерләүче яшьтәшен күреп, дәртләнә, кыюлана.

«BezTeatr» җитәкчеләре дә, мәктәпләрдәге татар теле дәресләре булмаса, телгә мәхәббәт тәрбияләнмәсә, театр студияләре генә могҗиза тудыра алмый, барысы да бергә җигелеп эшләгәндә генә, тел мәсьәләсен хәл итәргә мөмкин дип саный.

2021 елда «Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге» елында Казан Башкарма комитеты рәисенең урынбасары Гүзәл Сәгыйтова телне үзләштерүдә, татар телле мохит булдыруда татар телле театр студияләре дә кирәк дип чыгыш ясаган иде. Бу идея быел тормышка ашты. Казанның «Сәйдәш» мәдәни үзәгендә «Апуш» исемле театр студиясе эшли башлады. 30 бала катнашында «Апушның тылсымлы төшләре» дип аталган спектакль дә күрсәтелде. Студиядә балалар бушлай шөгыльләнә, әмма анда эләгүчеләр конкурс аша узды. Кастингка йөздән артык бала килде, алардан 30 ы гына сайланды. «Апуш»ның җитәкчесе Алия Фәйзрахманова балаларның татар телен камил белүе шарт иде дип аңлата.

– Татар театр студиясе булгач, туган телне белмәгән балалар белән эшләү авыр булачак иде, шуңа без телне белү дәрәҗәсен дә тикшердек. Гаҗәп, әмма Казанда театр сәнгате белән кызыксынган һәм татарчаны камил белгән балалар күп булып чыкты. Бу куандыра, әмма шул ук вакытта җаваплылык та өсти, – ди Алия. – Кастингка бер шәп кыз килде, бик талантлы, әмма татарчасы аксый. Эксперимент өчен аны алдык. Беләсезме, теләк булганда телне дә өйрәнеп була икән! Шулкадәр тырыш булып чыкты ул. Үзе кебек талантлы балалар белән дә аралашу ярдәм иткәндер, аның теле бик тиз шомарды.

Дәресләр саф татар телендә бара. Балалар үзара русча да сөйләшә ала, әмма дәрестә алар туган телдә генә сөйләшә. Дәресләрне танылган артистлар, хореографлар алып бара. Балаларга көндәлек эш йөге зур, әмма алар киләсе елга да киләбез дип таралышты. Августта тагын кастинг узачак.

Алия Фәйзрахманова театр студияләре балаларның татар телен тормышта да кулланырга, үсәргә, төрле һөнәрләргә өйрәнергә мөмкинлек бирә дип сөйли. Әйтергә кирәк, «Апуш» кебек театр студияләре Казанның башка районнарында да эшләячәк. Төрле мәдәни үзәкләрдә балалар өчен татар театр студияләрен ачу максаты куелган.

Борынгылар әйткән сүзләр

(Мәкальләр һәм әйтемнәр)

Хуҗи МӘХМҮТОВ



ИУДА ҮБҮЕ

«Инҗил» сүрәләрендә (Маттай, 26; Лук, 22; Марк, 14) риваять кылынганча, Гайсә (Иисус Христос) өйрәтүләрен дошман күргән баш руханилар һәм канунчылар аны үтерергә сүз куешалар. Әмма Алла улын тоту шактый кыен эш булып чыга. Шул вакыт Гайсә шәкертләреннән берсе – Яһүд (Иуда) Искариотның эченә шайтан керә. Ул әлеге кешеләр янына барып әйтә:

– Әгәр сезгә Гайсәне тапшырсам, миңа нәрсә бирерсез? – ди. Алар, бик шатланып, моңа 30 көмеш тәңкә санап бирәләр.

Бервакыт Гайсәнең Зәйтүн тавына дога кылырга китүен белгәч, Яһүд, кылыч-чукмарлар белән коралланган кешеләр ияртеп, тиз генә шунда юнәлә. Алар белән алдан сүз беркетеп куя: «Мин кемне үпсәм, шул Гайсә булыр. Аны кулга алыгыз», – ди.

Гайсәне күреп алу белән Яһүд аның янына килә дә, «Исәнме, Остаз!» дип, аны үбеп ала. Гайсә сорый:

– Яһүд! Син миңа үбүең белән хыянәт итәсеңмени? – ди...

Шушы риваятьтән туган «Иуда үбүе» дигән тәгъбир астыртын хыянәтне тыштан дуслык, мәхәббәт белдерү белән яшерергә маташу хакында әйтелә. Иуда исеме «сатлыкҗан», «икейөзле хаин» сүзләренә синоним булып киткән.

«Бәйрәм көнне, көчләп очыратып,
Үпте ялачы... Ай-яй кыю да!
Пычрак авызларын лычкылдатып
Үпкән төсле булды Иуда». – *(Шәйхи Маннур. Кичке моңнар)*.

ЙӨЗЕК КЕМ КУЛЫНДА БУЛСА, ШУЛ СӨЛӘЙМАН

Мәгънәви төрдәше: «Йөзеге барда - Сөләйман, йөзеге юкта – сөмәйгән». «Сөләйман» исеме һәм «йөзек» сүзе бу мәкальләрнең килеп чыгышы Сөләйман пәйгамбәр турындагы риваять-легендаларга бәйле булуын искәртеп тора.

Сөләйман г-м дөньядагы барлык патшалар гына түгел, бәлки җилләр, болытлар, кош-кортлар, җәнлекләр, җеннәр, пәриләр, диюләр өстеннән дә хакимлек иткән. Мондый чиксез кодрәткә ул Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән тылсымлы йөзек ярдәмендә ирешкән. Әгәр шул йөзеген югалтса, аның хакимияте юкка чыккан.

Коръәндәге «Сад» сүрәсенең 31-34 аятьләрендә Сөләйман пәйгамбәрнең Аллаһы тарафыннан әнә шундый сынауга дучар ителүе турында сөйләнелә (Ногмани тәфсире):

«Икенде намазына хәтле Сөләйманга Аллаһның рәхмәтеннән гаиптән атлар бирелде... Сөләйман атларның матурлыгына мәхәббәт итеп, аларны уйнату белән мәшгуль булды, хәтта икенде намазын, онытып, кичектерде...

...Без Сөләйманны патшалыгын алмак белән бәлаләндердек. Чөнки аның патшалыгы йөзегендә иде. Бер кич йөзеген хатыны янында калдырып киттек тә, Сөләйман сурәтендә бер җен йөзекне алып китте. Без аның көрсиенә бер гәүдәне – әлеге йөзекне алган җенне утырттык. Соңра Сөләйман тәүбә итте, Аллаһыга кайтты. Ягъни, йөзекне кулга төшереп, яңадан патша булды».

Насреддин Рабгузиның «Кыйсасел-әнбия»сендә Сөләйман г-м кичергән әлеге маҗарага махсус бер бүлекчә багышланган. Аның кыскача эчтәлеге түбәндәгечә.

Беркөнне Сөләйман г-м, җилләр күтәреп йөртә торган тәхетенә утырып сәхрәгә чыккач, җиде меңнән артыграк атларга юлыкты. Пәйгамбәр күренүгә, алар һавага очып юкка чыктылар. Өенә кайткач, Сөләйман г-м Сәмнидун исемле куәтле һәм хәйләкәр бер диюне чакыртып, аңа шул атларны тотып үзенә китерергә кушты. Дию аның әмерен үтәде. Сөләйман г-м атларны берәм-берәм караганда караңгы төшкәнен сизми калды һәм икенде намазын онытты...

...Икенче көнне тәһарәт алдыннан Сөләйман г-м йөзеге белән чалбарын Әминә исемле кәнизәгенә бирде. Бераздан Дахыйр исемле җен, Сөләйман г-м сурәтенә кереп, Әминәдән йөзек белән чалбарны алды да, тәхеткә менеп утырды. Сөләйман г-м тәһарәт алып чыкса - йөзек юк, тәхеттә Дахыйр утыра. Хак Тәгалә пәйгамбәр г-мнең күңеленә шом салды. Ул бу урыннан качып китте, хәтта ахшам җиткәнче йөгерде, аяклары кабарды...

...Дахыйр, Сөләйман г-м йөзеген киеп, кырык көн хөкем кылды. Күп кенә гамәле шәригатькә туры килми иде. Сөләйман г-мнең тугрылыклы вәзире Әсаф беркөнне елый-елый кешеләргә кычкырды: «Әй җәмәгать, бу Сөләйман түгел икән. Тәхеттә утырган адәмне тотыгыз!» - диде. Дахыйр, моны ишетеп, качты һәм йөзеген бер дәрьяга ташлап калдырды. «Әрхам» исемле балык ул йөзекне йотты.

...Сөләйман г-м беркөнне шул дәрья ярына килеп чыкты. Анда берничә кеше ау сала иде, ләкин бер балык та керми иде. Шунда бер балыкчы: «Бу нурлы йөзле мөсафир салып карасын», - дип, Сөләйман г-мгә мөрәҗәгать итте. Ул ауны салган иде, Хак Тәгалә фәрештәләргә әмер итте дә, алар ау тулганчы балыкларны сөреп керттеләр. Әрхам балыгы да шулар арасында иде. Сөләйман г-мгә сәлам биреп: «Йә Рәсүлулла, учыңны авызыма куй», – диде. Сөләйман г-м учын тотты исә, балык аның йөзеген учына салды. Пәйгамбәр г-м шат булды. Кош-кортлар, янына җыелып, яңадан Сөләйман г-мнең хезмәтенә керделәр...

Күрәнә ки, безнең «Йөзек кем кулында булса, шул Сөләйман!», «Йөзеге барда – Сөләйман, йөзеге юкта – сөмәйгән» кебек мәкальләребез хәзер китерелгән кыйссадан хиссага охшап торалар. Дөрес, аларның мәгънәләрендә дини төсмер юк. Сүз кодрәт, байлык, хакимият турында бара. Узган йөзнең беренче чирегендә бу гыйбарәләр әдәби телебездә әле шактый актив кулланыла иде.

Мирхәйдәр Фәйзинең 1913-1917 елларда язылган «Авыл бәйрәме» пьесасыннан *(Сайланма әсәрләр)*:

«Шәгъбан. Бәдбәхет, мәлгунь... (Таягы белән суга. Шәйхи таякны тартып ала).

Шәйхи. Йөзек кем кулында булса, шул Сөләйман. Заман да безнеке, таяк та миндә. Бөтен кодрәт безнең кулда хәзер».

ҖАНЫҢНЫҢ ВАКЛЫГЫН СЫЛТАМА ЗАМАНГА

Бу канатлы әйтелмә күренекле шагыйрьләребез иҗатыннан халык теленә күчкән аеруча тирән хикмәтле тәгъбирләрнең бер үрнәге булып тора. Аның чыганагы – Равил Фәйзуллинның «Җаныңның ваклыгын...» дип башлана торган исемсез шигыре (Сайланма әсәрләр):

«Җаныңның ваклыгын
сылтама заманга.
Куркырга, өркергә
җай бар ул һаман да.
Ә бит бар кешеләр —
шәхесен ватмаган,
хаклыкны сатмаган,
вөҗданын саклаган.
Әйткәннәр: тарихтан
түгелсәм түгеләм,
изелсәм изеләм –
әмма дә бөгелмәм!
Үзләре сеңсә дә,
рухлары калыккан.
...Әнә шулар үлеме
җан әрә халыкка.
Асылыңны яшереп
кыланма ни генә, —
буыннар хәтерендә
бары да чигелә!
Җаныңның ваклыгын
сылтама заманга...»

Шигырьгә һәм аннан «очып чыккан» канатлы гыйбарәгә әдәбият галиме Нурмөхәммәт Хисамовның гаять төгәл һәм нечкә тоем белән бирелгән махсус шәрехе бар. «Конъюнктурага яраклашып, имансыз яшәү бәрабәренә рәхәтләр чигеп гомер кичерүче чордашларыбыз, вөҗданнары каршына кискен сораулар куелганда, заман ышыгына сыенып котылырга яраталар, – дип күрсәтеп үткәннән соң, мәкалә авторы болай дәвам итә. – Шушы күренешне Равилебез классик шигыре белән әхлакый-иҗтимагый кискен рәвештә коралсызландырып ташлый... Шигырьнең беренче ике юлы (шагыйрь аларны, йомгак ясагандай, ахырда да кабатлый. – **Х. М.**) явызлыкка битарафлыкны, ваемсызлыкны, ярашучылыкны гаепләүче афоризм булып хәтерләргә уелып калды... Аның әлеге афоризмын инде намуслы замандашлары күтәреп алган, чор үзенең байрагы иткән. Хакыйкать шагыйрь милкеннән халык милкенә күчкән».

Әдипләр тудырган хикмәтле сүзләрнең «халык милкенә күчүенә» бер дәлил - аларның, мәкальләр белән рәттән, сөйләмдә һәм язма телдә киң кулланылыш табуы. Мондый мисалларны күзәтелә торган гыйбарәгә карата да китерергә мөмкин:

Әбүзәр. Һәм ике елдан өйләнергә рөхсәт сорап киләбезме?

Кәримҗан. Икеме, өч үк булырмы, бәлкем, дүрткә дә тартылыр? Анда күз күрер. Мәгәр мин соңгы сүземне әйттем. Заман да заман, дисең. Шагыйрь бу хакта менә болай дигән: «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга!». Менә шулай» (Аяз Гыйләҗев. Сайланма әсәрләр.).

Бу урында өстәп шуны да әйтергә кирәк: заман һәм шәхес темасы безнең мәкальләребездә дә киң яктыртылыш тапкан. Алар заманнан артта калмаска, аның мөһим яңалыкларын үзләштереп барырга чакыралар. Халык заманны чабып барган ат сурәтендә күрә. Мәкальләрнең берсендә «заманның ялына ябышырга» кушыла. Икенчесе: «Заманның ялына ябышмасаң, койрыгыннан тоталмассың», – дип кисәтә. «Заман сиңа буен куймас, син заманга буең куй» дигән сүз дә бар.

Әлбәттә, «һәр заманның үз гореф-гадәте». Алар арасында уңайлары гына түгел, тискәреләре дә очрый. Хәлбуки, халык акылы турыдан-туры заманны гаепләүне хупламый. Әйтик: «Заман бозык түгел, адәм бозык», «Замана бозык булыр, юллар төзек булыр». Икенче мисалны Нәкый Исәнбәт: «Заман бозылган чакта да төзәлүгә юллар бар димәкче», – дип шәрехли. Күреп үткәнебезчә, Равил Фәйзуллин гыйбарәсе дә шундый мәкальләргә аваздаш. Бу мотивның безнең фольклорга ислам әхлагы аша кергән булуы да ихтимал, һәрхәлдә, Мөхәммәд галәйһиссәлам хәдисләре арасында (ә алар татар халкында бик популяр булган!) шундый эчтәлектәгеләре дә бар. Менә бер генә мисал:

«Аллаһы Тәгалә әйтте: «Бәндә һәрнәрсәне заманга нисбәт итеп, Мине рәнҗетә. Әй өммәтем! Һичберегез һичнәрсәне заманга сылтамагыз, заманасы шулай, димәгез, чөнки заман — ул Мин Үзем. Кичен дә, көнен дә Үзем әйләндерәм»». (Гариф Бик. Мең дә бер хәдис шәрехе).

Хәдискә Габдерәшит Ибраһимов биргән шәрех тә гыйбрәтле: «Бездә берәр гаҗәп вакыйга булса, заман шулай, диләр, һәрнәрсәне заманга сылтарлар, бу - наданлык» *(шунда ук)*.

Гадел дәүләттә яшәве рәхәт

Сингапур үз бюджетына шулкадәр күп акча эшләгән ки, хәзер аны кая итәргә белми. Бары тик үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан безнең түрәләрдән аермалы буларак, шәһәр-дәүләт җитәкчеләре ел саен артык акчаны кабат үз гражданнарына бүлеп бирә. Сингапурда барлыгы 5,6 миллион кеше яши, әмма өстәмә акча 21 яшьтән өлкәнрәкләргә генә бирелә. Һәм бернинди тигезләү дә юк – һәркем үзенең еллык кеременә карап исәпләнгән бонус белән бүләкләнә. Елына 100 мең җирле доллардан артыграк акча эшләүчеләргә – 100 әр, еллык хезмәт хакы 28 меңнән артмаганнарга 300әр доллар бирелә. Акчаны кирәксенмәүчеләр аны хәйрия максатларына тотарга мөмкин. Бу бик бай илдә дәүләт хезмәткәрләре өчен бонуслар системасы гамәлдә, чөнки гади хезмәткәрнең эш хакы якынча 3 мең җирле доллардан (2 мең АКШ доллары), ә җитәкчеләрнеке 18 мең җирле доллардан (12 мең АКШ доллары) артмый. Шуңлыктан дәүләт аларга ел саен 0,5 процент өстәмә түли, кайвакыт күбрәк тә тамгалый. Сингапур эчке тулай продукт күләме буенча дөньяның әйдәп баручы биш иле арасына керә. Биредә еллык табышы 22 мең җирле долларга тулмаучы гражданнар керемгә карап салына торган салымнан тулысынча азат ителә.

(“The Straits Times”).

Космоста... ит үстерәләр

Израильдә Aleph Farms фирмасы, Россиядәге биопринтерлар җитештерүче 3D Bioprinting Solutions лабораториясе белән берлектә, космоста ит үстергән. Impossible Foods һәм Beyond Meat компанияләреннән аермалы буларак, Aleph Farms итне үсемлек компонентларыннан түгел, бәлки пробиркада үстерелгән хайван күзәнәкләреннән “ясый”. Сынау өчен кирәкле күзәнәкләрне Халыкара космик станциягә алып менгәннәр, анда микрогравитация шартларында алардан принтерда мускул тукымасының бер өлешен бастырганнар. Россия лабораториясе якын арада балык һәм куян тукымаларын бастыруны планлаштыра. Сынауның ике максаты бар: Җирдә ризыкны экологиягә зыян китермичә генә җитештерү һәм космик корабларда ерак юлга чыгачак, аннары башка планеталарда да яшәячәк кешеләрне ризык белән тәэмин итү. Aleph Farms фирмасын оештыручылардан берсе Дидье Тубиа әйтүенчә, бер килограмм ит җитештерү өчен кирәкле 10-15 мең литр су космоста юк, шуңа күрә аны башкача “үстерергә” өйрәнү зарур. Компания тере сыер күзәнәкләрен алып, лабораториядәге ясалма туклану мохитендә үстерә икән. Пробиркада үстерелгән итне үсемлек аксымыннан ясалган ит белән бутамаска кирәк, мәсәлән, популяр Beyond Meat фирмасы борчактан ит ясый. Пробиркадагы ит исә бозауның мускул тукымасы кисәгеннән тукландыргыч гельдә үстерелә.

(“Die Presse”).

Лох-Несс албастысы

Серле Лох-Несс күле Шотландиянең биек тауларында урнашкан һәм ике мең фут биеклектәге вертикаль кыялар белән әйләндереп алынган. Аның тирәнлеге кайбер җирләрендә тугыз йөз футка җитә. Бу гаҗәеп зур күл бик күп сер саклый. Аның болганчык суында бик борынгы заманнардан бирле албасты яши, дип фаразлана. Лох-Несс албастысы турында тәүге тапкыр безнең эраның 565 елында телгә алына, әмма шуннан соң XIX гасыр башына кадәр аның хакында бернинди хәбәр дә очрамый. Ә инде 1933 елдан безнең көннәргә кадәр албастыны биш мең тапкырлап күргәннәр икән! Бәлки, ялганлыйлардыр. Фаразларның иң таралганы буенча, Лох-Несс албастысы ул – моннан миллион еллар элек үлеп беткән динозавр-плезиозавр. Әмма аның шулкадәр озак яшәвенә ышанырлык түгел бит. Серле монстрның популяциясе, үрчер өчен, кимендә берничә дистә булырга тиеш, ә аның кадәр плезиозаврны туйдырыр өчен бер күлдәге ризык кына җитмәс иде.

(“Вокруг света”).

Киләчәк кем кулында?

Американың иң күренекле уйлап табучыларыннан берсе, футуролог, язучы Рэймонд Курцвейл якындагы 30 елга үз фаразларын төзегән. Аның әйтүенчә, инде 2022 елда ук АКШ һәм Европада кеше һәм робот мөнәсәбәтләрен җайга сала торган законнар кабул ителәчәк. 2024 елда инсаннарга компьютер белән җиһазландырылмаган автомобильне йөртү тыелачак. 2025 елда кешегә гаджет-имплантатлар куелачак. 2027 елда катлаулы гамәлләр эшләргә сәләтле шәхси робот суыткыч яки чәйнек кебек гадәти әйбергә әйләнәчәк. 2031 елда кеше әгъзаларын бастыра торган 3D-принтерлар һәр хастаханәгә куелачак. 2033 елда юлларда үзләре идарә ителә торган машиналар гына калачак. 2038 елда роботлаштырылган кешеләр пәйда булачак, алар өстәмә интеллект һәм төрле имплантатлар – күз-камера, өстәмә протез кул белән җиһазландырылачак. 2043 елда кеше тәне теләсә нинди формага керә алачак, эчке әгъзаларны кибернетик җайланмалар алыштырачак. 2044 елда биологик булмаган интеллект тере акылдан миллиардларча тапкыр яхшырачак. 2045 елда Җир үзе зур бер компьютерга әйләнәчәк.

(“The Independent”).



● Николай Рерих. “Монхиган. Мэн” картинасы.

Берүзенә бер утрау

1892 елда Нью-Йоркта туган Рэй Филлипс 50 елга якын Мэн штатындагы Монхиган утравында яшәгән. Ул университет тәмамлаган, 1917 елда АКШ Беренче бөтендөнья сугышына кушылгач, армиягә язылып, Европага киткән һәм капитан булганчы хезмәт иткән. Сугыштан соң туган шәһәрендә азык-төлек иминлеге инспекторы булып эшкә урнашкан. Әмма шау-шулы Нью-Йоркта яшәү аны тиз арада туйдырган. Кечкенә яхта сатып алып, ул диңгездә рәхәтләнеп ялгыз балык тота башлаган. Бервакыт 500 чакрым ара үтеп, 120 кеше яшәгән, мәйданы нибары 11 квадрат километр булган Монхиган утравына килеп җиткән. Биредә гел балыкчылар яшәгән, XIX гасырда исә аны бигрәк тә рәссамнар үз иткән – Эдвард Хоппер, Рокуэлл Кент биредә яшәп алган. 1922 елның җәендә биредә атаклы рус рәссамы Николай Рерих берничә картинасын иҗат иткән. Аның янәшәсендәге бик кечкенә Манана утравында исә маяк торган, беркем дә яшәмәгән. 1931 елда Филлипс аны 75 долларга сатып алган. Яхтасын сүтеп, йорт салган һәм берьялгызы яши башлаган. Монхиганнан бер чакрымлы бугаз гына аерып торганга, азык-төлек, почтаны шуннан килеп алган, җирле халык белән дуслашкан. Сарыклар үрчетә башлаган. Монхиган китапханәсендәге бөтен китапны укып чыккан, газета-журналлар яздырып алган, радио тыңлаган. Тора-бара ул Монхиганның символына әйләнгән. 1970 елларда аны күрергә дип бирегә туристлар агыла башлаган. Күрше утрауга күченүен үтенсәләр дә, 1975 елда 83 яшендә вафат булганчы Рэй Мананадагы йортын ташлап китмәгән, һаман берьялгызы яшәгән.

(“Лента.ру”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

11 июль
«ТАТАРСТАН– -ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ. ТАНЦЫ НА УГЛЯХ». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Ком сәгате». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.15 «Акыл батл».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Әдәби хәзинә». 6+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
23.50, 0.40 «Семь дней+». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.15 «Шаян хәлләр». 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Җырларымда син генә». Рафил Җәләлиев һәм Эльмира Гыйльфанова концерты. 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Әлфия Авзалова турында телеочерк. 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30 «Татарлар». 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «БЕЗОПАСНОСТЬ». 12+
10.30, 21.00 «ГОРОДСКИЕ ШПИОНЫ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Непростые вещи». 12+
15.30 «Битва оружейников». 12+
16.15 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
18.00 Вечерние новости.
21.00 «Время».
21.45 «СПРОСИТЕ МЕДСЕСТРУ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «РОМАНОВЫ. ВЕНЦЕНОСНАЯ СЕМЬЯ».

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.20 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Другие Романовы». «Августейшая нищая».
7.35 «Забытое ремесло».
7.50, 23.40 «Сергей Прокудин-Горский. Россия в цвете».
8.40 «БРОДЯГИ СЕВЕРА».
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Жан-Франсуа Тома де Томон. Биржа.
10.45 Academia. Александр Городницкий. «Магнитное поле океана: вчера и сегодня».
11.35 Искусственный отбор.
12.20 «Идите и удивляйтесь».
13.00 «БАЛЛАДА О ДОБЛЕСТНОМ РЫЦАРЕ АЙВЕНГО».
14.30 «Три тайны адвоката Плевако».
15.05 «Музеи без границ». Пермский музей современного искусства PERMM.
15.35 Голливуд Страны Советов. «Звезда Аллы Тарасовой».
15.50 Знаменитые фортепианные концерты. Л. Бетховен. Концерт №3 для фортепиано с оркестром.
16.50 Спектакль «Семейное счастие».
18.50 «Фома. Поцелуй через стекло».
19.45 Письма из провинции.
20.20 «Зеркало Олега Целкова».
21.15 «МАЯКОВСКИЙ. ДВА ДНЯ».
22.50 «Жизнь делает лучше, чем ты задумал...»

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25 «Научные расследования Сергея Малозёмова». 12+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «ОПЕКУН». 16+
21.40 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ». 16+

Сишәмбе

12 июль
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ. ТАНЦЫ НА УГЛЯХ». 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Төймә».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «Без химии». 12+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Янар чәчәк». Мирсәет Яруллин турында телеочерк. 6+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Бәйрәмнең дә бәйрәме». 6+
19.35, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «БЕЗОПАСНОСТЬ». 12+
10.30, 21.00 «ГОРОДСКИЕ ШПИОНЫ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Битва оружейников». 12+
16.15 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
18.00 Вечерние новости.
21.00 «Время».
21.45 «СПРОСИТЕ МЕДСЕСТРУ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «Цареубийство. Следствие длиною в век». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.20 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Другие Романовы». «Второй цесаревич».
7.35 «Театральная летопись. Петр Фоменко».
8.05, 23.40 «Конец эпохи негатива».
8.50 «ЗИМОВЬЕ НА СТУДЁНОЙ».
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Винченцо Бренна. Михайловский замок.
10.45 Academia. Николай Короновский. «Земля: вчера, сегодня, завтра».
11.35 Искусственный отбор.
12.20 «Рем Хохлов. Последняя высота».
13.00, 21.15 «МАЯКОВСКИЙ. ДВА ДНЯ».
14.30 «Азарий Плисецкий. Жизнь делает лучше, чем ты задумал...»
15.05 «Музеи без границ». Музеи деревни Учма Ярославской области.
15.35 Голливуд Страны Советов. «Звезда Любови Орловой».
15.50 Знаменитые фортепианные концерты. Р. Шуман. Концерт для фортепиано с оркестром.
16.40 Цвет времени. Клод Моне.
16.50 Спектакль «Триптих».
19.00 «Монолог актрисы. Майя Тупикова».
19.45 Письма из провинции.
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.30 «Авантюрист поневоле».
22.50 «Жизнь делает лучше, чем ты задумал...»

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25 «Научные расследования Сергея Малозёмова». 12+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «ОПЕКУН». 16+
21.40 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ». 16+

Чәршәмбе

13 июль
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ. ТАНЦЫ НА УГЛЯХ». 12+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00, 0.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00 «Без химии». 12+
21.00, 23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Аяз Гыйләҗев турында телеочерк. 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «БЕЗОПАСНОСТЬ». 12+
10.30, 21.00 «ГОРОДСКИЕ ШПИОНЫ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Непростые вещи». 12+
15.30 «Битва коалиций. Вторая Мировая война». 12+
16.15 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
18.00 Вечерние новости.
21.00 «Время».
21.45 «СПРОСИТЕ МЕДСЕСТРУ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «Цареубийство. Следствие длиною в век». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.20 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Другие Романовы». «Келья для принцессы».
7.35 «Театральная летопись. Петр Фоменко».
8.05, 23.40 «Великие фотографы великой страны. Сергей Левицкий».
8.50 «МУСТАНГ-ИНОХОДЕЦ».
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Андрей Штакеншнейдер. Мариинский дворец.
10.45 Academia. Николай Короновский. «Земля: вчера, сегодня, завтра».
11.35 Искусственный отбор.
12.15 «Давид Смелянский. Авантюрист поневоле».
13.00, 21.15 «МАЯКОВСКИЙ. ДВА ДНЯ».
14.30 «Азарий Плисецкий. Жизнь делает лучше, чем ты задумал...»
15.05 «Музеи без границ». Музеи «Альтес Хаус» и «Дом китобоя» в Калининграде.
15.35 Голливуд Страны Советов. «Звезда Фаины Раневской».
15.50 Знаменитые фортепианные концерты. И. Брамс. Концерт №2 для фортепиано с оркестром.
16.45 Спектакль «Одна абсолютно счастливая деревня».
19.00 «Монолог актрисы. Майя Тупикова».
19.45 Письма из провинции. Оренбург.
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.30 «Довести дело до конца».
22.50 85 лет Азарию Плисецкому. «Жизнь делает лучше, чем ты задумал...»

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25 «Научные расследования Сергея Малозёмова». 12+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ. СУДЬБЫ». 16+
12.00 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «ОПЕКУН». 16+
21.40 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ». 16+

Пәнҗешәмбе

14 июль
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2». 12+
10.00, 0.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ. ТАНЦЫ НА УГЛЯХ». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.00 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Безнең Республика - безнең гамәл». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Ватандашлар». 6+
12.05 «Ай нурында тулган моң». Римма Ибраһимова турында телеочерк. 6+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30 «Татарлар». 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Аклык турында җыр». Зөһрә Сәхәбиева турында телеочерк. 6+
20.00 «Бәхетем башкаласы». 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
10.30, 21.00 «ГОРОДСКИЕ ШПИОНЫ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+

12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Вместе по России». 12+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Битва коалиций. Вторая Мировая война». 12+
16.15 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
18.00 Вечерние новости.
21.00 «Время».
21.45 «СПРОСИТЕ МЕДСЕСТРУ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «Цареубийство. Следствие длиною в век». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.20 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Другие Романовы». «России царственная дочь».
7.35 «Театральная летопись. Петр Фоменко».
8.05, 23.40 «Великие фотографы великой страны. Евгений Халдей».
8.45 «ЛОБО».
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Александр Пель. Дом архитектора.
10.45 Academia. Андрей Панин. «Система исчисления времени в мире и в России».
11.35 Искусственный отбор.
12.20 «Виктор Берковский. Довести дело до конца».
13.00, 21.15 «МАЯКОВСКИЙ. ДВА ДНЯ».
14.30 «Азарий Плисецкий. Жизнь делает лучше, чем ты задумал...»
15.05 «Плавск. Дворец для любимой».
15.35 Голливуд Страны Советов. «Звезда Татьяны Окуневской».
15.50 Знаменитые фортепианные концерты. П. Чайковский. Концерт №1 для фортепиано с оркестром.
16.30 «Запечатленное время».
17.00 Спектакль «Война и мир. Начало романа».
19.00 «Монолог актрисы. Майя Тупикова».
19.45 Письма из провинции.
20.15 «Загадка жизни».
22.50 «Жизнь делает лучше, чем ты задумал...»

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25 «Научные расследования Сергея Малозёмова». 12+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «ОПЕКУН». 16+
21.40 «ПОД НАПРЯЖЕНИЕМ». 16+

Җомга

15 июль
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КӨТЕЛМӘГӘН КУНАК 2». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ. ТАНЦЫ НА УГЛЯХ». 12+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.00 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Родная земля». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 6+
20.00 «Без химии». 12+
21.00 «Юлчы». 6+
23.50 «МОЙ ПАРЕНЬ - АНГЕЛ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Үз җиремдә үз җырым». Гәрәй Рәхим турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Родная земля». 12+
19.35 «Заман көзгесе». 6+
20.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Рамил Курамшин турында телеочерк. 6+
21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ДЕРЕВЕНСКИЙ РОМАН». 12+
10.30, 21.00 «ГОРОДСКИЕ ШПИОНЫ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «СЛОМАННЫЕ ЦВЕТЫ». 16+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Битва коалиций. Вторая Мировая война». 12+
16.15 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.00 Вечерние новости.
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
23.25 «Петр Мамонов. Черным по белому». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ДВИЖЕНИЕ ВВЕРХ». 6+
23.55 Церемония открытия фестиваля «Славянский базар в Витебске».

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.00, 10.00, 15.00, 19.30, 23.10 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 «Другие Романовы». «Его Георгиевский крест».
7.35 «Театральная летопись. Петр Фоменко».
8.05 Гении и злодеи. Оскар Барнак.
8.30 «СЕРОМАНЕЦ».
10.20 «ВАЛЕРИЙ ЧКАЛОВ».
12.00 «Николай Кольцов. Загадка жизни».
13.00 «МАЯКОВСКИЙ. ДВА ДНЯ».
14.30 «Азарий Плисецкий. Жизнь делает лучше, чем ты задумал...»
15.05 «Владикавказ. Дом для Сонечки».
15.35 Голливуд Страны Советов. «Звезда Валентины Серовой».
15.50 Знаменитые фортепианные концерты. С. Рахманинов. Концерт №2 для фортепиано с оркестром.
16.30 «Запечатленное время».
17.00 Спектакль «Война и мир. Начало романа».
18.00 «Забытое ремесло».
18.15 «Билет в Большой».
19.00 «Монолог актрисы. Майя Тупикова».
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 «Люстра купцов Елисеевых».
21.00 «ФАВОРИТ».
23.30 «ДЖЕЙН ЭЙР».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СУДЬБЫ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.50 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
19.50 «ОПЕКУН». 16+
22.30 Гала-концерт «Aguteens Fest».

Шимбә

16 июль
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Бир кулыңны». Зөлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар концерты. 6+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 Хәмдүнә Тимергалиева истәлегенә багышланган концерт. 6+
17.00 Г.Тукай. «Сөй гомерне!» 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Ватандашлар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «ПРАЗДНИЧНЫЙ ПЕРЕПОЛОХ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Мәхәббәтем - җыр минем». Эмиль Җәләлетдинов турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 Рамил Курамшинның юбилей концерты. 12+
14.40 «Шаян хәлләр». 12+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Язылмаган язмышым». Салават Фәтхетдинов концерты. 12+
22.35 «ҖЫЛЫ ЭЗЛИ ҖАННАР». 12+

«ЭФИР»

5.00 «Опыты дилетанта». 12+
5.30, 0.40 «Вместе по России». 12+
6.30 «Клинический случай». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Сказочный патруль».
8.00 «Спасите, я не умею готовить!» 12+
8.45 «НЕВЕСТА ИЗ МОСКВЫ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ОТПЕТЫЕ НАПАРНИКИ». 16+
15.00 «Инвиво». 12+
15.30 «ПСИХОЛОГИНИ 2». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ДЕВУШКА ГРЕЗ». 16+
23.00 «КЛАН КЕННЕДИ: ПОСЛЕ КАМЕЛОТА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 15.00 Новости.
10.15 К 60-летию Григория Лепса. «Печаль моя смешна». 16+
11.20, 12.15 «Видели видео?»
14.00, 15.15 «Молога. Русская Атлантида». 12+
16.15 «СТАЛИНГРАД». 12+
18.00 Вечерние новости.
18.20 «На самом деле». 16+
19.25 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.15 «БЕЛАЯ НОЧЬ, НЕЖНАЯ НОЧЬ...» 16+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «НИКОГДА НЕ ГОВОРИ «НИКОГДА». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ИДЕАЛЬНЫЙ ПАЦИЕНТ». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 «Заколдованный мальчик».
7.50 «ФАВОРИТ».
10.00 «Передвижники. Василий Поленов».
10.30 «ЗВЕЗДНЫЙ МАЛЬЧИК».
11.45 Музыкальные усадьбы. «Дютьковский кудесник. Сергей Танеев».
12.10 «Этот удивительный спорт».
13.30 Диалоги о животных.
14.15 «Лебединое озеро». .
16.20 «Энциклопедия загадок».
16.50 «Андрей Дементьев. Всё начинается с любви...»
17.30 Искатели. «Сокровища Хлудовых».
18.15 «БАРЫШНЯ-КРЕСТЬЯНКА».
20.05 Российские звезды мировой оперы. Хибла Герзмава. Любимые романсы.
21.00 «АНАТОМИЯ УБИЙСТВА».
23.35 Чучо Вальдес на фестивале Мальта Джаз.

«НТВ»

4.55 «Кто в доме хозяин?» 12+
5.30 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.35 «ОПЕКУН». 16+
22.15 «Маска». 12+

Якшәмбе

17 июль
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Яшәү яме». Сиринә Зәйнетдинованың юбилей кичәсе. 6+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Безнең Республика - безнең гамәл». 12+
12.00, 19.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент.Общество». 12+
13.00 «Каләм очында галәм». Марсель Галиевның юбилей кичәсе. 6+
15.30 «Татар халык җырлары».
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.30 «Әдәби хәзинә». 6+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
22.00 «УДАЧА НАПРОКАТ». 12+
23.35 «НЕВЕРОЯТНЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ФАКИРА». 18+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 «Җаным җырлый». Фердинанд Сәлахов концерты. 12+
9.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Фәнис Җиһанша турында телеочерк. 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 «Кайда сез, яшьлек еллары». Зәһрә Шәрифуллина концерты. 6+
14.30 Спектакль «Мәхәббәт турында сөйләшик». 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Олы юл әйтте...» циклыннан «Ышаныч». 12+
21.45 Спектакль «Күрәсем килгән иде». 12+

«ЭФИР»

5.00 «Опыты дилетанта». 12+
5.30 «Вместе по России». 12+
6.30 «Не факт». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Сказочный патруль».
8.00 «Инвиво». 12+
8.30 «ПСИХОЛОГИНИ 2». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ДЕВУШКА ГРЕЗ». 16+
15.00 «Еда. Правильное питание». 12+
15.30 «Наша марка 2». 12+
15.45 «НЕВЕСТА ИЗ МОСКВЫ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ОТПЕТЫЕ НАПАРНИКИ». 16+
23.00 «КЛИНЧ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.05, 6.10 «ОТЧАЯННЫЕ». 16+
6.00, 10.00, 12.00, 15.00 Новости.
7.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.15 «Здоровье». 16+
9.20 «Непутевые заметки». 12+
10.15 К 80-летию начала Сталинградской битвы. «Город в огне». 12+
11.15, 12.15 «Видели видео?»
13.55, 15.15 «Я - Вольф Мессинг». 12+
16.05 «СТАЛИНГРАД». 12+
18.00 Вечерние новости.
18.20 «Порезанное кино». 12+
19.15 «ОПЕРАЦИЯ «Ы» И ДРУГИЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШУРИКА».
21.00 «Время».
22.35 «ПРАВИТЕЛЬСТВО США ПРОТИВ РУДОЛЬФА АБЕЛЯ». 12+

«РОССИЯ»

5.35 «СИНДРОМ НЕДОСКАЗАННОСТИ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «НИКОГДА НЕ ГОВОРИ «НИКОГДА». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Энциклопедия загадок».
7.05 Мультфильмы.
8.20 «БАРЫШНЯ-КРЕСТЬЯНКА».
10.05 «Обыкновенный концерт».
10.35 «МОЛОДАЯ ГВАРДИЯ».
13.20 Диалоги о животных.
14.00 «Коллекция».
14.30 Острова. Елена Камбурова.
15.10 Спектакль «Антигона».
16.40 «Пешком...»
17.05 «Чистая победа. Сталинград».
17.55 К 90-летию со дня рождения Евгения Евтушенко. Больше, чем любовь.
18.35 «Романтика романса». Евгению Евтушенко посвящается.
19.30 Новости культуры.
20.10 «СУЕТА СУЕТ».
21.35 Большая опера- 2016.
23.35 «ВАЛЕРИЙ ЧКАЛОВ».

«НТВ»

5.00 «Кто в доме хозяин?» 12+
5.35 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.40 «ОПЕКУН». 16+
21.25 «Ты не поверишь!» 16+
22.20 «Маска». 12+

Тәтеш районының Тоншерма авылында Раиса Сарафанова белән Петр Илюшкин 1994 елдан бирле бергә яши. 1949 елгы хатын-кыз ир йортына ул чакта 23 яшендә булган улы В.Прокопьев белән килә. Василий тумыштан акылга зәгыйфь, шул сәбәпле, башка балалар кебек мәктәптә дә укымаган, ләкин үз-үзен карый ала, өй тирәсендә вак-төяк эшләрдә булышырга сәләтле, туган телендә – чуашча сөйләшә, русча да яхшы аңлаша. Соңгы вакытларда 50 яшьлек ир-ат урамда бары тик өлкәннәр белән генә күренгәли. Кечкенәдән психиатр күзәтүендә тора ул. 2011 елда әнисе экспертиза үткәрттергәч, ир кешенең психик кимчелеге уртача дәрәҗәдә икәне раслана, район суды чирле кеше мөстәкыйль яшәрлек түгел дип таба, 2 нче төркем гомерлек инвалидлык бирелә аңа. Ә менә опекуны итеп әнисе түгел, 1951 елда туган Петр Илюшкин билгеләнә.

Акылы чирле чикне белми

Монысы инде 1949 елгы карчыкның эчкече булуы нәтиҗәсе. Петр хәләл җефетенең элегрәк 10-15 көн салып йөргәч туктап торуын, ә соңгы бер елда тоташтан эчүен әйтә, көненә кимендә, өч литр сыра чөмерә, лаякыл исергәнче эчә, ди. Искәртеп үтик, карчыгы урамда кеше көлдереп йөрмәсен өчен, сыра һәм тәмәкене ул үзе алып кайтып бирә. Петр үзе эчми, тартмый торган хөрмәтле кеше авылда, ә Раиса турында фикерләр тискәре, әлбәттә. Аны акылга сай һәм хәвефле зат дип санаучылар да күп. Аның белән торырга куркам дип, Петр үзе дә әйткәләгән була. Моның чыннан да шулай икәне, Р.Сарафанова узган елның 14 октябрендә коточкыч явызлык кылып куйгач, рәсми рәвештә расланды.

Ул көнне Петр иртүк торып хуҗалык эшләре белән кайнаша, аннан соң телевидение өчен еллык акчаны түләү ниятеннән район үзәгенә китә, кирәкле даруларны да алып, шул ук Тәтеш-Буа автобусы белән төш вакытында кайтып та җитә. Өйалды ишеге эчтән бикле булганга, шактый шакыганнан соң, инде тәрәзәне алып керәм дигәндә Раиса ишекне ача. Аның махмырдан интегүе күренеп тора, шул ук вакытта абзый матчадан асылынып торган бауга игътибар итә. Моның сәбәбе тиз ачыклана, карчык урындык алып килеп асылынырга җыенуын төшендерә. Ир-ат моңа юл куймый һәм Василийны эзләргә керешә, мич янындагы җәймә капланган караватында күренми ул, ә ачып карагач коточкыч күренеш хасил була, ягъни балта белән чабып канга баткан ир-атның җансыз гәүдәсе ята анда.

Тетрәнгән абзый сорауларына аңлаешлы җавап бирми карчык, гел үләм, дип баш төзәтергә сорый. Петр аның хәле чыннан да хөрти икәнен күрә, тиздән төрмәгә ябачакларын да белә һәм кибеттән һәркайсы литр ярымлы өч шешә сыра алып кайтып бирә. Хатын-кыз баш төзәтеп рәтләнә төшкәч тә, явызлыгы сәбәбен аңлата алмый, бары тик түзеп тора алмадым дип мыгырдый.

Шулай итеп, Петр шактый вакыт узгач кына, авыл фельдшерының өенә барып хәвефле хәбәрне әйтә. 23 яшьлек кыз аңа ияреп китми, чөнки хәтәр карчыктан шикләнә, шул сәбәпле, полиция һәм авыл башлыгы Ф.Галимовка шалтырата, фаҗига урынына җитәкче ир-ат белән бергә бара. Әлбәттә, ярдәмгә мохтаҗ кеше булмый анда. Полиция хезмәткәрләре Р.Сарафанова белән П.Илюшкинны эчке эшләр бүлегенә алып китәләр, тиздән ир кеше аннан чыгарыла, икенче көнне зинданда кунган 72 яшьлек карчыкны суд сак астына алырга дигән карар чыгара. Шул ук көнне аның 50 яшьлек улы Тоншерма зиратына җирләнә. Бу хакта Раисаның Буада яшәүче сеңлесе Любовь Сарафанова да ишетми кала. Аңлы рәвештә кеше үтерү очрагы буенча кузгатылган җинаять эшендә зарар күрүче итеп шушы ханым билгеләнә.

П.Илюшкин әлеге мәхшәргә Василийның кайвакыт әнисе әйткәнне тыңламавы этәргеч биргән дип исәпли. Бу җәһәттән, аның биргән ризыкны ашамавын, өстенә япкач карышуын, шуның өчен әнисенең аның яңагына сугуын да искә ала. Сарафанова исә гаепне иренә дә сылтагандай сөйли. Имеш, 14 октябрьдә ул Петрның аны картлар пансионатына озатырга җыенуы турында әйткәнен исенә төшергән, чирле малаен аның белән калдырырга теләмәгән, шуңа күрә Василийны үтерергә, үзе асылынырга уйлаган. Әйтүенчә, караватта яткан ир-атны алдан җеп белән буып үтерергә тотынган, әлбәттә, аның каршылык күрсәтүе сәбәпле булдыра алмаган, шуннан соң чоландагы балтаны алып кереп, үткен ягы белән, күбрәк баш тирәсенә сугарга керешкән, хәтәр коралны комод артына яшереп куйган. П.Илюшкин аны картлар йорты белән куркытуын кире кага, ул сәрхуш белән ник интегәсен, озат пансионатка, дип миңа авылдашлар гына әйткәләде, ди. Күрәсең, чыбыксыз телефон бу хакта Раисага да җиткергән була.

Суд-медицина экспертлары мәрхүм гәүдәсендә ачык рәвештәге егермедән артык яра саный. Шуңа күрә тикшерү комитетының Буа районара бүлегеннән Айрат Мөхәммәдуллин аңа аеруча ерткычлык белән кеше үтерүдә рәсми гаепләү белдерә. Бу исә Р.Сарафанова 8 дән 20 елга кадәр ирегеннән мәхрүм ителәчәк дигәнне белдерми. Психиатрлар комиссиясе карчык акылга зәгыйфь булганга үз гамәлләрен аңларлык хәлдә булмаган, ул үзе һәм тирә-юньдәгеләр өчен куркыныч зат, шуңа күрә саклана торган психиатрия клиникасында мәҗбүри дәвалануга мохтаҗ дип белдерә. Шуннан соң тикшерү изоляторында берничә ай утырып өлгергән карчык республика диспансерына урнаштырыла. Бу хактагы рәсми карар Татарстан Югары судында чыгарылачак.

* * *

Узган елның 13 ноябрендә Әлмәттә 54 яшьлек Сергей Григорьев та шундый ук хәтәр хатын-кыз кулыннан һәлак булды. Әфганстандагы сугыш ветераны 1974 елгы Мәҗидә Миначеваның пычаклы һөҗүмен кире кагып азаплануы нәтиҗәсендә аның кул, чигә-маңгай тирәсендәге тугыз җәрәхәте әллә ни зыянлы булмый, сул ботындагы ике төп кан тамыры киселүгә китергән унынчысы язмышын хәл итеп куя.

М.Миначева Свердлов өлкәсендә туып-үсә. Өлкән яшьтәге әтисе аның холкындагы сәерлекләр 15 яшьләрендә сизелә башлануын әйтә. Башлангыч чорда ошбу дорфалыкларга әллә ни игътибар итүче булмый. 90 нчы елларда чырае үзгәреп әйләнә-тирәдәгеләргә җикеренеп холыксызлана, гел бер сүзләрне кабатлый, әөянәге узып тынычлангач, берсен дә хәтерләми торган кыз махсус сырхауханәгә салгач яисә өендә дарулар кабул иткәч кенә, үз хәленә кайта торган булып кала, чир кискенләшү очраклары бигрәк тә көз-кыш көннәрендә еш кабатлана. Соңрак үткәрелгән экспертизада Мәҗидәнең әнисе ягыннан карт әбисендә эпилепсия авыруы булуы күрсәтелеп нәселдәнлеккә дә ишарә ясала.

2019 елда хәләл җефете вафатыннан соң ир кеше ике кызы белән Татарстанга күченеп кайта, аларның кечесе белән үзе Сарман районында кала, Мәҗидәгә Әлмәттә тулай торак бүлмәсе алып бирә. Шул рәвешле, инде 45 яшьләрендәге хатын-кыз мөстәкыйль яши башлый, әйтүенчә, сәүдә оешмаларын җыештырып, ашханәләрдә савыт-саба юып вакытлы эшләрдә эшләп очын очка ялгап бара. Даими эшкә урнашып кешечә яшәргә, психик чиреннән бигрәк, эчү дигән зәхмәте комачаулый. Соңгысы аның көтелмәгән явызлыклар кылып кую мөмкинлеген тагын да арттыра. Хәер, 13 ноябрь мәхшәре бөтенләй үк көтелмәгән хәл түгел үзе. Әфган кушаматлы С.Григорьев шул ук «общага»да туганнары биргән бүлмәдә 2013 елдан бирле яшәгән, иш-ишен таба дигәндәй, күршеләр берара ир белән хатын кебек тә торганнар, 1967 елгы сугыш ветеранының барлы-юклы пенсиясе, очраклы керемнәре хисабына көн күргәннәр. Әлбәттә, ике сарык башы бер казанга сыймаган кебек, сәрхушләр дә аерылышкан. Тиздән туганнар эшләмичә йөреп, коммуналь хезмәтләр өчен түләмәгән, торакны ташландык хәлгә китергән Сергейны бүлмәдән чыгаралар. Шуннан соң ир кеше уртак душ бүлмәсендә куна башлый.

Күршеләр аның турында эчсә дә, тыныч, зыянсыз кеше иде, диләр. Юкса, юыну бүлмәсендә кунып йөрергә рөхсәт итмәсләр иде, мөгаен. Ә Мәҗидә хакында сөйләгәндә «ненормальная» сүзе еш кулланыла, хәтта кеше алдында да Сергейга ташлана иде дип, ызгыш-бәрелешләрнең аннан башлангыч алуын белдерәләр, бигрәк тә соңгы вакытта Мәҗидәнең Сергейга үтермичә тынычланмаячакмын, дип еш ярсып йөрүләрен искә алучылар бар. Юлия атлы күрше Сергейга полициягә барырга тәкъдим итүен дә искә ала. Сугышларда катнашкан ир-ат Мәҗидәдән курыкмыйм дип, хатын-кыз өстеннән шикаять белән йөрми, билгеле.

Юлия 13 ноябрьдә дә күршесеннән Сергейның «манчырга» җыенуы турында ишетә, ә кичкә таба баскычтан менеп килгәндә, аның сүгенеп кычкыруын ишетә, икенче катка күтәрелгәч, канга баткан С. Григорьевның идәндә ятуын күрә. Мәҗидә исә бүлмәсенә кереп бикләнгән була, әйтүенчә, анда эзләп таба алмаслар дип уйлый.

Аның күрсәтмәләрен гадәти дияргә мөмкин. Башка бик күпләр кебек үк ул да ошбу гамәлен мәрхүмнең явыз кылануы белән акларга, аннан курку нәтиҗәсе итеп күрсәтергә омтыла. Тикшерү барышында шунысы ачыклана, икенче каттагы мәйданчыкка С. Григорьев пәйда булганчы ук кулына пычак тотып чыга, ягъни «дошман»ын сагалап тора ул. Моның сәбәбен дә аңлата алмый. Имеш, усал кеше аңа таба бер адым ясагач та, куркудан аның кулындагы бер шешә аракысын бәреп төшереп челпәрәмә китерә, Сергей тагын до котырынып киткәч, уң кулындагы хәтәр әйберне эшкә җигә, ир-ат идәнгә егылып аңсыз калгач, югарыда телгә алынган хәлиткеч җәрәхәтне ясый.

Аның аңлы рәвештә кеше үтерүе аермачык. Гаебен ул үзе дә таный, Әлмәт шәһәр суды авыр җинаять кылучыны сак астына ябарга карар кыла. Бөгелмәдәге тикшерү изоляторында нәкъ ике ай утырган М.Миначева республика психиатрия сырхауханәсенә салына. Чөнки экспертиза аны да үз гамәлләрен аңларлык булмаган, үзе һәм башкалар өчен хәвефле зат буларак мәҗбүри дәвалануга мохтаҗ дип таба.

Кызганыч ки, акыл ягыннан чирле кешеләрнең чиктән ашкан явызлыклары турындагы мондый мисалларны күпләп китереп була.

Наил ВАХИТОВ.

Мәдәни җомга

Кай ник югалган?

яки Лабораторияләр зыяны

Режиссер А.Устинов Казан яшь тамашачы театрында (ТЮЗ) Х.К.Андерсенның «Снежная королева» әкиятенә нигезләнеп драматург Е.Тимофеева язган сценарий буенча «Здесь был Кай» дип исемләнгән спектакль куйды. Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла, дигән сыман, рус театры турында үзебезнекеләрне күз уңында тотып язуыбыз. Ник дигәндә, «Здесь был Кай» тамашасы әлеге дә баягы иҗат лабораториясенең бер нәтиҗәсе буларак куелган. Ул рус ТЮЗында былтыр көз Евгений Шварцның 125 еллыгы уңаеннан үткән иде.

Бала чактан һәммәбезгә яхшы таныш әкиятне детективка әйләндереп, бүген кешеләрнең күпләп юкка чыгуы турында социаль драма куярга теләүләре аңлашыла. Чыннан да, дөнья буенча бер хәбәрсез югалган балалар, яшүсмерләрнең исәбе юк. Шулай да спектакльдә якынча саннар китергәннәр, әсәрне сәхнәләштерүгә «Лиза Алерт» югалганнарны эзләү хәрәкәте вәкилләре ярдәм иткән. «Ел саен илдә 180 мең кеше хәбәрсез югала, шуларның 20 меңе табылмый, шулар арасында 30 меңләп бала исәпләнә», – дип коточкыч саннар белән башлыйлар спектакльне. Тамашаны караганда күңелне якын кешеләрең өчен курку хисе биләп ала һәм бу хис театрдан чыккач та тиз генә онытылмый. Салкын төсләр, җан өшеткеч ут, бериш актерларның бертөрле монотон тавыш белән сөйләве бүгенге битарафлыкны сәхнәдә торгызырга мөмкинлек бирә. Биредә Кай да, Герда да – шартлы геройлар. Кар патшабикәсе дә персонаж түгел, гүя кешеләрнең бер-берләренә карата салкынаюын билгеләгән күренеш кенә.

Бер генә нәрсә аңлашылмый – ни өчен яңа спектакль кую өчен нәрсәнедер җимерергә, ботарларга кирәк соң? Яңа пьеса язып, шуның нигезендә социаль драма куеп булмыймыни? Һәр лабораториядә эшләгән эскизны олы сәхнәгә меңгезү нигә хаҗәт? Килмешәк режиссерлар, ни куйсак та килешә, дип уйлыйлармы әллә? Без тамашачы исә бу күренешләргә ник битараф калырга тиеш әле?!

Бу уңайдан М.Гафури исемендәге Башкорт дәүләт театрының моннан берничә ел элек куелган «Хыялга каршы» спектакле искә төште. Алар классикларны имгәтмичә, хәзерге заман авторы Айгиз Баймөхәммәтовның «Калдырма, әни» повесте буенча пьеса иҗат итеп (авторы – Айгизә Ишбулдина) балалар йортларында тәрбияләнүче ятим балалар турында фаҗигаи яңгырашлы, көн кадагына суга торган үткен спектакль иҗат итте (режиссеры – Илсур Казакбаев) һәм Казаныбызга бер гастрольгә килгәч күрсәткәннәр иде. ТЮЗ спектакленнән аермалы буларак, «Хыялга каршы» шактый озак – тәнәфессез ике сәгатькә якын дәвам итә. Күңелне шундый ук шомлы хисләр били. Аның каруы биредә классиканы һәм балачак хатирәләрен ботарлауларыннан күңел әрнеми. «Хыялга каршы» зур уңыш белән бара. Бурятиянең Улан-Удэ шәһәрендә иң шәп ансамбль һәм хәзерге заман прозасын сәхнәләштереп, яңа сурәтләү чаралары эзләү өчен фестивальдә бүләккә лаек булган иде. «Здесь был Кай» тамашасына классиканы җимергән өчен антиприз бирсәләр генә инде...

Лабораторияләр «булганны җимерү өчен генә» дигән фикер көннән-көн ныгый бара. Яшь иҗатчылар үзләре иҗат итә алмаганлыктан, исәпсез лабораторияләр үткәрә, дигән уй килә. Кариев театрында, мәсәлән, «Алтынчәч» спектаклен карадык, Алтынчәчне генә күрмәдек. Алтынчәч татар кешесенә опера иҗат иткән композитор Нәҗип Җиһанов, либреттосын язган каһарман шагыйрь Муса Җәлил, анда җырлаган Галия Кайбицкая, Фәхри Насретдинов, Мәрьям Рахманкулова һ.б. затлы җырчыларыбызның истәлеге буларак, Болгар ханнары турында хәтер белән бергә күңелебезгә кереп калган. Еллар үткәч тә күңелне җылытып торган кадерле ядкәрләр белән уйнау үзе кешелексезлек һәм вәхшилек түгелмени?

Шулай итеп классикларның текстларын ботарлау күренеше үзе социаль драмага әйләнеп бара кебек. Бу хакта үзенә бер спектакль куярга мөмкин. Әмма яшь иҗатчылар бу юлы темасын, сюжетын үзләре уйлап тапсын иде...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 8.07.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2760

16+